Безнең МИРАС

12
декабрь 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

24 НОЯБРЬДӘ КФУНЫҢ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫНДА «ИЛҺАМЛЫ КАЛӘМ» ҺӘМ «ШИГЪРИ САБАНТУЙ» ДИП АТАЛГАН БӨТЕНРОССИЯ ӘДӘБИ-ИҖАДИ КОНКУРС-ФЕСТИВАЛЕНЕҢ ЙОМГАКЛАУ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ.

Институт директоры Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов җиңүчеләрне котлый

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
12(35)
декабрь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

42

ЭЧТӘЛЕК

3 Баш мөхәррир мөнбәре

ТАРИХИ МИРАС

4 **Тәхетле җәллад.** *Фәнзаман Баттал*
9 **Сөембикә манарасы.** *Габделбари Баттал*
20 **Төньяк төркиләрдә төркичелекнең тәүге авазы. Шиһабетдин Мәрҗани.** *Йосыф Акчура*
22 **Мишәрләр.** *Зариф Бәшири*

ПЕДАГОГИК МИРАС

28 **Әхлак.** *К.Бикколый, Г.Госмани*

ҖИҢҮ — 70!

31 **Очыш дәвам итә!..** *Шаһинур Мостафин*
34 **Бабам истәлекләре...** *Ришат Гапсәләмов*
36 **Дәһшәтле еллар хатлары.** *Әлфия Шамова*
40 **«Илемә булган сөю ялкыны»** *Шәфигулла Гарипов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

42 **Хакыйкатьнең төсе нинди?** *Марат Закир*

ӘДӘБИ МИРАС

44 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
48 **Маҗаралы хикәятләр.** *Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль*
51 **Бим шәһәре төзүчесе һәм Гүәшир падишаһның вәзире**
64 **Солдат.** *Гаяз Исхакый*
74 **«Айкай сине Иделем...»** *Марсель Әхмәтҗанов*
79 **Бәяләмә...** *Рәмзи Вәлиев*
85 **Язмышым бүләге.** *Миннәхмәт Кашапов*
88 **Без ачлыкны ешрак күрдек шикелле...**
90 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
93 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

ХӘТЕР САГЫНДА

95 **Чулпылар.** *Руфия Мөхетдинова*
96 **Ипле һәм игътибарлы түрә иде.** *Гәрәй Рәхим*



51 **БИМ ШӘҺӘРЕ ТӨЗҮЧЕСЕ ҺӘМ ГҮӘШИР ПАДИШАҺНЫҢ ВӘЗИРЕ.**

95 **ЧУЛПЫЛАР.** *Руфия Мөхетдинова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

СПОРТ

104 **«Афәрин, Айрат!»** *Атлас Гафиятов*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

108 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның декабрь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

112 **Ул елларга карап көнләшерлек...**

114 **Мирасворд**
115 **2014 елга «Безнең мирас» журналының библиографиясе**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Декабрь*

Заказ №А-3189. **Тираж** — 1558 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 3.12.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Иске Казан». Гравюра, 2012 ел.
Н.Хуҗиәхмәтов рәсеме.

Ә БЕЗДӘ БӘЙРӘМ ӘЛЕ...

Илдә ядрә исләреннән
Башларың әйләнмәле:
Кардәш-ырулар кырыла...
Ә бездә... бәйрәм әле?!

Ил ялангач, ач булса да,
Кемнәрдер бирән әле...
Ил картлары хәер сорый...
Әй... бездә бәйрәм әле.

Күзләрең әйләнмәле дә
Телләрең бәйләнмәле:
Бәягә бәя биргесез...
Әй... бездә бәйрәм әле?!

Күпләр белми, азлар белә
Яшәүнең хәйләләрен...
Кесәдә җилләр сызгыра...
Әй... бездә бәйрәм әле?!

Уйласаң, уйлар коточкыч! –
Сораулар... хәйран әле...
Иртәгә нинди көн килер?
Әй... бездә бәйрәм әле...



Илья Репин «Явыз Иван һәм аның улы Иван. 1581 елның 16 ноябре». Киндер, майлы буяу. 1885 ел

ТӘХЕТЛЕ ҖӘЛЛАД

Фәнзаман Баттал

Ил тәхетенә диктаторлар, тираннар утыруга ук, ни сәбәптер, көтелмәгән афәтләр башлана – йә җир тетри, су баса яки күп зыяннар китерүче вулканнар уяна, меңәр кешелек йортлар шартлый, яңа сугышлар кабына һәм ил халкында шом арта... Булган һәм булуы бик ихтимал андый афәтләрне санап бетермәле түгел...

Иван Грозный тәхеткә утыруга һәм, өйләнү ниятенә кереп, туй башлавына ук Мәскәүдә коточкыч янгыннар башлана. Шәһәр урамы-урамы белән күз алдында юкка чыга башлый. Апрель башы гына булуга карамастан, күкләр, җирләр, урамнар җәһәннәм утыдай кызганлыктан, карлар эреп бетә. Янгын, хәтта Яуза елгасы аша сикереп, шәһәрнең башка төбәкләрен дә мәхшәргә әйләндерә, йортларны, башка биналарны рәттән себереп бара, янган урыннарда көл генә җәелеп кала. Кинәт, алда нинди тормыш башланачагын хәбәр иткәндәй, бөтен Мәскәүдә көчле зыңгылдау тавышы яңгырый. Монысы исә, соңыннан аңлашылганча, Благовещенский соборының бик биектә асылынып торган зур да, авыр да чаңы җиргә убып төшү галәмәте була. «Олы кала»га, ягъни Кремльгә дә үтеп керә

ут, давыл көчәя, өермәләр күтәрелә, патшалыкның казнасы төтенгә әйләнеп оча, Иванның ат сарае, корал палатасы юкка чыга, арырак Намуслы Тәре храмы дөрли. Күптән түгел генә Иван белән Анастасияне никахлаган митрополит Макарий янучы храмнардан аеручa кадерле иконаларны коткару белән җитәкчелек итә. Янгын, кай якка да качу форсаты калдырмыйча, митрополитның үзен дә уратып ала. Ул Тайник башнясыннан бауга тотынып төшмәкче була. Ләкин бавы өзелә, үзе аска мәтәлеп җан бирә... Урысларның ул замандагы сөйләме белән әйткәндә, «железо там яко олово разливашеся, и медь яко вода растаяваше». Аңлашылгандыр, тимер — кургаштай, бакыр судай эреп ага, дип язганнар. Шул чорда теркәлгән тарихи мәгълүматка ышанмый булмый: 25000 ихата утка оча, меңнәрчә адәм янып үлә, исән котылганнары торaксыз кала...

Шушы урында укучыма сорау бирәсем килә: — Куркынычмы?

Әйе, бая да әйткәнемчә, коточкыч хәл! Әмма, янгыннар тынгач — Урыс кенәзлегендә, тора-бара Урыс илендә, аннары Урыс империясендә тагын да хәтәррәк хәлләр башлана... Анысы инде — «дошманнар эзләү». Сүзне кыска тоту өчен шуны гына әйтеп үтәм: бер нәселдән яратылган Годуновлар һәм Романовлар арасында елларга сузылган бәрелешләр, рәхимсез җәзалар, үтерешләр арта, яңадан-яңа гайбәтләр, гыйбрәтләр арта... Бер чакта да сугышсыз яшәмәгән ил кабат кан коя... Иоанн Грозный иң хәтәр җәзаларны ләззәт белән күзәтергә ярата. Әйтик, әкрен утта көйдерелүче якыннарының, әле аннан алдарак «остазларым» дип атаган акыл ияләренең җан бирү вакытларында күзләренә мыскыллы, елмаюлы карашын төбәп:

— Йә, хыянәт итүеңнең җәзасы рәхәтме? — кебегрәк сораулар биреп йөри торган булган. Ә инде шактый «дошманнарын» үз куллары белән буып үтерүне еш кабатлаган.

Тарихчы Руслан Скрынниковның язуына караганда, Иван үзенең яңа туган балаларын да йокы бүлмәсендәге тәрәзәдән елгага ыргытып бара торган булган. Бу очракта шунысын да әйтеп үтмичә булмый, зина хурлыгы җәһәтеннән чик-чаманы белмәгән бу патшаның әледән-әле алыштырып торган никахлы хатыннары җидедән арта, никахсыз сөяркәләре күп була. Ә инде җитлеккән, өйләнгән улын да үз куллары белән үтерүе турында бөек урыс рәссамы Илья Репинның «Явыз Иван үз улын үтерә» дигән картинасын күрмәгән кеше юктыр. Иванның бу сурәттәге ерткыч чырае балаларның гына түгел, өлкәннәрнең дә котын алырлык. Ник үтергән икәнлеге дә тарихта сер итеп сакланмаган. Үз килене янына кереп, аны көчләп, зина кылып яткан мәлдә өсләренә улы килеп керә. Шуның «вакытлы-вакытсыз борчуына» үртәлгән, ярсыган Иван, кем әйтмешли, сикереп торып, улын буа башлый. Ахырын әйттек инде, шул буунын үтергәнче дәвам итә...[1] Дөрес, Иванны идеаллаштырырга ниятләүче кайбер шовинистлар бу сурәтнең исеменә дәгъва да белдереп маташалар. Янәсе, бу рәсем элек «Явыз Иван улы белән» дип кенә аталган. Ниятләре дә бик яхшы аңлашыла: миллионнарча кешеләрне кырып, канга батырып, күп милләтләрнең яшәеш рәвешен гарипләндереп, урыс державасы биләмәләрен киңәйткән патшаны ул кадәр үк вәхши итеп күрсәтүне яхшысынмыйлар. Ләкин үткән тарихны чистартырга, иске замандагы әсәрләргә дә цензура кертергә ниятләү җинаять саналыр иде. Ә хакыйкатьне нык белгән бөек Репин үзенең ошбу иҗатын тарихи хаклык белән бик дөрес исемләгән!

[1] Явыз Иванның улын үтерү сәбәпләре берничә.

Хәер, зиначылыкта чик-чамасы булмаган бу патшаның үлем чире дә азгынлыктан булуын үз заманында ук яхшы белгәннәр. Ә инде медицина фәне алга киткәч, аның каберен ачып тикшергән, калдыкларына анализ ясаган галимнәр дә Иванның сифилистән җан биргүен төгәл исбатлаганнар[2]. Җирәнгеч булса да әйтим: җан биргүгә үк, каны бик тиз таркала башлаудан, аның мәете кабара башлаган, җеназасына әзерләүче якыннары да чыдый алмаслык сасы ис таралган. Урыс мәкален дә истә тотсак, «собаке — собачья смерть», ягъни этко — этләрчә үлем сыманрак ахыр булган бу...

Бу Явыз Татар Иленә басып кергәч кенә ерткычка әверелмәгән. Бала чагыннан ук үзенең дуамаллыгы, мәкерле, акылга сыймаслык «уеннар»дан рәхәтлек таба белүе белән күпләрнең котын ала торган булган. Мәсәлән, биек биналар түбәсенә песи, эт һәм башка җан ияләрен алып менеп, югарыдан төртеп төшерүдән кызык тапкан. Тора-бара, үзенә ияртеп, үз тирәсе балаларны да алып менә югарыга явыз малай һәм, шулвакыттагы тарихчылар теле белән әйтсәк, «начал и человеков ураняти»... Күңел ачуының берсе — боярларның малайларын атка атландырып, урам буйлап, шыркылдап көлә-көлә, кешеләрне таптатып йөрү... Алай гына да түгел, базар кебек күп халыклы урыннарга кылычлар болгыйболгый көтмәгәндә килеп керү һәм тыныч халыкның башларын күмәкләшеп кыеп йөрү... (Шушы ук «уенны» булачак император Пётр I дә яратканлыгы тарихи китапларда очрый.)

Әле тәхеткә утырмас борын ук бояр Шуйскийны этләр өереннән талатып үтертүе дә бик гыйбрәтле. Үтерткәннән соң, мәетен сәгатьләр буе алдыртмыйча, шул тирәдә әрле-бирле куанып йөрүе дә тарихта урын тапкан. Ә инде үз биләмәләрендәге шактый шәһәрләрдә «опричнина» дип аталган ун мең кешелек җәза отрядлары оештырып, бихисап санда урысларны да кырып йөрүе аерым бер тема...

...Инде хәзер, милләтебездә күп сораулар тудырган нәсел-нәсәбен барлап карыйк дөньяда тиңе булмаган бу Явызның. Алдан ук әйтеп куям: тикшерү, ачыклау вакытында күпләрегез хурланыр, арагызда әледәнәле «әстәгъфирулла!»ны кабатлаучылар да булыр... Ә мин, атаклы тарихчылар белән берлектә, урыс патшалары династияләренең кемнәр «ярдәме һәм гаебе» аркасында кан яңартулары, буталышлары, кыска гомерле булулары, шактый патшаларның тәхеттә утырган чакта ук чери башлаулары, үзара үтерешләре, ни сәбәптән Россия кешеләренең берчакта да бәхетле тормышка ирешә алмаулары турында кыскача гына исбатламалар тәкъдим итәм. Шунысын алдан ук әйтеп куям: язып утырганда әледән-әле көләм дә, гарьлектән чыккан яшьләремне дә сөртеп-сөртеп куям...

...Күренекле Николай Коняев болай яза: «Костромага Ярославль ягыннан барасың икән, карашың Иделнең сулъяк ярындагы ак диварлы һәм алтынланган башлы Ипатьев монастырена төшәчәк. Әле Иван Калита заманында ук аның төзеләчәк урынында Чет исемле (татарча әйтелеше ничектер?) татар морзасы йоклап ял иткән һәм төшендә ул апостол Филиппны Һәм великомученик Ипатий Гангрскийны күргән, имеш. Алар морзаны Христос нуры белән нурлаганнар. Шундый могҗизаны күреп тетрәнгән морза изге чукынуны (святое крещениене), Захарий дигән исемне кабул иткән һәм Годуновлар династиясенә нигез салучы булган». Шуннан соң автор Захарий Годунов токымының Алтын Урдадан булуын исбатлый.

Коняев кына түгел, башка галимнәр

---

[2] Явыз Иванның үлеме сәбәбе турында да берничә фараз бар.

дә бу яшь морзаның Үзбәк хан нәселеннән икәнен бәян итәләр. Чукынганнан соң, үз акчасына Ипатьев монастырен салдыруын да раслыйлар. Хан токымы булгач, шик тә юк, бай булгандыр бу чибәр егет. Казан җиреннән ни өчен чыгып качканын да белә тарихчылар: баксаң, ислам динен дәүләт (ханлык) дине итеп игълан иткән әтисе белән ризалашмаган. Ислам таләпләрен дә өнәп бетермәве ачыклана Четнең.

Иван Васильевич Грозныйның бабасы Иван III, аннары атасы патша Василий Өченченең гаилә һәм ирлек (!) хәлләренә борылып карыйк. Бабасы ике мәртәбә өйләнә. Башта беренче хатыныннан Дмитрий исемле улы туа һәм закон буенча әтисе тәхетенә ул утырырга тиеш була. Ләкин, таҗлап өлгерүгә үк, күңеленә ошамаган сыйфат-гадәтләрен табып, аны төрмәгә тыга. Аннары Софья исемле (Иван III анысын Зоя дип йөртә) яңа хатын ала. Анысыннан булачак патша Василий дөньяга килә. Василий да атасы кебек үк ике мәртәбә өйләнә. Беренчесенә өйләнгәнче, язмачлары (писцы) аның кыз сайлаячагы хакында илгә хәбәр тараталар. Хәзергечә сүз йөртсәк, чибәр кызлар конкурсы игълан итү була инде бу... Патшага кәләш булырга өметләнүче 1500 кызны теркиләр. Шулардан Сабурова фамилияле Соломонияне сайлап ала Василий. Сизенәсездер, монысының да татар затыннан икәне бөркелеп тора. Ләкин... 20 ел буе патша кочагында ятса да, бу хатыны бала тапмый. Сабурованы аерып, чәчләрен дә кыркытып, монастырьга тыккач, үзеннән икеләтә яшь кыз ала. Менә хикмәт!.. Монысы да дүрт елдан соң гына балага уза һәм аның да, ягъни Елена Глинскаяның да тамыры Мамай хан нәселеннән икәнлеге мәгълүм.

Иван тугач, Мәскәү күгендә күк күкрәүгә тиң яңа хәбәр дә тарала. Баксаң, Казан ханбикәсе урыслар ягыннан килеп йөрүче чабышчыларга (гонцам) болай дигән: «Сезнең яңа патшагыз ике тешле булып туган икән. Бер теше белән — сезне, икенчесе белән безне ашар инде ул», — дигән. Иван Грозный тугач ук шундый күрәзә кылган Ханбикәнең сизенүен тарихны әз-мәз генә белүче замандашларыбыз да кирегә сукалый алмый.

Ничек кенә булмасын, Елена Глинская белән Василийга Иванның тууы зур шатлык китерә. Василий үз эшләре белән кая гына китмәсен, Еленага Иванның хәлен хәбәр итеп торырга куша. Ә хатыны Ваняның ничек пупылдавына, ничек чырылдавына, елаганда нинди тавышлар чыгаруына кадәр көн саен сөенечле хатлар җибәреп тора. Бер сүз белән генә әйтсәк, алар, үзләрен бәхетле тоеп, тату яшиләр. Ләкин дөнья бу!.. Әҗәл, зур гаделлек белән фәкыйрьләрне дә, хәерче һәм пашаларны да тигез күреп, фани дөньядан мәңгелек кочагына алып китә. Иван Грозный туып өч ел үтүгә үк Василий III дә гүр иясе була... Аннан васыятьнамә калганмы, диешә-диешә, патша йортында ыгы-зыгылар башлана. Андый кәгазь табылмагач, «аның дәүләт билгесе булган скипетрын Иванга калдыруын, ә ул үскәнче Русь белән Елена Глинская идарә итәргә тиешлеген әйтеп үлгәнен» игълан итәләр. Шул ук вакытта Псков елъязмачысы Василий III соңгы әмерен болай язып куйган: *«Он приказа великое княжение сыну своему большому князю Ивану и нарече его сам при своём животе великим князем и приказе его беречи до пятнанацати лет своим боярам неминогим»*. Кыскасы, буталышлар, ризасызлыклар кабат башлана, фетнә-переворот ихтималы да сизелә. Ләкин татар нәселеннән булган Елена Глинская тәвәккәл һәм зирәк хатын икәнлеген күрсәтә, үзәкләштерелгән дәүләт игълан итә, үзенә каршы торучы боярларга үз максатында каты торуын сиздерә.

Шулай да җитәкче даирәләрдә власть өчен чәйнәшләр, гайбәтләр, астыртын үтерешләр туктамый. Шундый реакцион көчләр белән озак көрәшергә сабыры да бетә, сәламәтлеге дә какшый һәм иренең үлеменнән соң биш ел үткәч вафат була. Агулап үтерелгән, дигән версия Русьта гына түгел, дөньяга да тарала. Урыс җирендә агулаулар да табигый хәл. Әнә бит, аның улы Иван Грозныйны да үз табибы агулап үтергән, дигән хәбәр дә бар тарихта… Булыр-булыр… Сүз уңаенда үз үлеме белән үлмәгән патшаларның хәтергә килгәннәрен генә санап үтәм: император Павелны буып үтергәннәр, Александр II шартлатканнар, Николай II гаиләсе-ние белән атканнар, Александр I һәм III, Николай I үлем сәбәпләре әлегә кадәр ачылмаган…

Язмамның төп максатын — явыз Иванның кемлеген аңлатуга ирештем кебек инде. Хәзер аның татарларга кайбер мөнәсәбәтләрен генә әйтәсем калды. Шулай да бу тәмуг кисәве, үзенең татар каныннан яратылганын яхшы белгәндер. Шулай булмаса, үз тирәсенә Мансуров, Бәхтияров, Адашев, Ширәмәтов кебек татар токымындагы затларны җыеп ятмас иде. Үзе чирле башлагач һәм сәламәтлеге физик яктан да, психик җәһәттән дә нык какшавын сизгәч, тәхетенә кайсыдыр урыс боярын яки кардәшен түгел, бәлки Касыйм биләмәсендәге татар ханы — Сөйманбулат (Симеон) Бикбулат улын утыртып калдырган! Ул гына да түгел, дәүләт күләмендәге киңәш-табышларга килгән чакларында Кремль сараенда боярлар белән тигез булып, хәтта тыңлаучан, тыйнак бала кебек утыра да белгән. Әле утыруын да арткы рәтләрдә генә утырган ул һәм «великий Государь Бикбулатович указларын» игътибар белән тыңлаган, хуплап тавыш биргән. Әйе, үз ролен бик шәп башкарган ул. Ә инде икәүдән-икәү генә калгач!.. Әйе, бернинди шаһитлар да юк чакта үзен бәләкәй кеше, «Иванец» кына дип атаган Явыз Иван үз наказларын, боерыкларын шыпырт кына аңлата: кемнәрне асарга яки монастырьга тыгарга, кемне учакта яндырырга, кайсы боярның милкен алып, үзләрен кая куарга, кайсы нәселне корытырга… Мондый максатларын ул «великий князь Всея Руси Симеон Бикбулатович» кулы һәм указлары белән гамәлгә ашыра. Ләкин, кабатлап әйтәм, шунысы хак — тәхетен Татарга ышанып тапшыра! Урыска калдырса, һичшиксез переворот-түнтәрешләр башлана иде Кремльдә. Бәлки әле Явыз Иванның үзен дә беренче очраган агачка асып куйган булырлар иде… Ә күндәм татар хуҗасына тугры калган, елга якын (11 ай) утырган тәхетеннән төшеп, иплe генә булып, чын хуҗасына тапшырган…

Әйе… Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, татар түрәләре Мәскәү Кремлендә берчакта да ризасызлык белдермәгән, өстән нәрсә кушсалар, шуны үтәгәннәр һәм хәзер дә шулай…

Ниһаять, соңгы сүзләрем… Явыз Иван тәмугка күчкәннән соң, татар каныннан яралган Годуновлар арасында кабат сугыш-тарткалашлар башлана. 1584 елдан властьта Романовлар нәселе ныгый башлаган 1613 елга кадәр, ягъни 28 ел дәвамында Русь тәхетендә күп патшалар алышына. Шулардан бары тик Грозныйның улы Фёдор һәм Борис Фёдорович Годунов кына 14 һәм 7 ел утыра алган. Ә алардан соң калган 12 елны алты патша бүлешкән, аларның да өчесе — Ялган Дмитрийлар… ■

СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ ХАКЫНДА

Габделбари Баттал

Инде килик Сөенбикә манарасына. Татарларның үзләрендә һичбер язма әсәр калмаган. Мондый әсәрләр йә Казанны алганда Иван Грозный тарафыннан яндырылып бетерелгәннәр, яки андый тарихи әсәрләр язып угърашучы булмаган.

Казанның гомум тарихын тикшергәндә, рус летописьлары, сказание, рус хөкүмәтенең төрле грамоталарын, рәсми документлар-фәләннәр, рус мөәррихләре тарафыннан язылган тарихи китаплар гына мәнбәгъ[1] ителеп тотылдыгы кеби, татарлардан калган монументлар, гыймарәт вә әсәрләр хакында тикшергәндә һәм башлыча безгә шул ук мәнбәгъләрдән «мәдад[2]» сорарга туры килә. Үз кешеләребез милли тарихыбызны, шул җөмләдән, Казан тарихын да күптән түгел генә тикшерә башладылар. **Шиһаб хәзрәт** бу манара хакында бер җөмлә генә сүз әйтеп киткән, дәлиле-фәләне юк. **Гайнетдин Әхмәров** үзенең «Казан тарихы»нда «Хан мәсҗеде» дигән махсус бер баб язса да, ул хакта төпле тәхкыйк ясамаган, бәлки күбрәк *«Сөенбикә бина кылдырган мәсҗед манарасы имеш», «Бу урында ханнар зираты булып, манара төбендә бер изге адәм дә күмелгән имеш», «Хан мәсҗеден кәнисәгә әйләндереп, аның биек манарасын дошман һөҗүменнән саклану өчен һәрдаим менеп, карап торырга булганлыктан, ватмаенча калдырган имеш»* дигән кебек «имеш-мимеш» хәбәрләр белән кифаяләнгән[3].

Зәки Вәлиди «Төрек вә татар тарихы» дигән әсәрендә Иван Грозныйның Казанны ничек вәйран[4] итүен тәэсир кылган урынында, җәяләр эчендә генә: *«Тик дошманнан сакланып торырга уңай булуын зан итеп, Сөенбикә бина иттергән вә бу көнгә кадәр сәламәт калган манараны калдырды»*, — дип киткән[5]. Әмма манараның «Сөенбикә бина иттергәнлеген, Иван Грозный ул манараны шул максат өчен калдырганлыгын нинди дәлилләргә таянып сөйләгәнлеген әйтмәгән. Әмма «Кыскача төрек-татар тарихы»нда ул манараны телгә дә алмаган.

Сөенбикә хакында махсус рисалә дә язган **Һади Атласов**, ул рисаләдә бу манарага махсус бер баб багышласа да, бу мөәллиф беренче мәнбәгъләрне тикшерү белән мәгърүф кеше булса да, манараның татар әсәре булуын нык исбат итмәгән вә: *«Бу манараның кайчан һәм кем тарафыннан бина ителгән булуында шөбһә юк»*, — дигән дәгъвасына канәгатьләнерлек дәлилләр китерә алмаган; бәлки «алай булырга кирәк» дигән гөманнар[6] белән генә икътифа[7] иткән[8].

Ахыры. Башы журналның 10 нчы санында.

[1] Мәнбәгъ — тарихи чыганак.
[2] Мәдад — ярдәм.
[3] Әхмәрев Г. Казан тарихы. — Казан, 1909. — Б.108-110.
[4] Вәйран — ватык, җимерек.
[5] Вәлиди З. Төрек вә татар тарихы. — Казан, 1912. — Б.259-260.
[6] Гөман — уй, фикер.
[7] Икътифа — канәгатьләнү.
[8] Атласи Һ. Сөенбикә. — Казан: Типо-литография «Өмет», 1914. — Б.61.

Гомумән, безнең соңгы заман мөәррихләре манараның татарлардан калган булуын сабит[9] бернәрсә итеп алганнар, тик аны салуын максат, салучының кем булуы, урыс тарафыннан ни өчен җимерелми калуы хакында гына төрле тәхминатта[10] булынганнар.

Хәлбуки, Казан тарихына мәнбәгъ булган урыс язма әсәрләрендә бу хакта күп ихтилаф[11] бар. Бу манара хакында сүз кузгаткан урыс мосаннифләренең[12] кайберәүләре аның татар әсәре булуын дәгъва кылган хәлдә, бәгъзеләре урыс әсәре булуын исбат итәргә тырышалар.

Ләкин, гомумән, Казан тарихы ни дәрәҗәдә караңгы булса да, ошбу газамәтле[13] манараның да тарихы шул дәрәҗә караңгы. Аның урыс әсәре булуын исбат итү дә уңай бер эш түгел.

Манара хакында мөәррихләр арасында ихтилаф булганлыгы өчен дә хәзер **Археология җәмгыяте әгъзалары**: *«Туктагыз әле, татарлар, ул бит сезнең бабаларыгыздан калган әсәр түгел!»* — дип мәйданга чыгарга батырчылык итә алдылар.

Казан хакында тарих язган һәрбер урыс мөәррихе «Сөенбикә манарасы» татар әсәреме, урыс әсәреме дигән мәсьәләне күтәргән, һәркайсы төрле тәхминнәр[14], предположениеләр (фараз) белән бер якны куәтләгән.

Манараны урыс әсәре диючеләр кайсы урыс патшасы заманында салынуы хакында төрле фаразлар белән угърашалар. Тәхминнәрнең берничәсен бу җирдә күчерәм.

Н.К.Баженов дигән урыс тарихчысы әйтә: *«Бу манара татар әсәре, чөнки ул бөтенләй шәрекъ ысулында ясалган. Янә «Урысларга кальга эченә манара салырга нинди максат булсын?»*[15] дип куя.

М.С.Рыбушкин «Кыскача Казан шәһәре тарихы» дигән китабының беренче басмасында: *«Бу манара хакында ихтилаф булса да, аның татарча аталуы тикмәгә түгелдер[16]», — ди, әмма икенче басмасында «Халык сүзенә караганда, бу манара татар заманыннан калган, әмма безнең фаразыбызга күрә, ул Анна Ивановна заманында салынган[17]»,* — дигәннән соң:

— Стиленә (салыну рәвеше) карап, бу манараны татар хөкүмәте заманына нисбәт бирү мөмкин булса да, Казанны фәтех иткән кеше йортлар гына түгел, мәсҗедләр һәм ханнарның төрбәләрен җимерткән вакытта бу манара гына сәламәт калырга мөмкинме соң? — дигән сөальне биреп, манараның татар әсәре булуын инкяр кылмакчы була[18].

Әмма **М.К.Пинегин**, бер дә икеләнмичә, «Казан электә һәм хәзердә» дигән китабының бер урынында: *«Хәзерге Сөенбикә манарасы — Мөрали [Нургали] мәсҗеде ул[19]»*, — ди. Икенче бер урында: *«Татар ханлыгы заманыннан калган бердәнбер әсәр — Сөенбикә манарасыдыр»*[20], — ди.

Икесенең дә әсәрләре Казанда 1877 елда басылган ике мөәррих бу манара мәсьәләсен биннисбә[21] яхшы тикшергәннәр, ниһаять, икесенең дә манараның татар әсәре булуы фикеренә килгәннәр. Боларның берсе — «Очерки древней Казани» иясе протоиерей **Платон Заринский**, икенчесе — археолог, профессор **С.Шпилевскийдыр**. Болар һәр икесе князь Курбскийның сүзенә

[9] Сабит — шиксез, ачык.
[10] Тәхминат — якынча (уйларда).
[11] Ихтилаф — каршылык.
[12] Мосанниф — китап язучы.
[13] Газамәт — бөек, олы.
[14] Тәхмин — чамалау.
[15] Баженов Н.К. Казанская история. Ч.3. — Казань: Типография университета, 1847. — С.24.
[16] Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. — Казань, 1834. — С.65.
[17] Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. — Казань, 1848. — С.85.
[18] Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. — Казань, 1848. — С.85-86.
[19] Пинегин М.К. Казань в ее прошлом и настоящем. — СПб., 1890. — С.365.
[20] Пинегин М.К. Казань в её прошлом и настоящем. — СПб., 1890. — С.349.
[21] Биннисбә — чагыштырмача.

Фотолар
Абдулла Дубин
архивыннан алынды.

һәм Писцовая книга сүзенә таяналар. Моны лекциянең икенче кыйсемендә күрербез.

Татар әсәре булуын кабул иткән кешеләр арасында манараның ни максат белән салынуы хакында мәсьәлә күтәрелә. Мәгълүмдер ки, татар риваятьләре аны мәсҗед манарасы диләр. Мөәррихләрдән **П.Заринский** да аны *«мәсҗедкә тәгъликле[22] бина»*[23], ди. **Шпилевский** да шуңа маил[24]. Ул әйтә: *«Писцовая книга»да ул манара «мәсҗед» дип йөртелсә дә, фи әлхакыйка[25], Мөрали [Нургали] мәсҗеде булган бина хәзерге Сарай чиркәве булган бина иде»*[26].

Шиһаб хәзрәт «манара» гына дип китә, мәсҗед манарасы булуын әйтми. Гарәпчәдән «манара» русчадагы башня мәгънәсендә булганлыктан, «манара» дигән сүзнең үзеннән генә мәсҗед манарасы булуы аңлашылмый.

Пинегин да манараның мәсҗедкә тәгъликле бина булуы белән бара[27].

Профессор Загоскин манараның мәсҗед манарасы булуына хилаф. Ул әйтә: *«Мөрали [Нургали] мәсҗеденең манарасы булмастыр. Чөнки мөселман архитектурасында бу формада манараларның булуы һич мәгълүм түгел. Бу гыймарәтнең башка бер назначениесе булырга кирәк. Бәлкем ул хан йортының баш капкасы булып хезмәт иткәндер, нитәккем[28] соңыннан «Коммендантский дом»га шунда ук капка булып хезмәт иткән иде»*[29].

Һади әфәнде Атласов бу манара хакында әйтә: *«Бу манара татар телендә «Хан мәсҗеде» аталып йөртелсә дә, вакыйгъда, ул мәсҗед түгел һәм булганы да юк; бу манара үзенең ясалуы һәм тормышы белән, манарадан бигрәк яу килгәнне карар, ушандак[30] дошман өстенә атар өчен ясалган нәрсә булганлыгыны аңланадыр. Чынлап та, Казанда шундый нәрсәләр бар иде»*[31].

Сөенбикә манарасы хакында аерым рисалә язган, мәзкүр Дворцовый чиркәүнең папасы **[поп] Невзоров** манараның мәсҗед манарасы булуына маил[32].

Мөәррихләр бу манара хакында дәхи бер мәсьәлә күтәргәннәр: «Манара бөтене белән татар әсәре яки урыс әсәреме, әллә түбәнге өлеше татар әсәре булып, югары ягы урыс гыймарәтеме?»

Платон Заринский, манараның әсасән[33] татар әсәре булуын кабул итә һәм аның үзгәртелгән булуын мөмкин таба, ошбу сәбәпле әйтә: *«Манарага күз салу белән күрәбез ки, аның түбәнге өч каты, шөбһәсез, борынгы гыймарәттер, ул катлары башка катлардан үтә аерылып тора»*[34].

Профессор Загоскин әйтә: *«Манараның түбәнге дүрт почмаклы өч катының Казан рус кулына керүдән элек салынган булуына күп галәмәтләр бар. Әмма, югарыда сигез кырлы катлары һәм очлы башы соңгырак заманнарда салынган булырга да мөмкин»*[35].

Мәзкүр папас **[поп] Невзоров** рисаләсенең дүртенче битендә: *«Манараның Анна Ивановна заманында салынганлыгы, бу патша заманында крепость эченә комендант йорты салынып, манараның шуңа баш капка булып хезмәт итүеннән генә таралган фикер[36]»*, — дисә дә, 8 нче битендә ул сүзне онытып,

[22] Тәгъликле — бәйле.
[23] Заринский П.Е. Очерки древней Казани. — Казань, 1877. — С.148
[24] Маил — авыш, һәвәсле.
[25] Фи әлхакыйка — чыннан да.
[26] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. — Казань: Типография университета, 1877. — С.472.
[27] Пинегин М.К. Казань в её прошлом и настоящем — СПб., 1890. — С.365.
[28] Нитәкем — ничек, ни рәвешле.
[29] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1805. — С.103.
[30] Ушандак — шулай ук.
[31] Атласи Һ. Сөенбикә. — Казан: Типо-литография «Өмет», 1914. — Б.61-62.
[32] Невзоров П.О. О Сююнбекиной башне. — Казань, 1894. — С.6.
[33] Әсасән — нигездә.
[34] Заринский П.Е. Очерки древней Казани. — Казань, 1877. — С.150.
[35] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1805. — С.103.
[36] Невзоров П. О Сююнбекиной башне. — Ка-

манараның югары дүрт каты шул Анна Ивановна заманында салынганлыгын яклап сөйли[37].

Манара урыс әсәре дигән кешеләренең кайберәүләре (мәсәлән, сабикъ Казан дарелфөнүне профессоры), Казан, Вятка, Оренбург губерналарындагы магул-татар әсәрләрен тикшерүче вә тасвир итүче **Эрдман** аны Иван Грозный заманында иске мәсҗед хәрабәләреннән салынган, диләр. Кайберәүләре Алексей Михайлович заманында, кайберәүләре Анна Ивановна заманында булуын дәгъва кылалар.

Бу манараның Иван Грозный заманында салынуына **Эрдман** бер дәлил китерми. Алексей Михайлович заманында салынуына дәлил итеп менә нәрсәне китерәләр: *«Бу манара белән янәшә торган, гүя манара белән бер нигезгә корылган чиркәүне төзәткәндә, җир астында Михаил Фёдорович һәм Алексей Михайлович падишаһларның акчалары табылган, ул акчалар гүя йорт нигезенә салынганнар»*, — имеш. Анна Ивановна заманында салынганлыгын гөман итү, бу падишаһ заманында манара башында бөркет сурәте куелудан гына килеп чыккан бернәрсә. Аңа башка дәлил юк.

XX гасырга кадәр Сөенбикә манарасының татар әсәре булмавын дәгъва кылган урыс мөәррихләренең кулында һичбер көчле дәлил юк иде. «Урыс падишаһларыннан Фәлән Фәләнеч заманында салынган», — дип әйтәләр дә аны җөзафа[38] гына әйтәләр, игътибар итәрлек һичбер дәлил китерә алмыйлар иде. XX гасырдан элекке мөәррихләр өчен манараның татар әсәре булуын исбат итәр өчен дәлил күбрәк, мохаләф[39] тарафында ул дәлилләргә каршы куярлык адәм рәтле дәлил юк иде. Манараның татар әсәре булуын алга сөргән кешеләрнең бер дәлилләре — манараның стиле — салыну рәвеше иде. Алар: *«Бу манара шәрык стилендә салынган, шунлыктан, татар әсәре булырга кирәк»*, — диләр иде.

Егерменче гасырның беренче елында, ягъни 1901 елда **академик В.Суслов**, шул ук стильгә таянып, манараның урыс әсәре булуын дәгъва итеп мәйданга чыкты. Ул үзенең «Памятники древ[не]русского зодничества» дигән китабында әйтә: *«Сөенбикә манарасы Казан кальгасының төньяк өлешендә тора: аның биеклеге 35 сажинга җитә. Үзе алты катлы, түбәсе нечкә, озын, татар риваятьләре бу манараның салынуын мөстәкыйль Казан падишаһлыгы заманына нисбәт бирәләр вә ул манараны ханбикә Сөенбикә тарафыннан иренең кабере өстенә салынган төрбә манарасы, диләр. Бу манара күп михнәт чиккән, үз ватанының дошман кулына төшүен үз күзе белән күргән патша хатыны, гүзәл Сөенбикә хакындагы легендаларга мөнәсәбәтле булганлыгыннан, аны Казан мөселманнары бик ихтирам итәләр. Шул сәбәптән, күп кешеләр ул манараны татар гыймарәте дип беләләр. Янә аны Мөрали [Нургали] мәсҗеденең манарасы, дип әйтүчеләр дә бар. Татарларның ядкяр өчен салынган гыймарәтләренең стильләре хакында җитәрлек мәгълүмат булмаганлыктан, Сөенбикә манарасының формасын рус архитектура әсәрләре белән чагыштырып, ул манараны XVII гасырдагы рус мигъмарисе әсәрләреннән санарга тиеш буладыр»*[40].

зань: Типография губернского правления, 1894. — С.4.

[37] Невзоров П. О Сююнбекиной башне. — Казань: Типография губернского правления, 1894. — С.8.

[38] Җөзафа — уйламыйча.

[39] Мохаләф — каршылык.

[40] Суслов В.В. Памятники древнего русского зодничества. Издание Императорской Академии художеств. — СПб., 1901. — Выпуск седьмой. — Л.13.

Бу фикердә аңар **Игорь Грабарь** кушыла. Ул үзенең «История русскаго искусства» дигән китабында Мәскәүдәге Боровецкая башняны сөйләгәннән соң, әйтә:

I — Ясалу рәвеше белән Боровецкая башняга ошаган, Казандагы Сөенбикә манарасы, аңа караганда дикъкать беләнрәк эшләнгән, шулай да крепость манаралары типыннан ерак тора, ул күзәтү өчен ясалган манаралар җөмләсеннән[41].

II — В.Суслов аны XVII гасырга нисбәт бирә. Аның татарча «Сөенбикә» дигән исеме, электә Ядкәр хан заманында 14 маналы имән кальганың уртасындагы эч кальгадагы бер борынгы манарага исем булгандыр, ихтимал. Эч кальганың Демидов тарафыннан нәшер ителгән шәркый зәвыктагы хәрабәләре күрсәтәдер ки, ул хәрабәләр белән хәзер мәүҗүд[42] манара арасында һичбер мөнәсәбәт юктыр.

Янә **П.Дульский** дигән казанлы мөәллиф үзенең Казанда 1914 елда басылган «Памятники Каз[анской] старины» дигән китабында мәзкүр Грабарь вә Сусловларның сүзләренә таянып, ягъни манараның стиленә карап, аның урыс әсәре булуын куәтләгән кеби, ул яңа бер дәлил китерә: голландияле Витзенның 1705тә басылган әсәренә өстәлгән Казан манзараларында да ул манара юк, ди. Менә аның бу хактагы сүзләрен укыйм, китабының 17 нче битендә яза:

I — Дикъкать җәлеп итә торган һәм ихтилафлы бер борынгы әсәр Сөенбикә манарасыдыр. Бу әсәрне мигъмари формаларга таянып түгел, бәлки искедән калма авыз риваятьләренә таянып, татар падишаһлыгы дәверенә нисбәт бирәләр. Берничә Казан планын карап, без ул манараны бер планда да тапмадык. Янә Витзенның 1705тә басылган әсәренә өстәлгән манзарасында да бу манара юк. Казан иске әсәрләрен яхшы белүче Н.Агафонов бу хакта түбәндәге сүзләрне яза: «Кремль эчендәге манараның Сөенбикә манарасы дип аталуы — хата, чөнки ул обер комендант йортының капкасы өстенә XVII йөзнең соңгы яртысында гына салынган»[43]. Ихтимал, манараның беренче каты XVII гасырга кадәр иске мәсҗед манарасының кирпечләреннән ясалган бер коббәле[44] капка булып хезмәт иткәндер. Бу манара нигезенең мөселман Казаны заманыннан калган булуы да мөмкин. Әмма икенче каттан башлап киткән бинасы, мотлакан[45], XVII гасырның рус гыймарәте булырга гына мөмкиндер»[46].

II — Архитектура тарихын язучылар Сөенбикә манарасының ясалу рәвешен, Мәскәү гыймарәтләренең ясалу рәвешенә охшаган дип тапканлыкларыннан, ул манараны XVII гасырга нисбәт бирәләр. Сөенбикә манарасының Мәскәүдәге Боровецкая башняга охшавы да аның салыну вакытын ачык күрсәтә.

Менә болар Сөенбикә манарасы хакында төрле тарихи фәнни дәлилләр, каринә[47] вә фаразыяларга таянып, сөйләгән сүзләр, монда кадәр сөйләгән сүзләрдән аңлашылуына күрә, манараның урыс әсәре булуына ошбу дәлилләр бар:

I — Манара Алексей Михайлович заманында салынган, чөнки манара белән бер нигездә салынган Сарай чиркәвен төзәткәндә, җирдән Михаил Фёдорович вә Алексей Михайлович акчалары

[41] Грабарь И.Е. История русскаго искусства. Т.I. Архитектура. Допетровская эпоха. — М., [1910]. — С.324.
[42] Мәүҗүд — реаль.
[43] Агафонов Н.Я. Материалы к вопросу о переименовании улиц г.Казани. Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц. — Казань: Типография губернского правления, 1899. — С.30.
[44] Коббә — гөмбәз, түбәсе түгәрәкләп ябылган бина, корылма.
[45] Мотлакан — шиксез.
[46] Дульский П. Памятники Казанской старины. — Казань, 1914. — С.17.
[47] Каринә — билге.

табылган. Бу акчалар мәзкүр бинаның нигезләренә салынган булсалар кирәк.

II — Манара Анна Ивановна заманында торгызылган, чөнки бу падишаһ заманында салынган комендант йортына манара астыннан кереп-чыгып йөргәннәр.

III — Татар гыймарәтләренең нинди стильдә булганлыклары билгеле түгел, әмма Сөенбикә манарасы Мәскәүдәге Боровецкая башняга бик охшый, бәс[48]*, Казан манарасы да Мәскәү манарасы кебек, XVII гасырдагы рус архитектура әсәре булырга кирәк.*

IV — Сөенбикә манарасы голландияле сәйях[49] *Витзенның 1705тә басылган әсәренә дә өстәлгән Казан манзараларында юк. Бәс, ул манара 1705 нче елдан соң гына торгызылган булырга тиеш.*

Инде без бу дәлилләрне берәм-берәм тикшереп барыйк:

1 — Бу дәлилләрдән берничәсе бик зәгыйфь, бәлки бөтенләй төпсез дәлил. Чөнки Сарай чиркәве мәсҗедтән үзгәртелү сәбәпле, аның Сөенбикә манарасы белән бер нигезгә салынуы мөмкин булса да, җирдән табылган акчаларның Алексей Михайлович заманында салынган яңа биналарның нигезләренә салынган булулары һич лязим[50] түгел. Зирә[51] ки, Сарай чиркәвенең нигезе белән үк яңадан салынмаганлыгы, бәлки иске мәсҗедтән генә үзгәртелгәнлеге сабит[52]. Бу хәлдә мәсҗедтән үзгәртелгән чиркәү тирәсендә табылган акчалар Сөенбикә манарасының салыну вакытын ничек тәгаен итә алсын?

2 — Икенче дәлилнең төпсезлеге аермачык күренеп тора. Сөенбикә манарасының соңыннан салынган комендант йортына капка булуыннан, ул манараның комендант йорты белән бер вакытта салынуы нигә лязим[53] булсын? Сөенбикә манарасы астында әзер капка булган, менә шуны тотканнар да комендант йортына капка ясаганнар. Татар таш биналарының Иван Грозный тарафыннан җимерелмичә, тик назначениеләренең генә үзгәртелгәнлеге профессор **С.М.Шпилевский** сүзеннән мәгълүм булды[54].

Профессор Загоскин әйтүенә бинаән, хан сараеның кайбер палатлары шул комендант йортына кушып җибәрелгәч, Сөенбикә манарасы астындагы ачыклыкның комендант йортына капка булып хезмәт итүе бер дә гаҗәп түгел[55].

3 — Стиль мәсьәләсенә килсәк, югарыда әйтелгәнчә, кайбер урыс мөәррихләре (мәсәлән, **Рыбушкин**) манараның стилен татар әсәре булуына дәлил итеп китерәләр иде. Әмма **академик Суслов** стильне манараның урыс әсәре булуы файдасына хезмәт иттермәкче була. Ләкин аның бу тугърыдагы сүзе бик алай катгый түгел, югарыда күргәнебезчә, ул бу хакта: *«Татар гыймарәтләренең стильләре хакында җитәрлек мәгълүмат булмаганлыгыннан, Сөенбикә манарасының формасын, рус архитектура әсәрләре белән чагыштырып, ул манараны XVII гасырдагы рус мигъмарисе әсәрләреннән санарга тиеш буладыр»*,[56] — дигән иде. Әмма **Грабарь**: *«Ул Мәскәүдәге Боровецкая башняга охшаш»*, — дип өсти.

Манараның татар әсәре булуына башка дәлилләр булып тор-

[48] Бәс — димәк.
[49] Сәйях — сәяхәтче.
[50] Лязим — кирәк.
[51] Зирә — чөнки.
[52] Сабит — шиксез.
[53] Лязим — зарур, кирәк.
[54] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. — Казань: Типография Университета, 1877. — С.473.
[55] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1805. — С.103.
[56] Суслов В.В. Памятники древнего русского зодничества. Издание Императорской Академии художеств. — СПб., 1901. — Выпуск седьмой. — С.13.

ган вакытта *«Татар гыймарәтләренең стильләре ничек булганлыгы мәгълүм түгел, әмма Сөенбикә манарасы Боровецкая башняга охшый»* дип кенә манараның урыс әсәре булуын исбат итү мөмкинме? Әгәр академик җәнаплары татар гыймарәтләренең Сөенбикә манарасы стилендә булмавын исбат кылган булса иде, без аның дәгъвасына, әлбәттә, мөсәлләм[57] булыр идек. Һәрхәлдә, стиль манараның татар әсәре икәнлегенә дәлил була алмаса да, урыс әсәре икәнлегенә дә дәлил булып җитми.

4 — Манараның Витзен манзараларында булмавына килсәк, мин Витзенның китабын күргәнем юк, Казан көтебханәләреннән никадәр эзләсәм дә, таба алмадым. Ләкин аның Казан манзараларын **И.Покровскийның** Казанда 1906 елда басылган «Казанский архиерийский дом» дигән китабында күрдем.[58] Бу китапта Витзен китабындагы Казан манзарасы дәрҗ[59] ителгән[60]. Бу манараларның берсе хәзерге Бишбалта дамбасы ягыннан карап, берсе Казан елгасы ягыннан карап ясалган. Дөрес, бу манараларда Сөенбикә манарасы күренми. Ләкин бу манараларның кем тарафыннан тәрсим[61] ителгәнлеге мәгълүм түгел. Витзенның үзенең Казанга килүе сабит түгел. **И.Покровский** «Каз[анский] арх [иерийский] дом» дигән китапта әйтә: *«Был ли Витзен в Казани или нет, мы не знаем, но достоверно известно, что он посетил берега Каспийского моря...»*[62].

Бу хәлдә Казан шәһәрен Витзенга тәрсим итеп җибәргәндә, мөсәһәләнең[63] булуы яки татарлардан калган әсәргә әһәмият бирмәү тәгассыбының[64] катышуы мөмкин түгелме? Әгәр бу манзаралар бер археологның яки Витзенның үзенең рәһбәрлеге[65] астында тәрсим ителгән булсалар иде, Сөенбикә манарасы, әлбәттә, калмас иде, безгә бит аларның кем тарафыннан тәрсим ителүе мәгълүм түгел, ихтимал, алар бер мөтәгассыйб[66] христиан руханиеның рәһбәрлеге[67] астында тәрсим[68] ителгәндер, ихтимал, монда да «тарихи интерестан башка благочестие (тәкъвалык[69]) зур роль уйнагандыр...».

Дәхи шуны әйтергә кирәктер ки, Витзен китабының һәр ике мәртәбә басылуы Пётр Великий заманына туры килә. Әгәр шул заманнарда Сөенбикә манарасы булмаган булса, аның салынуы йә Беренче Екатерина, йә Пётр Икенче, йә Анна Ивановна заманында яхуд[70] аннан да соңрак була. Кайбер урыс тарихчылар бу падишаһлар арасыннан Анна Ивановнаны яд итәләр[71], әгәр Анна Ивановна заманында салынган булса, бу хәтле газимәтле[72] бинаның салынуы хакында бер-бер рәсми документта, әлбәттә, сүз булмый калмас иде. Хәлбуки, манараның Анна Ивановна заманында салынуын дәгъва кылучылар һичбер андый рәсми документка таянып сөйләмиләр, бәлки төрле фаразлар, предположениеләр буенча гына хөкем итәләр. Шунысы гаҗәп: Комендант йортының Анна Ивановна заманында салынуын кисеп әйтәләр, чөнки аның хакында рәсми кәгазьләрдә сүз бар, әмма шул ук рәсми кәгазьләр гүя комендант йорты белән бергә салынган «Сөенбикә манарасы»н нигә яд итмәделәр икән? Әллә бу манара телгә алмаслык дәрәҗәдә кечкенә вә әһәмиятсез бер гыймарәтме югыйсә? **Озын сүзнең кыскасы: манараның Анна Ивановна заманында салынуына һичбер**

[57] Мөсәлләм — риза.
[58] Бу китапның 12-14 нче битләрендә сызык астында Витзенның үзе вә китабы хакында да беркадәр мәгълүмат бар.
[59] Дәрҗ — теркәү.
[60] Покровский И. Казанский архиерийский дом. — Казань: Центральная типография, 1906. — С.I-II.
[61] Тәрсим — рәсем.
[62] Покровский И. Казанский архиерийский дом. — Казань : Центральная типография, 1906. — С.13.
[63] Мөсәһәлә — әһәмият бирмәү.
[64] Тәгассыб — омтылу, фанатизм.
[65] Рәһбәрлек — җитәкчелек.
[66] Мөтәгассыйб — бер эшкә бирелгән.
[67] Рәһбәр — юл күрсәтүче, башлаучы.
[68] Тәрсим — ясау, сызу.
[69] Тәкъвалык — диндарлык.
[70] Яхуд — яки.
[71] Яд итү — телгә алу.
[72] Газимәт — олы, бөек.

игътибар итәрлек дәлил юк, бәлки тарихларда: «Анна Ивановна заманында ул манара башына кош куелды», — дигән сүз бардыр ки, бу манараның Анна Ивановна заманыннан элек булганлыгын күрсәтәдер. Алай булгач, аннан соңрак салынгандыр? Бу хакта һичбер сүз кузгаткан кеше юк. Пётр Великий заманыннан да элек салынмаган, чөнки шул заманда тәрсим ителгән Витзен китабындагы Казан рәсемендә ул манара юк. Бәлки Пётр Великий белән Анна Ивановна арасында хөкүмәт сөргән Беренче Екатерина яхуд Икенче Пётр заманында салынгандыр? Аңар һәм бер дәлил дә юк, шунлыктан, ул турыда сүз кылган кеше дә юк.

Манараның Витзеннан соң салынуына игътибарга алырлык дәлил булмагач, ул, әлбәттә, Витзеннан элек салынган була. Соң ул Витзен манзараларында нигә юк? Моңа җавап шул:

— Витзен өчен Казан манзаралары тәрсим ителгәндә, Сөенбикә манарасы мөсаһәлә[73] сәбәпле яки дини тәгассыб[74] тәэсире сәбәпле, төшереп калдырылган. Витзеннан элек салынган булса, кайчан салынган? Казанның урыс дәверендә салынганмы, татар дәверендәме? Урыс дәверендә диючеләрнең кайберәүләре Иван Грозный заманында, кайберәүләре Алексей Михайлович заманында салынган, диләр. Дәгъваларның адәм рәтле һичбер дәлилләре булмаганлыгын югарыда күрдек. Инде манараның татар дәвере заманында салыну ихтималы гына каладыр.

Сөенбикә манарасының татар әсәре булуын без мондый «ихтимал»лар-фәләннәргә таянып кына дәгъва кылмыйбыз. Мин лекциямнең беренче кыйсемендә: «Профессор Шпилевский белән протоиерей Платон Заринский манараларның тарихын биннисбә яхшы тикшергәннәр. Ниһаять, һәр икесе манараның татар әсәре булуы фикеренә килгәннәр, икесе дә князь Курбский һәм Писцовая книга сүзенә таянып сөйлиләр», — дигән идем.

Казанны алган вакытта Иван Грозныйның команданларыннан берсе булган князьнең Казанны алу хакында язган сказаниесе бар. Казан кальгасына һөҗүм вакытында **Курбский** 12 мең гаскәр белән Казан елгасы буендагы хәзерге Гривка бистәсе янында торган вә шул яктан һөҗүм кылган. Менә шул хакта ул әйтә:

— Унике мең гаскәрне маһир[75] сәргаскәрләр[76] командасы астында хәзерләп, шәһәр диварлары һәм капка алдында тау башында торган олуг манара (башня) янына якынлаштырдык.

Икенче бер урында **Курбский**: «*Шәһәр бик нык иде. Аның таш пулатлары, таш мәсҗедләре биек дивар белән ихата кылынганнар иде*», — ди. Икенче бер урында болай ди:

— Казан елгасыннан караганда, тау шундый биектер ки, хәтта карап күз җитмәслек, шул тау өстендә кальга. Падишаһ сарайлары вә гаять биек таш мәсҗедләр тора.

Шулай дия торып та, аның «теге тау башында, капка алдында торган «олуг манара янына», дип әйтүе тикмәгә түгел, әлбәттә. «Гаять биек» дип тәүсыйф[77] ителгән мәсҗедләр, пулатлардан башка тау башында торган, аерып әйтер дәрәҗәдә зур вә биек манараның булуы безнең файдабызга көчле дәлил түгелме? Князь Курбский кебек Казанны үзе алышкан, күргән нәрсәләрен бик дикъкать белән язган мөәллифнең сүзе аннан

[73] Мөсаһәлә — игътибар итмәү, әһәмият бирмәү.
[74] Тәгассыб — фанатизм.
[75] Маһир — оста.
[76] Сәргаскәр — гаскәр башлыгы.
[77] Тәүсыйф — сыйфатлау.

соңгы мөтәгассыйб урыс мөәллифләренең мең, миллион фаразлар, предложениеләреннән дә көчлерәктер, янә Писцовая книгада хәзерге Сөенбикә манарасының Мөрали [Нургали] мәсҗеденең манарасы булуына ишарә бар, менә шул дәлилләргә, бигрәк князь Курбский хәбәренә таянып, **Платон Заринский** әйтә:

— Всё это доказывает существование в татарской Казани высокого минарета или башни. Очень может быть, что эта башня неправильно носит название Сююнбекиной башни, очень может быть, что её форма изменена, но о пренадлежности её к старинной мечети едва-ли может быть сомнение.[78]

Тәрҗемәсе: «Бу дәлилләрнең һәммәсе күрсәтәдер ки, татар Казанында биек бер мәсҗед манарасы яки гади манара булган икән. Ихтимал, аның «Сөенбикә манарасы» дип аталуы хатадыр, ихтимал, аның шәкеле үзгәртелгәндер, ләкин аның бер мәсҗедкә тәгъликлы бина булуына шөбһә юктыр».

Профессор Шпилевский Рыбушкинның: *«Мәсҗедләрне, хан каберләрен җимереп ташлаган Иван Грозный бу манараны ничек бөтен калдырсын?»*[79] дигән бәхәсенә каршы болай җавап бирә:

— Бу бәхәснең әһәмияте юк, чөнки Писцовая книга берничә татар пулаты һәм бер-ике мәсҗеднең калганлыгын күрсәтә. Татар таш биналары җимерелмәгәннәр, бәлки алар башка максатлар өчен генә кулланыла башлаганнар. Мәсәлән, Мөрали [Нургали] мәсҗеде чиркәүгә әйләндерелгән вә һөкәза[80] *манараның татар әсәре булуына иң зур дәлил — борын-борыннан, буынбуынга күчерелеп килгән авыз риваятьләредер. Бу манара татарлар арасында иске-искедән бирле «хан мәсҗеде» дип аталып килгән. Татарлар аны мөкатдәс бер бина итеп саныйлар, аның янына барып, борынгы заманнарны сагыналар*[81]. *Әдип Фатыйх Әмирхан тәгъбиренчә: «Сөенбикә кызлары аның янына килеп, Ходайга гыйбадәт итәләр, истимдад*[82] *итәләр, тынычсызлыклар, тормышның фаҗигаләреннән шикаять итәләр, тулган күңелләрен елап бушаталар, җылы күз яшьләре белән баһадирның кызыл итәкләрен чылатып юаныч табалар иде».*

Бу риваятьләр, әлбәттә, Казан алынган көннән, ягъни XVI гасырның яртысыннан бирле авыздан-авызга күчерелеп килгәндер. Шулай булгач, бу риваятьләрне, бу игътикадларны илтифатсыз калдыру ярыймы? Аслан[83] ярамый. Шунлыктан **профессор Шпилевский** әйтә: *«Бу манараның татар әсәре булуына мөһим дәлил, бу хактагы татар риваятьләредер. Чөнки татарларның үз күз алларында салынган урыс манарасын үзләренеке дип дәгъва итүләре, аңа тәкъдис*[84] *күзе белән караулары аслан ихтимал тотмыйдыр».* **Папас [поп] Невзоров** та үзенең югарыда мәзкүр рисаләсендә шул ук сүзләрне тәкрарлый. Әмма **профессор Загоскин** болай ди:

— Безнең кулыбызда татар риваятьләре бардыр ки, алар бик мантыйкый иттереп Сөенбикә манарасын мөстәкыйль Казан падишаһлыгы заманына нисбәт бирәләр. Бу манараны Казан мөселманнары бик ихтирам итәләр. Бу манараның төбендә догага тезләнгән татарларны еш-еш күрергә туры килә. Урыс әсәре булган бинага шундый ихтирамлы мөнәсәбәтнең бу-

[78] Заринский П. Очерки древней Казани. — Казан: Губернская типография, 1877. — С.149.
[79] Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. — Казань, 1848. — С. 85-86.
[80] Һөкәза — бу сурәттә.
[81] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. — Казань: Типография Университета, 1877. — С.473.
[82] Истимдад — ярдәм сорау.
[83] Аслан — беркайчан да.
[84] Тәкъдис — изге дип ышану.

луы һич мөмкинме? Бик ачык күренә ки, бу хактагы татар риваятьләре бик иске һәм җитди әсасларга корылганнар.

Бу риваятьләргә яхшы гына мөнәкъкыйд[85] мөәррих **Шиһаб хәзрәт** тә зур әһәмият биргән. Чөнки ул икенче кыйсем «Мөстафадел әхбар»ының башында, дәлил-фәлән китермәстән туп-туры: *«Бу заманыбызда кадим мөселманнардан калган әсәрдән бер манараны, мөселманнар Хан мәсҗеде дип, руслар Сөенбикә манарасы дип тәсмия[86] итәләр»*[87], — ди. Әгәр ул авыз риваятьләренә зур әһәмият бирмәгән булса, халык хәтере өчен генә аны «кадим мөселманнардан калган манара», димәс иде. Ул бит «дәлил юк» дип, хәтта мәсҗед манараларындагы айның дини эмблема булуын да инкяр кылган. Шуны «Мөкаддимә вафиятель әсляф» дигән китабында язудан да курыкмаган иде[88].

Дәхи бер мәсьәлә — Сөенбикә манарасы таштан салынган. Татар Казанында таш биналар булганмы соң? Ихтимал, шәһәрнең коймасы агачтан булган шикелле, андагы биналар да гел агачтан булгандыр? Юк, шәһәрдә зур таш биналар, таш манаралар булган, Иван Грозный белән бергә Казанны алышкан **князь Курбский** әйтә:

— *Казан елгасыннан караганда, тау шундый биектер ки, хәтта күз җитмәслек шул тау өстендә кальга, падишаһ сарайлары вә гаять биек таш мәсҗедләр тора, андый мәсҗедләр бишәү. Ул мәсҗедләргә үлгән ханнарын күмәләр*[89].

Профессор Загоскин әйтә: *«XVI йөзнең өченче чирегендә тәртип ителгән Казан Писцовая книгасында бер хан сарае яд ителә. Бу книга тәртип ителгәндә, ул сарайның аерым-аерым пулатлары хәрби складка әйләндерелгән булган. XVII гасырда шул иске сарайның кайбер өлешләре, шунда торгызылган «Комендант йорты» дигән бинага кушылган*[90].

Профессор Фукс: *«1807 нче елда Казандагы крепость эчендәге хан сараен җимерделәр»*[91], — ди. **Профессор Загоскин** әйтүенчә: *«Комендант йортының тузган диварлары 1845 нче елда хәзерге губернатор сараен салган чакта җимереп алынган. «Комендант йорты» шул хан сараен һәм эченә алганлыгыннан, бу хан сараеның калдыклары XIX гасырның 40 нчы елларында туздырылган буладыр»*[92].

Протиерей Заринский яза:

— *Хан сарае, шәһри Болгардагы шикелле, берничә таш пулаттан гыйбарәт иде, ул пулатлар избизле [известьле] таштан вә кирпечтән салынганнар иде*[93].

НӘТИҖӘ: менә ошбу лекциядә сөйләнгән сүзләрдән соң мин:

— СӨЕНБИКӘ МАНАРАСЫ КАЗАННЫ ИВАН ГРОЗНЫЙ АЛГАННАН СОҢРА САЛЫНМАГАН, УЛ УРЫС ӘСӘРЕ ТҮГЕЛ, БӘЛКИ УЛ, КАЗАН МӨСТӘКЫЙЛЬ ПАДИШАҺЛЫК БУЛГАН ЗАМАНДА САЛЫНГАН ТАТАР ӘСӘРЕ, дигән нәтиҗәне чыгарамын.

Бетте.

Казан, 1917 ел

Текстны һәм искәрмәләрне басмага
***Җәүдәт Миңнуллин** һәм **Энҗе Сабирова** әзерләде.* ■

[85] Мөнәъкыйд — тәнкыйть итүче.
[86] Тәсмия — исем бирү.
[87] Мәрҗани Ш. Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. — Казан: Университет басмаханәсе, 1900. — Б.3.
[88] Мәрҗани Ш. Мөкаддимә вафиятель әсляф… — Казан: Вячеслав матбагасы, 1883.
[89] Курбский А.М. История о великом князе Московском // Извлечено из «Сочинений князя Курбского». — СПб., 1913. — С.21.
[90] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1805. — С.99.
[91] Фукс К. История города Казани. — Казань, 1899. — С.1.
[92] Загоскин Н.П. Спутник по Казани . — Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1805. — С.99.
[93] Заринский П.Е. Очерки по древней Казани. — Казань, 1877. — С.145.

ТӨНЬЯК ТӨРКИЛӘРДӘ ТӨРКИЧЕЛЕКНЕҢ ТӘҮГЕ АВАЗЫ. ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ

Йосыф Акчура

1885 елда төньяк төркиләренең мәркәзе Казан шәһәрендә миллият фикеренең тарих һәм этнография өлкәсендә мәйданга чыгуын күрәбез. Шуңарчы үзләрен мөселман дип кенә хисаплаган, аңсыз рәвештә генә сөйләм телләрен төрек (төрки) тел дип йөрткән Казан халкы арасында яңалык сөяр галим Шиһабетдин Мәрҗани «Китабе мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтен бастыра.

Төрки телдә язган бу әсәрендә Казан мөселманнары барлыгын милли тел ноктасыннан, катгый һәм ачык бер рәвештә хәтергә сала, мәйданга игълан итә. «Китабе мөстафадел әхбар»ның бу хактагы мәшһүр җөмләләре: «Кайберәүләр татар булуны кимчелек дип санийлар, ул исемнән нәфрәтләнеп: «Без татар түгел, мөселманбыз!» — дип татарлыктан чигенәләр, аңа каршы торалар. Әй, мескен! Татар булмасаң, гарәп йә таҗик, йә нугай түгел; кытай йә урыс, йә әфган, йә прус, йә нимсә хәтта түгел! Инде кем булырсың?!» (Китабы Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар, 1885. Т.1. — Б.6.) Шиһабетдин хәзрәтнең милләтенә бу ачулы мөрәҗәгате казанлыларның үз тарихларына, үз нәсел һәм кабиләләренә кыйммәт һәм әһәмият бирмәүләренә ризасызлыктан туган. «Инсаннарның һичбер заман вакыйгаларын һәм маҗараларын теркәмәүләре сәбәпле, дөньякүләм галим, хөкемдар һәм бөек фикер ияләре кебек бабаларыбыз, аталарыбыз, агаларыбыз халкыбыз белә алмаслык билгесезлек пәрдәсе астында калган. Казан һәм Болгар хәлләрендә «Шәһре болгар әүлияләре», йә «Газизләр кабере», «Хан мәчете», «Хан заманындагы эш» дигән әйтемнәрдән башка һичбер нәрсә белмиләр. Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлау дәрәҗәсенә ирешә алмыйлар. Үз кабиләләреннән никадәр хөкемдарлар килеп кичкәне турында хәбәрләре юк». Кирәк югарыдагы мөрәҗәгате, кирәк шул хакыйкатьне ачыклавы авторның милли аң иясе икәнен ачык искәртә. Дунай болгарларының милләтпәрвәр тарихчысы Паисий[1] 1762 елда язган «Славян һәм Болгар тарихы» исемле әсәрендә болгарларны үз исеменнән киткәннәрне өчен ачы сүзләр белән суктыра. Аларга: «Бу ахмаклар ни өчен үз милләтләреннән чигенәләр? Ни өчен «болгар» дигән исемегездән оялысыз һәм грекларның (румнарның) мәкерле сәясәтләренә буйсынасыз?» — дип мөрәҗәгать итә. (Болгарстанда туранизм фикере // Төрек йорты — 1915. — №16. — Б.450.) «Әхвали Казан вә Болгар»ны язучы белән «Славян һәм Болгар тарихы»н язучы, йөз еллар үткән аралыкта үз халыкларына бер үк шелтә белән мөрәҗәгать итәләр. Милләтләрендә аң һәм милли тойгы уятырга тырышулары очраклы охшашлык кынамы? Юкса, Шиһаб хәзрәт рус телендә Паисий әсәрен укыдымы икән? Бу мәсьәләне Шиһаб

[1]Паисий Хилендарский (1722-1773) — болгар мәгърифәтчесе, рухани, тарихчы.

хәзрәтнең биографиясен һәм әсәрләрен нечкәләп, тирәнтен тикшерүче Казан галимнәре хәл итсен.

Шиһаб хәзрәтнең тарихи һәм күпмедер дәрәҗәдә сәяси миллиятчелеге «бөтентөрек» фикеренә кадәр үк формалашкан. Төньяк төркиләреннән булган хәзрәтнең казанлыларны кырыс катгыйлыкта һәм ачык рәвештә «татар» шәкелендә исемләве — шуның ачык бер галәмәте. Ш.Мәрҗани әсәрләрен мин нечкәләп тикшермәдем. Бу фикерләрем риваять хәлендәге мәгълүматларга һәм хәзрәтнең тууына 100 ел тулу уңаеннан Казанда басылган «Мәрҗани мәҗмугасы» исемле китапка нигезләнә. Әлеге 639 битле җитди һәм кыйммәтле китап махсус комиссия тарафыннан басмага әзерләнгән һәм Салих бине Сабит Гобәйдуллин тарафыннан Казанда «Мәгариф» матбагасында басылган (1915).

Шиһаб хәзрәтне милләтпәрвәрлек тәэсирендә төрки теле һәм әдәбияты белән җитди мәшгуль булды, дип тә әйтә алмыйбыз. Дөресен әйткәндә, хәзрәтнең хосуси сөхбәтләрдә: «Сүз арасына рус сүзләрен кыстырмау, мөмкин булган кадәр үз телеңне сакларга тырышу кебек киңәшләрен Шәһәр Шәрәф әфәнде сүзләре буенча гына беләбез» («Мәрҗани», 126-127 б.) Дөрес, бу риваятьнең чынлыгына шикләнер сәбәп юк. Төньяк төрки галимнәре һәм фикер ияләре, үз халкын урыс ассимиляциясеннән саклар өчен бу чараны һәрчак тәкъдим итәләр. Рус теленең көчле тәэсиреннән төньяк төркичәсен сакларга теләгән Мәрҗани язмаларында үз телен көнчыгыш гарәп һәм фарсы телләре хәвефеннән саклау тенденциясе күренми. «Төрекчә (төркичә) яздым», — дигән әсәрләрендә, мәсәлән, «Мөстафадел әхбар»да Мәрҗани гарәп һәм фарсы сүзләрен шыплап тутырган. Ш.Мәрҗанинең бу өслүбе бәлки Бохарада озак яшәве һәм формалашуы нәтиҗәседер, чыгатай теле чикләрендә калуыннандыр. Төрки телгә игътибарсызлыгы шул чакларда ук кайбер тәнкыйтьчеләрнең, шул җөмләдән, төньяк төркичәсен гыйлем һәм әдәбият теленә әйләндерү өстендә эшләгән Каюм Насыйриның да урынлы тәнкыйтенә юлыга.

Шулай булса да, әлеге заманга кадәр бөтен ислам галәмендә куәтле бер традициягә әйләндерелгән — гыйльми һәм җитди әсәрләрне гарәп телендә язу шартларында «Мөстафел әхбар»ны төрки телдә язуы һәм дусларыннан Хөсәен әфәнде Фәезхан улының татар грамматикасына багышланган әсәрен югары бәяләве Мәрҗанидә милли тел кыйммәтенә кызыксыну булганын күрсәтә. Галим Казанда рус-татар укытучылар мәктәбенең мөдире, мәшһүр шәркыятьче Радловның дусты һәм шул укытучылар мәктәбендә илаһият укытучысы иде. Мәрҗани Радлов аша борынгы рус тарихы белән һәм этнография галимнәре белән танышты. Аның Радловның төрек-татар теле һәм шивәләре хакындагы тикшеренүләре һәм фикереннән хәбәрсез калуы мөмкин түгел. Мәрҗанинең Европа галиме белән якынлашуы дөньяга карашын киңәйтә, эшләү ысулын заманлаштыра дисәк, хата булмас. Төньяк төркиләрендә милләтчелек идеологиясен формалаштыруда «Тәрҗеман» газетасыннан соң милләткә хезмәт иткән икенче әсәр «Мөстафадел әхбар» булган. Шиһабетдиннең милләттәшләренә ачулы мөрәҗәгатьләре чүлдә ялгыз кычкыру гына булып калмады. Шәкертләре остазның дини сабакларын гына түгел, тарихи хезмәтләренә таянып милләтпәрвәрлеген дә дәвам иттерделәр һәм үстерделәр. Шул рәвешчә, XIX гасырның соңгы чирегендә төньяк төркиләрендә дә милләтчелек, төркилек фикере башланганын күрәбез.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

МИШӘРЛӘР*

Зариф Бәшири

6 КЫЗЛАРЫ, ХАТЫННАРЫ ВӘ ИСКЕ ГАДӘТЛӘРЕ

Кыргыз, чуаш вә мишәр кеби кавемләрне гадәт вә әхлак, төс вә табигать җәһәтләреннән бәхетле итәргә теләнелсә, иң кулай юл да аларның хатын вә кызлары әхвәленнән бәхетле булулары, дип уйлыйм. Аның өчен хәзерендә бу кавемнәргә башка кавемләрнең каты катнашмавын искә алганда, боларның хатын вә кызлары бөтенләй диярлек укымаган вә читләргә гадәт алырлык дәрәҗәдә катнашмаганлыктан, иске гадәт, табигать вә төсләре башкармаган вә үзгәрелмәгәндер.

Хатын вә кызларда булган иске табигать, холыклардан начарларының үзгәрүе өчен, мәсәлән: каты вә тупас, җанга салкын вә ачулы табигатьле

Мишәр хатыннары балалары белән. XX йөз башы

*Дәвамы. Башы журналның 10 нчы санында.

булган бер хатын яки кызның холкы нәзакәт вә хиссиятлелек, хиссият вә җазибәлелек (үзенә тартучы, үзенә каратучы), мөлаем вә йомшак табигатьлелек кеби сыйфатларга алышынуы өчен, әлбәттә, укуы вә төрле милләтләргә катнашып үзендә булган кимчелекне күрүе вә барыннан бигрәк иреклe, азат вә хокуклы булуы тиештер.

Мишәр хатын вә кызлары исә бу хәлгә килгәндә, хәтта кыргыз вә чуаш хатыннарына караганда да тәмамән иске хәлләрендә булып, уку, хөррәлек вә үзләрендә беркадәр хокук саклау кебиләрдән бөтенләй гарипдерләр. Шуның өчен дә аларның хәрәкәт вә төсләренә карау белән дә искелекне нык саклаганлыкларын вә җуймаганлыкларын ачык белергә буладыр. Затән һәрбер милләт вә һәр кавемнең иске гадәтләрен саклау тугърысында иң нык гайрәт вә көч сарыф кылучылары хатыннар таифәседер. Кыскасы, иске гадәтләрнең нык таянычлары хатыннар димәк мөмкиндер. Моның өчен тарих сәхифәләрен актару вә хосусән Рәсүл Әкрәм әфәндебезгә каршылык иткән һәр кабиләнең башында иске гадәтләрнең югалуыннан куркыган хатыннары Исламнан куркып вә өркеп йөргәнлекләрен күз алдына китерү бөек бер дәлил була алыр.

Чуаш кыз вә хатыннары кияүгә баруда вә мәгыйшәт юлларында үз ихтыярларын саклый алганнар. Мишәр кызхатыннары гадәттә аталарының сатлык хайваннары, кияүләренең бәхетсез уенчыкларыдыр. Алар бу хәлләрне үзләре өчен җәбер вә мәгыйшәтләре өчен куркынычлы бер гадәт дип тә белмиләр вә уйламыйлар.

Мишәр кызлары аталарының биргән, хакыйкый хәленчә әйтсәк — саткан егетенә һич сыкранмый вә кайгырмый барырга әзердерләр. Чөнки алар: «Кияүгә бару нәрсә? Нинди кияү белән торганда матур мәгыйшәт була?» — дип уйламыйлар да, уйласалар да, тик:

Мишәр кызлары аталарының биргән, хакыйкый хәленчә әйтсәк – саткан егетенә һич сыкранмый вә кайгырмый барырга әзердерләр.

«Хатыннар кияүнең бала уенчыгы вә колы мисалында булган бер нәрсәсе вә аның һәр әмеренә буйсынучы вә һәр төрле җәбер вә кабахәтлекләренә түзүбезгә тиеш», — диеп кенә уйлыйлар да, кияүгә китүне бер гадәт кенә, нинди кияү булса да бара һәм аның һәртөрле залименә вә әмеренә түзә һәм чыдыйдыр. Бу хакда мишәр кызларының авызларында: «Мин — алучыга баручы, куучыдан — китүче», — дигән бер мәкаль дә һәрвакытта сөйләнә вә тәкрарланадыр.

Мишәр кызларында гыйшык вә мәхәббәт дигән нәрсә дә юк диярлек. Матур гына әйткәндә: **«Мишәр кызы артык сөйми дә вә сөелми дә»**. Чөнки сөю вә сөелү өчен иң беренче шарт — нечкә хиссиятле, нәзакәт вә җазибәле булудыр. Болар исә мишәр кызларында бөтенләй юктыр вә аеруча укымаган да булса, «мишәр кызы» дию урынына, «җанлы бер күсәк», дип әйтергә дә мөмкиндер. Моннан башка азатлылык вә хокуклылык җәһәтендә мишәр кызлары кыргыз кызларына караганда да түбән хәлдәдер. Кыргыз кызлары исә аз булса да беркадәр хокуклы вә иреклe булу белән бергә гаять дәрәҗәдә үткен кыланышлы вә җазибә буладыр.

Мишәр хатыннары вә кызлары, бердән шушы хәлдә булулары вә, икенчедән, ирләренең гаять көнче табигатьле булулары сәбәпле, гаять дәрәҗәдә гыйффәтле вә саф күңелле булалар, шәһвәт (җенси дәрт, теләк) пәрәстлекдән ерак торалар. Чөнки мишәрләрнең ирләре хатыннары хакында соң дәрәҗәдә көнче вә начар уй, явыз фикердә торучы табигатьледерләр. Әгәр бер кызның яхуд бер хатынның гыйффәте хакында

тузан кадәрле генә бер гаебе беленсә дә, бөтен халык телендә ул хурлау, мыскыл итү белән сөйләнә, атасы вә яңа кияү алдында кыйнау вә сугу кеби газаплар белән бәлаләнәдер. Бер кыз яки хатын ят бер ир белән берәр генә сүз алыштырса да авыл әллә никадәр исемнәр күтәрә вә гыйффәтсезләр җөмләсеннән саналадыр. Менә шушы сәбәпләргә күрә дә мишәр кызларының түгел гыйффәтеннән язганы, бәлки дә беркадәр шаярганы да меңгә бер генә сөйләнә вә ишетеләдер.

Бу урында шуны да аңлатып китүне тиеш саныйм: мишәр кызларының мондый гыйффәтле булулары ирләреннән куркып вә яман исемнән өркеп кенә түгел, бәлки **алар борынгы заманнан гыйффәтле булып яралалар вә туалар, гыйффәтле булып үләләр**.

Мишәр кызлары, бердән, бастырынкы күңелле вә артык шәһвәт пәрәст булмаганлыктан, кияүнең төс вә матурлыкларына артык игътибар кылмаганлыкларыннан, вә икенчедән, киләчәк мәгыйшәт вә рәхәтлекләрен уйлый алырлык дәрәҗәдә тәрбияләнгән бер гакылга ия булмаганнарыннан, кияүне дә сайлап тора алмыйлар. Фәкать шунысы шаян дикъкатьтер ки: бер мишәр кызы никах мәсьәләсен аңларлык дәрәҗәгә килсә яхуд фикере ачылырлык дәрәҗәдә укыса, ул ничек кенә булса да үзе теләгән егеткә бара ала. Иң әүвәл атасы вә анасына өзеп кенә әйтә, алай да булмасаябышып чыгып китә дә егет белән үзләре никах ясаталар. Нигездә, **мишәр кызлары, һәр эшләренең аңлаган вә шулай дип белгән кадәресен, һәртөрле киртәләргә күкрәк киереп вә батыр күңеллелек белән аның чынлап барлыкка килүенә җөрьәт итә алалар**. Әмма аларга җәһаләт (наданлык, аңбелемсезлек) ныклап урынлашкан. Бу урында шуны да яшермәүне тиеш күрәмен ки: бу көндә төрле шәһәрләргә сәүдә өчен таралган мишәрләрнең кызлары һәрбере укыган вә хәтта күбесе бөек мәктәпләрдә йетешкән була вә йетешәдер. Аңлаган эшне юлда калдырмаучы вә бигрәк тә берәүдәге яхшы якларны күреп үзләрендә дә шуны булдырырыга теләүче вә тәкълидче (ияручe) мишәрләр монда да тәкълидсез (башкага иярмичә) чыдый алмаслар.

Киемнәре җәһәтенә килсәк, кызларының күлмәкләре киң вә озынлыкта уртача булып, фәкать ике катлы зурзур итәкләре генә кушылган, бергә җыелган буладыр. Бер итәге билдән башлап тубыкка кадәрле вә икенче итәге күкрәк астыннан башлап тез өстенә кадәрле төшкән буладыр. Изүләре бәгъзе бизәксез вә бәгъзе чуаш хатыннарыныкы кеби мич капкачы рәвешендә боргалап-боргалап төрлечә ситсылардан бизәп ясаган буладыр. Башларына чуаш кызларыныкы кеби кечкенә шәл яки яулыкны кыекчан урталай катлыйлар да, бер кыегын артка салындырып бәйлиләр.

Хатынлык галәменә чыккач, бөтен киемнәре үзгәреп, тәмам чуаш хатыннарына охшап калалар. Күлмәкләре бары беркадәр киңлек җәһәтеннән генә чуаш хатыннарыныкыннан аерыладыр. Башларына «тастар» бәйлиләр. Әмма боларның тастарлары чуаш хатыннарыныкы кеби гади чүпрәкләрдән генә булмыйча, артка салынган койрыгы алтынлы алкалар вә чуклар белән бизәлеп, иң ярлысыныкы да 15, йә 20 сумнарга төшәдер. Бер мишәр кызының кияүгә алып бара торган иң кадерле вә мөһим бер приданый-иярчене дә — сөекле тастарыдыр. Кияүгә китәр вакытын сизә башлады исә барлык иҗтиһад вә әрсезлеген сарыф кылып, тастар хәзерли башлыйдыр. Сүз арасында «фәләннең кызы буйга җитеп килә инде» урынына «тастар әзерли инде» тәгъбирен йөртәләр. Фәкать бу тастарлар төрлечә булып, һәрьяк мишәрләренең үзләренә махсус буладыр. Мәсәлән, саратский мишәр хатыннарының маңгайларына да бер

кадәр койрык салынып, итәгенә көмеш тәңкәләр тезелгән, Пенза вә Тамбов мишәрләре дә, тәмам чуаш хатыннарыныкы ысулынча, баш өстенә бер кечкенә матур гына шәл ишеп бәйләгән вә шәлнең ике кыегын югарыга таба күтәртеп куйган буладыр. Тау як мишәрләренең исә фәкать киң вә озын яхуд ак киндерләрдән генә тегелгән булып, хатыннарының алдын вә артын, кулларын вә аяк башларын тәмам каплап алган һәм баеракларында маңгай өстендә көмеш укадан тегеп ясалган бер катыргы да була вә бу катыргының чуклары күз кашларына кадәрле салынып йөри. Бу мәукыш (мордва) хатыннарында да булып, аларның маңгайдан югары булган кисәге гади тактадан гына буладыр. Моңа болар да «тастар» ди. Тау як мишәр хатыннары исә «чалма» якә «үрпәк» исемнәре илә йөртәләр.

Асылда «тастар» сүзе дә фарсыча «чалма» мәгънәсендә булган «дастар» сүзендән алынган булса кирәк.

Мишәр хатыннарының күлмәк өстеннән кия торган өч билле, ачык түгәрәк якалы, чабу вә итәкләренә ак вә сары чуклар яхуд төрле төстә саташ вә ситсылар тоткан камзуллары да буладыр. Кызлары вә хатыннары гомумән кулларына беләзек вә ишмә[1], аякларына үзләре бәйләгән оек һәм дә бәйрәмнәрдә кызыл вә яшел төсләрдә читек кияләр. Сачләренә чулпы вә төрлечә саташлар тагалар. Бармакларына зур-зур кашлы йөзекләр, муеннарына хәситәләр кияләр. Күзгә сөрмә тартудан башка, битләренә кершән вә иннек, тешләренә «теш карасы», тырнакларына «кына» ягынмак кеби нәрсәләр боларда бик модададыр. Бу вакыт мишәрләрнең яшьрәк хатын-кызларына казан хатыннарының иң иске модаларыннан булган зур итәкләр өстенә куштан итәкләр салу, зур калфаклар вә карташилар да кирә башлады. Боларны да читдә йөргән ирләре генә алып кайтып тараттылар. Ләкин мишәр хатын-кызлары гомумият илә бизәнү вә киенү эшенә гаять һәвәскәр. Затән, алар дөньяга килә, һичбер нәрсәдән хәбәре вә белеме булмаган ана кулында һичбер нәрсәне кирәксенми, агач кеби фәкать җөссәсен (гәүдәсен) өстерәп буйга җитә, кияүгә бара, мәгыйшәт мәшәкатьләрендә ирләренә тузан кадәре дә ярдәм итми, иренең тапканын ашау белән картая. Менә шушы дәверләрендә киенү вә бизәнүдән башканы күрми вә белми дөньядан да кичәләр. Чөнки мишәр хатыннары йорт тәрбиясе вә кул эше кебиләрне гүзәлчә белүдән гаять дәрәҗәдә мәхрүмнәрдер. Ашамлык-тәгамнәр пешерүдә, түгел тәкәллифле ашларны, бәлки дә гади вә көндәлек ашларны да соң дәрәҗәдә татсыз вә иштиһага (теләккә) мохалиф (каршы) яраксыз итеп пешерәләр.

Хатынлык галәменә чыккач, бөтен киемнәре үзгәреп, тәмам чуаш хатыннарына охшап калалар.

Беркадәр җөйләгән эч киемләре дә тик өстеннән шуып төшмәслек дәрәҗәдә генә буладыр. Күзгә күренерлек беркадәр һөнәрләре дә: урак ура белә вә арыш суга белү. Өй эшеннән пичкә ягып сыер саву, санаигы нәфисәдән (нәфис сәнгать) беркадәр житен вә сүс җепләре белән ашъяулык, сөлге вә киявенә күлмәклекләр өчен алачалар тукудыр. Элек бу бик куәтле булып, гаҗәеп дәрәҗәдә нәфис эшне белсәләр дә, хәзер төн-көн түбәнлеккә йөз тотмактадыр.

«Гакыллыга бер ашар җитәр, диләр» мәкаленә бармагымны төртеп,

[3] Ишмә исә, бакыр чыбык өстенә нечкә генә көмеш чыбыкны чорнап, беләккә кияр өчен ясалган бер нәрсәдер.

боларның йорт вә бала тәрбияләре хакында бу урында артык сөйләүне дә сүз озайту дип кенә беләмен. Заныма калса, бу ике төрле нечкә вазифалар тугърысында алардан артык шәй өмид итү дә буш булса кирәк.

Мишәр хатыннары вә кызлары үзләренчә гаять диндар йөреп, иске гадәтләренә нык ябышкан булулары өстенә, багучылар артыннан чабып бәхет сынату, җыелыш җыеп гайбәт сату вә кеше хәлен тикшерү, юк-бар сүзләрне үстерә-үстерә халык арасына тарату, бер-берсеннән көнләшеп, зур-зур исраф вә ясалма кыланулар вә күрше хатыннары илә җәнҗал кубарышу кеби эшсезлектән килгән начар вә хатыннарга ятышмаган әхлаклар вә сыйфатларга даияләр.

Мишәр хатыннарының бу хәлдә булуларына ирләренең бәхәссез уенчыгы булып «чапан» зинданында тоткын булып бикләнеп яткан хатыннар үзләреме

Бер мишәр, углының углы булганга, үз углы булудан артык сөенәдер. Бу минем тармагым күбәю, нәселем зураю, дип горурлана.

гаепле, юк исә аларны мәдәният юлына салып, гыйлем вә мәгариф, тәрбия вә күркәм әхлак эшләренә коендырудан кул тарткан ирләреме гаепле? Мин бу хакда катгый хөкем бирә алмасам да, ачыграк фикерле вә укыганрак бер мишәр хатынының сүзләрен язып китмәк булам. Ул бичараның чын бәгыреннән чыккан шушы сүзләрен тыңлап карагыз әле:

«Сез, ирләр, һаман безнең тәрбиясезлегебезне тәнкыйть кыласыз. Зан итәмен ки, безнең тәрбияле булуыбызны телисездер. Шулай булгач, безне ныклап укытып карагыз әле, ничек булыр икән! Горурлык белән әйтә аламын ки, ***без, мишәр хатыннарында булган истигъдад (сәләтлелек, булдыклылык, зирәклелек, үткенлелек) вә кабилият, тырышлык вә саклык, аң вә гыйффәтне һичбер милләт хатыннарында таба алмассыз...*** *Сез беләсез бит, менә шушы авылларда йөз йорт хуҗасының унысы да өйдә юктыр, алар һәммәсе хатыннарын ташлап унар ел читтә йөри. Шул* ***унар ел өй саклап яткан бер мишәр хатынының иренә хыянәт иткәнен ишеткәнегез бармы?*** *Ә ирләрнең төрле бәйрәмнәрдә типтереп йөрүенә катнашасым килмәсә дә, шунда түккән акчалары белән безне укытсалар иде, без дә башка булыр идек, дияргә җөрьәт итә аламын; шулай булгач, безнең уңмаганлыгыбызга уйламыйча үпкәли дә алырсызмы?»*

Дөрес, шушындый надан вә тәрбиясез булган мишәр хатыннарында бәгъзан бик гүзәл хасләтләр (холык, табигать, үзенчәлек, сыйфат) дә юк түгел. Мәсәлән, иренең әмереннән баш тартмау, гыйффәтенә хыянәт итмәү, йорт эчендә белгән кадәр хезмәтендә ялкаулык кылмау кебиләр.

Төс җәһәтенә килгәндә, мишәр хатын-кызлары гаять дәрәҗәдә матур. Әгәр аларның үткен вә матур кара күзләре, сөйкемле-көләч яңаклары, оялу белән елмайган вакытта карасыман алсулыкка әйләнгән кара туткыллы йөзләре, шомырт кеби кара вә озын сачләре белән керфекләре вә кашлары, шома вә тигез сөйкемле булган эре вә таза бәдәннәре яхшы тәрбия күргән, хиссият вә җазибәле (кешенең күңелен үзенә тарта торган көч, сыйфат) рух белән тәрбияләнгән бер кызда булса иде, җир йөзендә иң мактаулы вә матурлык белән мәшһүрә булган шәмгарәб кызлары да болар янында лә шәй (әһәмиятсез, һич кыйммәте юк) булып калыр иде.

Мишәр хатыннарының ирләр арасында гадәттән иң мактаулылары да — күп ир бала анасы булганнарыдыр. Мишәрләр, кирәк ир вә кирәк кыз балалар булсын, аларның күплегенә вә гаиләсенең зурлыгына никадәрле сөенсә дә, ир баланың күплегенә сөенгән кадәр үк сөенмиләр. Бер мишәр, углының

углы булганга, үз углы булудан артык сөенәдер. Бу минем тармагым күбәю, нәселем зураю, дип горурлана. Чөнки мишәрләрдә иң иске вә гаять ерак булган бер бабаның бөтен тармагы шуның фамилиясендә йөридер. Халык арасында да фәлән кабиләдән вә фәлән нәселдән дигән кеби, «фәлән халыктан» дип йөртелмәктәдер. Мәсәлән, «Бәшир халык», «Яхый халкы», «Шалкай халык», «Акчура халкы» кебиләр. Шуның өчен дә зур бер мишәр авылында да 3-4тән артык фамилия булмый. Шул сәбәпле, ир баланың күплеге бер кабиләнең зурлыгын арттырганлыктан, бу мишәрләр өчен зур бәхтиярлык булып, ир балаларына «болар безнең алтын баганаларыбыз» дип йөриләр. Ир балаларын артык сөйгәнгә күрә дә үзләренең иң сөйгән, аның кирәклегенә нык төшенгән сәүдәгәрлек гыйлеменә һәр мишәр үз баласын баштан ук өйрәтергә тырыша.

Мишәр халкы болай да гаиләләренең зурлыгына гомумән шатланучан буладыр. Алар үзләре дә: **«Өй җәмәгатең**

Мишәр хатыннарының ирләр арасында гадәттән иң мактаулылары да – күп ир бала анасы булганнарыдыр.

кирәк кечкенә вә кирәк зур булсын, барыбер гаилә мәшәкатен күрәсең. Гаиләнең ничек булса да көне һаман бер көенчә үтә; шулай булгач, зур бер гаиләнең тәрбиячесе исемен алу, әлбәттә, бер фазыйләт (яхшы эш)», – диләр. Менә шул сәбәпләргә күрәдер дә мишәрләр соң дәрәҗәдә тиз вә күп үрчегән бер халыктыр.

Текстны басмага
***Салават Галимов** әзерләде.*

Татарстан Фәннәр Академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондыннан алынды: 57 ф., 1 тасв., 75 сак. берәм.)

Дәвамы бар

ӘХЛАК

К.Бикколый, Г.Госмани

8. МӨШАВӘРӘТ (КИҢӘШЛӘШҮ)

Киңәшләшү дип әйтүебез, бер эшне кылмакчы булсаң, ул эш нинди генә эш булсын, аны ялгыз үз белдегең белән генә кылмый, бәлки башкаларга киңәш илә кылудыр. Эшләрне киңәш илә кылганнар хаталыклардан котылып, мең төрле файдалар хасил итәрләр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре эшләребезне киңәш илә кылырга боерды. Пәйгамбәребез: *«Синең белән берәү бер эш хакында киңәшләшсә, ул сиңа тәмам ышанганлыгыннан киңәш сораган булыр. Бәс, син үзең ул турыда ни кылыр идең, аңарга шуны киңәш ит»*, — димештер.

Хәстә бер табиб үзен икенче табибтан дару кылдырырга ничек мохтаҗ булса, шуның кеби адәм баласы никадәр галим вә гакыллы булса да, башына бер эш төшкәндә, икенче кешеләрнең киңәшенә шулкадәр мохтаҗдыр. **Адәм баласы кайсыбер вакыт үзеннән белеге аз кешедән дә хикмәтле вә файдалы киңәш ала белер.** Гакыллы кешеләр кемнән булса да булсын, ишеткән нәсыйхәтләреннән файда итә белерләр. Гакыллы кешеләр, үзенең белгәненә генә таянмыйча, һәрвакыт башкалардан киңәш сорарлар, киңәш сораган кешенең киңәше тугры булганда, үзенең белгәненә каршы вә башка булса да, шиксез, кабул итәрләр. Балалар, сез яшьләрсез, сезләр камиллеккә ирешкәнче күп адәмнәрнең нәсыйхәтләренә мохтаҗсыз, ләкин үзегезгә начар холыклы бер киңәшче тотмагыз! Булыр-булмас адәмнәр илә киңәш кылмагыз! Чөнки һәрбере төрле сүз сөйләп сине саташтырырлар. Бер хәстәгә күптөрле дару бирелсә, кайсын файдаланырга белми шашырлар. **Киңәшләшү өчен гакылы булган ике-өч кеше җитәдер.**

9. МОРАИЛЕК (ИКЕЙӨЗЛЕ БУЛМАК)

Кешеләргә ярар өчен, кешенең алдында бертөрле, артында икенче төрле сөйләп йөрүчене икейөзле, диләр. Мондый кешеләр адәмнәргә яхшы күренеп берәр файда итәр өчен яки берәүне алдау өчен мондый яман сыйфатка кереп йөрерләр. Бу бик начар вә ярамас эштер. Кешегә ярарга теләгән кеше, кешенең хәтере өчен бу кеше мине яратсын дип, күп ялган сүзләргә, вә булмаган нәрсәләрне алдарга өйрәнер һәм ул кешедә булмаган яхшы сыйфатларны бар, дип сөйләр. Мондый кеше күп вакыт начар кешеләргә дә ярар өчен, яман кешеләрнең яман сыйфатларын да яхшы, дип сөйләр вә бәгъзе вакыт үзе дә аларга ярар өчен яман эшләрне кылыр. Шулай итеп, әхлагы бозылыр, яман холыкларга өйрәнер. Мондый кешеләргә шәригатьтә монафикъ диярләр. Бу кешенең һичбер сүзенә ышану, игътибар итү дөрес булмас. Чөнки ул һичвакыт чын күңеленнән сөйләми, бәлки сиңа ярар өчен вә сине алдап файдаланыр өчен генә сөйләр. Андый кешенең мактавына да һич алданмагыз. Чөнки ул, сине яхшы күрүче булса, сине алдыңда мактамый, артыңда мактар иде. Әмма

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында

ул синең дошманың янына барса, аңа ярар өчен, сине әллә нинди явыз сүзләр илә хурлар, яманлар. **Яхшы кеше һичвакыт кешене алдында мактамас**, мондый икейөзлеләрдән берсе, хәзрәти Гали разый Аллаһы ганһе янына барып, аны бик югары күтәреп мактый башлагач, хәзрәти Гали: *«Мин синең мактавыңнан түбән дәрәҗәдә булсам да, әлхәмде лилля синең күңелеңдә булганыңнан күп югарымын»*, — диде.

Сез, балалар, мондый яман сыйфатлы кешегә һич игътибар кылмаганыгыз кеби, үзегез дә мондый начар сыйфатта йөрүдән бик саклана күрегез! **Яхшы булсагыз, кешегә ялганнар илә ярарга тырышмасагыз да, сезнең яхшылыгыгыз дөньяга фаш булыр.** Кешеләргә ярау вә кешеләргә яхшы күренү, әлбәттә, гүзәл эштер. Ләкин, кешегә ярар өчен, кешенең ярамаган эшләренә дә: «Әйе, шулай кирәк, бик яхшы итеп син...», — дип яманлыкны мактау, яманлыкны кылудан да яманрак хәрәм эштер. Яхшы күренер өчен яхшы фигыльләрдә йөрү — иң яхшы эштер. **Күркәм холыкта булган кеше кешенең гаебен әйтсә дә, гакыллы кеше аны яман күрмәс.** Бәлки нәсыйхәт итүче, изгелектә йөрүче дип, аның тугры әйтүенә шатланып, ул яман фигыльне ташларга тырышыр. **Кешене яманлыктан тыю — яхшылыкны кылудан да яхшырактыр.**

10. ЯМАН ТЕЛ

Дус-ишкә һәм башка кешеләргә усал сүз әйтү, кешене сүгү яки адәмнең хәтере калырлык начар сыйфатлар илә кешене рәнҗетү — бик яман вә ярамас холыклардандыр. Мондый яман телле булу мәктәп балаларына гына түгел, урам балаларына да килешмәс вә бик оятлы эштер. Мөселман булган кешенең авызында сүгенү, үртәнү кеби яман сүз булмый, бәлки һәрвакыт кешегә күркәм сүз әйтү, яхшы сүз илә кешенең мәхәббәтен арттырып, һәркемне үзенә карата торган ал тел булыр. **Яман сүз илә адәмнәргә түгел, хайваннарга да кычкыру ярамас.** Хайваннарны сүгәргә өйрәнгән кеше торабара адәмнәрне дә сүгәр, аларга да яман сүз әйтергә гадәтләнер. Мондый кеше иң мәхәббәтсез, иң бәхетсез, иң кадерсез кешеләрдән булып, һичвакыт яхшы кешеләр арасына кереп сүз сөйли алмас. Чөнки яхшы кешеләр янында яхшы сөйләү кирәк булып, яман сүз әйтү нигездә ярамас. Әмма мондый **яман сүзләргә, кешене сүгәргә, үртәргә өйрәнгән кеше, яхшылар янында да сабыр итә алмас, яман сүз әйтер**. Шул сәбәпле аннан яхшы кешеләр бизәрләр. Сез, балалар, мондый кабахәт вә ярамас гадәтне өйрәнеп, явыз холыклы булудан бик саклана күрегез, ничек тә кечек вакытта, бигрәк тә мәдрәсәдә, яман сүз әйтүдән сакланып, яхшы вә күркәм сүзләргә гадәт итегез.

Казан гаиләсе

11. ЗИЯРӘТ

Ата-ана вә карендәшләрнең хәлен белү вә аларны күрергә баруга зиярәт диярләр. **Зиярәт дөньялыкта өлфәт вә мәхәббәтне арттырыр.** Вә ахирәт

өчен олуг саваплы булуга сәбәп булыр. Галимнәр: *«Һәр көн зиярәт итегез, мәхәббәтегез арта барыр»*, — димешләр. Мөселман кешегә һәрвакыт мөселманнарның хәленнән хәбәрдар булып тору тиештер. Мөселманнарның хәлен белү, әлбәттә, аларны күрергә бару, хәл вә мәгыйшәтьләрен сорашып тору илә булыр.

Ата-ана вә якын карендәшләрне, аеруча кыз карендәшләрне зиярәт кылу важиб булып, аны үтәмәсәң, ягъни зиярәткә бармасаң, важибне куйган булып, зур гөнаһлы булачаксың. **Зиярәттән баш тартучыларга карендәшлекне кисүче, диярләр.** Бу исә гаять чирканыч вә ярамас сыйфатлардан булып, мөселманнарга нигездә ярый торган эш түгел. Пәйгамбәребез с.г.в. карендәшлекне кисүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте иңмәс, дип, алар илә бергә утырудан да мөселманнарны тыйды. Әмма карендәшекне җиренә җиткереп, туганнарны зиярәт кылу — Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә якын итеп, тәмугтан ерак кылыр, диде. Галимнәр **өч нәрсә** оҗмах әһеленең холыкларыннандыр, диләр. Аларның берсе — **яманлыкка каршы изгелек кылу**; икенчесе — **берәү сиңа золымлык кылса, гафу кылу**; өченчесе — **карендәшләргә яхшылык кылу**. Бәс, ата-ана, карендәш вә остазларга һәрвакыт изге ният илә зиярәт кылу — мөселман булган кешенең бурычыдыр.

Әгәр кулыгыздан килсә, һәдия (бүләк) илә зиярәт кылыгыз. Бүләк алып баруга куәтегез булмаса, яхшы тел вә күркәм сүзләр илә карендәшләрнең хәлен белергә тырышыгыз. Әгәр алай да барып күрергә куәтегез булмаса, хат илә карендәш вә якыннарыгызның хәлен белеп торырга омтылыгыз. **Якыннарны зиярәт кылган кешенең ризыгында бәрәкәт булыр.** Кардәшләренә мәхәббәте артыр, якыннары да моңа мәхәббәт итеп, кулларыннан килгән кадәр ярдәм итәрләр. Һәм мөселманнар бу кешегә рәхмәт әйтерләр. Ул күркәм холыклы, кардәшләренә шәфкать итүче, диярләр. Аллаһы Тәгалә бу кешедән риза булыр. Ата-аналары да моңа шатланып, һәрвакыт изге догада булыр. Зиярәт итүнең файда вә савапларын бер китапка гына язып бетерү мөмкин түгелдер. Һәр мөселман кешегә мондый изге холык илә холыклану важиб булып, моның кеби күркәм эшләргә кечектән үк гадәтләнергә тырышу тиештер.

12. ХӘЙЛӘКӘРЛЕК

Хәйлә кылам дип кешене алдау, юк-бар сүзләр илә кешене ышандыру — бик яман вә явыз холыклардандыр. Яман вә ялкау балалар мәктәпкә бармас өчен, яки барсалар да сабак укымас өчен «Хәлфә өйдә юк!» яки «Бу көн сабак бирмәде!» дип өйләренә кайтып, ата-аналарын юк сүзләр илә ышандырырлар. Ата-анасы да, балам алдамый торгандыр, дип инанып, угылына ачуланмас. Шулай итеп, мондый яман гадәткә өйрәнгән балалар бер мәртәбә, ике мәртәбә аталарын яки хәлфәләрен алдап, төрле хәйләләр кылып, алтын кеби газиз гомерен сабак укымый бушка үткәреп, тәмам надан вә холыксыз булып калырлар. Зур булгач та, мондый начар гадәтне ташлый алмый, тагын да зуррак хәйләләргә өйрәнеп, төрле яман эшләр кыла башларлар. Ахырында бу кешенең хәйләкәрлеге галәмгә фаш булып, «Ул хәйләче!», «Ул алдакчы!» дип яман атка калыр. Һәркем аңардан өмет өзәр. Аның эшләгән эшенә, сүзләгән сүзенә инанмаслар, аңа шәфкать вә ярдәм дә кылмаслар. Шул сәбәпле ул, халык арасында үз кадерен үзе югалтып, кадерсез, абруйсыз, надан вә фәкыйрь, эшлексез кеше булып калыр. Гомерен кыен вә мәшәкатьтә үткәрер. **Хәйләкәр булудан кечек вакыттан ук саклану тиештер.**

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

ОЧЫШ ДӘВАМ ИТӘ!..

Шаһинур Мостафин

Көннәрдән беркөнне, Ижевск каласында яшәүче күптәнге дустым-яшьтәшем — Удмуртия Республикасы Язучылар берлегенең татар телле язучылар бүлеге җитәкчесе — шагыйрь, прозаик, публицист Ринат Баттал, миңа телефоннан шалтыратып, үзенең үтенечен җиткерде:

— ...Воткинск шәһәрендә татар язучылары катнашында түгәрәк өстәл артында очрашу үткәрергә ниятләгән идек. Шул уңайдан, кадерле кунаклар итеп, Казаннан, үзебезнең куратор буларак, сине һәм танылган галим, шагыйрь Рифат Җамалны чакырырга ниятләдек. Шәт, риза булырсыз бит?! Яхшы, зур рәхмәт — сүзебезне тыңлавыгызга! Килгәндә «Фәрдетдин батыр» исемен йөртүче «Казан-Ижевск» экспрессына утырсагыз иде. Тиз дә, рәхәт тә уңайлы-җылы вагоннарда бару! Һәр ике республиканың — Татарстан белән Удмуртиянең — уртак горурлыгы бит ул!..

Һәм без шулай эшләдек тә. Юлда барганда мин әңгәмәдәшемә «Яңа меңьеллыкка очыш» дигән китабымның

төп каһарманы булган данлыклы очучы Фәрдетдин Сәхәбетдин улы Сәхәбетдинов турында бәйнә-бәйнә сөйләдем…

***

Моннан нәкъ 95 ел элек — 1919 елның 29 октябрендә — хәзерге Мөслим районының Югары Табын авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә ул. Гаиләдәге унбер бала арасында Фәрдетдин — иң өлкәне. Авыл мәктәбендә өч ел укыганнан соң, ул, әти-әнисе, бертуганнары белән, Ижевск каласына күчеп килә. Биредә Фәрдетдин 5 нче урта мәктәптә укуын дәвам иттерә һәм, бераз үсә төшкәч, шәһәрдәге аэроклубка йөри башлый. Үсмернең иң зур теләге — легендар Валерий Чкалов кебек кыю очучы булу! Кызыл Армия сафларына алынгач та, Фәрдетдин Саратов өлкәсенең Балашов шәһәрендәге училищеда хәрби очучы һөнәрен үзләштерә.

1943 елның гыйнвар аеннан башлап, кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдинов мөстәкыйль очышлар ясый башлый. Волхов фронтында барган хәрби хәрәкәтләрдә нәтиҗәле катнашуы, кыюлыгы һәм тапкырлыгы өчен, ул 14 нче Һава армиясе командующие — авиация генерал-лейтенанты, Советлар Союзы Герое Иван Журавлёвның шәхси рәхмәтенә һәм истәлек язулы кул сәгатенә лаек була.

1943 елның 27 мартында 281 нче штурм авиадивизиясенең 703 нче штурм авиаполкына Ленинград өлкәсенең Карбусель авылы белән Малукса бистәсе арасында дошманның хәрби ныгытмаларын, җанлы көчләрен, техникасын утка тотарга фәрман бирелә. Очучы Фәрдетдин Сәхәбетдинов белән укчы Егор Кретов «иярләгән» «Ил-2» хәрби очкычы да гитлерчы илбасарлар биләгән мәйданда ут давылын уйната. Кинәт кенә аларның штурмовигы дошман зениткаларының утлы боҗрасы уртасында кала. Нәтиҗәдә, очкычка снаряд тия һәм ул яна башлый. Фәрдетдин сугышчан дусты Егор Васильевичка парашют белән сикерергә боерса да, яралы сержант үзенең яраткан командирын очкычта ялгыз гына калдырырга теләми. Шуннан соң алар, ныклы бер карарга килеп, атаклы очучы Николай Гастелло (1907-1941) үрнәгендә, дөрләп янучы очкычларын фашистларның җанлы көчләре һәм хәрби техникасы өстенә юнәлтәләр. Дошман ныгытмалары өстенә барып җиткәч, алар тагын бомба ташларга өлгерәләр. Куәтле һава дулкыны ике дус утырган очкычны кинәт күккә чөя һәм бераздан Малукса бистәсе читендәге сазлыкка илтеп чумдыра…

2002 елда Ленинград өлкәсе, Татарстан һәм Удмуртия эзтабарларының уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә, әлеге «Ил-2» хәрби очкычы табыла. Иң гаҗәбе шул: 59 ел дәвамында салкын сазлык төбендә яту сәбәпле, очкыч кабинасындагы татар егете белән рус егетенең гәүдәләре чагыштырмача яхшы сакланган.

Сержант Егор Кретов Ленинград өлкәсенең «Новая Малукса» мемориаль комплексында үзенә «мәңгелек прописка» ала. Кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдиновның җәсәден исә, якын туганнарының соравы буенча, 2002 елның 13 октябрендә Ижевск каласына алып кайталар…

***

15 октябрь иртәсендә Фәрдетдин Сәхәбетдиновның җәсәден цинк табуттан алып, мөселман йолаларын тулысынча үтәп, тәхлил әйтеп, догалар укып, биредәге мәчет аксакаллары Мифтахетдин ага Фәрдиев белән Мәхмүт ага Нуретдинов яхшылап юдылар, ахирәт күлмәге кидерделәр һәм тагын ике кат ак җәймәгә төрделәр. Шуннан соң гына Фәрдетдин батырның җәсәден, агач табутка салып, өстенә әләм ябып, Ижевск шәһәре үзәгендәге Мәңгелек ут янына алып килделәр. Монда янә бер мәртәбә кадер-хөрмәт күрсәтү мәрасиме булды. Бирегә Удмуртиянең һәм Татарстанның

төрле төбәкләреннән меңнәрчә кеше җыелган иде. Араларында чал чәчле генераллар да, югары дәрәҗәле офицерлар да һәм яп-яшь солдатлар, курсантлар да бар иде.

Кайгылы-тантаналы җыенны Ижевск шәһәре вице-мэры Сергей Протозанов ачты һәм алып барды. Ул, 24 яшьлек очучының олуг батырлыгын югары бәяләп:

— Безнең Ижевск аэроклубын данлаучы, аны дөньяга танытучы кыю лачыннарның берсе ул! — диде. — Ватаныбыз тарихына тәвәккәл татар егете Фәрдетдин Сәхәбетдин улының да исем-фамилиясе алтын хәрефләр белән язылыр!..

Чыгыш ясаучылардан Удмуртия эзтабарларының «Долг» оешмасы җитәкчесе Фаил Ибраһимов, әлеге республиканың Татар иҗтимагый үзәге президенты Фнүн Мирзаянов, отставкадагы офицер Мифтахетдин Фәрдиев һәм башкалар киләчәктә Фәрдетдин батырның якты истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә башкарылырга тиешле эшләргә тукталдылар. Аерым алганда, әлеге каһарман укыган 5 нче урта мәктәпкә һәм аэроклубта аңа багышланган махсус стенд яисә музей бүлмәсе булдырырга, ел саен 29 октябрьдә (батырның туган көнендә) «Батырлык» дәресләре үткәрергә, Фәрдетдиннең данлы исемен шәһәрнең яңа төзелеп килүче бер урамына кушарга, дигән фикерләр әйтелде. Ижевск — Казан — Ижевск арасында йөрүче экспресска «Гастеллочы Фәрдетдин Сәхәбетдинов» дигән исем бирү тәкъдиме белән дә чыктылар җыенда...

Фәрдетдин батырның җәсәден Ижевск шәһәрендәге татар зиратына илткәндә, дистәләрчә машиналардан торган матәм колоннасын уздырып җибәрү өчен, һәр җирдә хәрәкәт тукталды. Колоннаның алдыннан да, артыннан да милиция машиналары «мигалка»ларын уйнатып барды.

...Җеназа намазын Удмуртия мөфтие урынбасары, Ижевск мәчетенең имамхатыйбы Фаиз хәзрәт Мөхәммәтшин укыды.

— Үткәнен белмәгән-барламаган хәтерсез кешенең киләчәге юк, — диде ул, җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп. — Шуңа күрә без, җәмәгать, Иманлы Хәтер сагында һәрчак уяу торырга бурычлыбыз. Киләчәктә шушы зиратта үзебезнең күренекле мөселман кардәшләребез өчен мемориаль үзәк булдыру да бик фарыздыр. Мөхтәрәм Сәхәбетдин ага улы Фәрдетдин кардәшебезнең дә рухы моңа шат булыр иде...

Фәрдетдин батырны заманында үзе яшәгән тансык туфракта, газиз әнисе Таҗылбанат кабере янәшәсендә гүргә иңдерделәр.

Күпне күргән зиратта, берән-сәрән сары яфраклары гына калган агачларны сискәндереп, өч мәртәбә ату тавышлары яңгырады. Яшь буын вәкилләреннән торган хәрбиләр үзләренең өлкән ватандашларына, әнә шулай, хушлашу салюты бирделәр: «Тыныч йокла, каһарман... Без сине һәрчак истә тотарбыз!» Кабер өстенә сары сагыш төсендәге яфраклар коелды, яңгыр тамчылый башлады...

***

Тагын шунысын да әйтеп үтим: Фәрдетдин Сәхәбетдин улының олуг батырлыгын мәңгеләштерү йөзеннән һәм Удмуртия Республикасындагы Татар иҗтимагый үзәгенең үтенечен искә алып, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты, 2005 елның 12 августында игълан иткән карарына нигезләнеп, Казан — Ижевск — Казан арасында йөрүче ЭР9Е №646 санлы тиз йөрешле электр поездына (экспресска) «Батыр Фәрдетдин» исемен бирде.

Шулай итеп, Ф.С. Сәхәбетдиновның яңа меңьелыкта да очышы (поезд канатларында!) уңышлы дәвам итә!.. ■

«МИНЕМ ШӘҖӘРӘМДӘ – БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ» КОНКУРСЫНА

БАБАМ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ...

Бабам Гапсәләмов Сәлихҗан Гапсәләм (Галим) улы 1924 елның 24 нче гыйнварында Минзәлә районы Әнәк (хәзер Актаныш районына карый) авылында туа. Пучы урта мәктәбендә яхшы билгеләренә генә укып, кулына өлгергәнлек аттестаты алам дигәндә, 1941 елның 22 июнендә фашистлар Туган илебезгә сугыш башлый. Авыр сугыш еллары аның матур яшьлек елларын урлый. Ерак бабам белән ерак әбием бердәнбер улларын, Сәлихҗанны сугышка озаталар.

Бабам мари урманнарындагы Суслонгерга килеп эләгә. Монда күргәннәре аерым бер китап язардай вакыйгаларга бай була. Шушы лагерьдан исән кала, һәм декабрь аенда сугышка китә.



Яуның беренче көненнән үк ул артиллерист булып сугыша. Кёнигсберг (Калининград) шәһәрен азат итеп, Берлинга кадәр барып җитә. Сугыш беткәч тә бабама Туган илебезгә кайтырга насыйп булмый, ул 6 ай японнарга каршы сугышта була.

Сынауларны күп кичә, күкрәген орден-медальләр белән бизәп, 1947 елны туган ягына, Әнәк авылына, җиңүче булып кайта.

Сугыштан соң бабам колхозда тимерче булып 45 ел хезмәт итә. Ул ясаган йозаклар, келәләр, ипи табалары хәзерге көндә дә кулланышта. Буш вакытында блокнотына шигырьләр язу белән шөгыльләнә. Әбием Саимә белән 7 бала тәрбияләп үстерә. Алар арасында төрле һөнәр ияләре бар. Айрат абыем исә «Нур Баян» күмәк хуҗалыгының рәисе. Бабам һәрвакыт балалары белән горурланып яшәде.

Бабам бүгенге көндә инде гүр иясе. Якты истәлеге булып хатирәләр генә калды. Аның батырлыклары өчен мин дә, әтием дә, калган балалары да, оныклары да горурланабыз. Аны барысы да хөрмәт иткән һәм хәзер дә олылап искә алалар.

***

Татар халкының бик үзенчәлекле бер традициясе бар. Ул — нәсел шәҗәрәңне өйрәнү һәм белү. Шәҗәрә аркылы инсан ата-бабасы җирендә яшәвенә, нәсел дәвамчысы булуына инанган.

Мин нәселебездә фронтовик шагыйрь Нур Баян булуы белән дә горурланам. Ул 1905 елның 15 маенда Әнәк авылында туа. Бөек Ватан сугышы башлангач та фронтка китә. Кызганычка каршы, аңа бөек Җиңү көнен күрергә туры килми: 1945 елның 23 апрелендә һәлак була.

Игътибарыгызга нәсел-шәҗәрәмне тәкъдим итәм, анда безнең туграбыз — нәсел тамгабыз да бар.

Гапсәләмов Ришат Иршат улы,
Актаныш районы,
Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы
(Җитәкчесе Шәрипова Гөлшат Әхмәтшәех кызы)



Афзал Шамов, Хәмит Ярми һәм Гомәр Бәширов. 1951 ел. Казан

ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР ХАТЛАРЫ

ФОЛЬКЛОРЧЫ ХӘМИТ ЯРМИ[1] ЯЗУЧЫ АФЗАЛ ШАМОВКА

7/XII-1944 ел.
Казан

Афзал туган!

Сиңа бик күп сәлам. Үзем исән-сау. Шул ук институтта эшләп ятам. Ләкин директор булып түгел, элекке эшемә кайттым — фольклор секторының җитәкчесе булып эшлим. Институт белән М.Гайнуллин[2] иптәш җитәкчелек итә. Мондый үзгәреш безнең институтның эше ӨК[3] да каралганнан соң булды. Институтның эше һәм минем җитәкчелек итү канәгатьләнмәслек итеп табылды. Үзем элекке эшкә кайтуым белән канәгать, секторның эшен яхшы куеп, хаталарны төзәтермен, дип уйлыйм.

Менә мин бу хатны сиңа бер үтенеч белән язарга булдым. Миңа ӨК Ватан сугышы фольклор җыентыгын чыгарырга тапшырды. Бу эш, беренчедән, тылда булган фольклор материалын җыйнау юлы белән, икенчедән, фронт фольклорын җыйнау эшен юлга салу белән булырга мөмкин. Билгеле, фронт фольклорын җыйнауда сезнең ярдәмнән башка бернәрсә дә эшләп булмас. Мин синең вакытың бик санаулы булуга карамастан, үзеңдә булган фольклор материалын бу хатны алу белән җибәрүеңә һәм бу эшне (барлык редакциядә эшләүчеләрнең катнашы белән) дәвам иттерерсең, дип ышанам. Моны син минем задание, дип аңлама, фәкать бер фольклорчының икенче фольклорчыга һәм үзенең якын иптәшенә булган үтенече, дип аңла.

Инде Казан турында язарга тиеш идем. Нәрсә языйм, бар да искечә кебек. Институттагы иптәшләр бар да эшләп яталар. Союзда бик күптәннән булганым юк. Разинны[4] кичә күрдем, ул инс-тка килеп чыккан иде. Ул миңа ярдәм итә. Үземнең бала-чагалар исән. Роза[5] мед.институтта. Урал[6] Архан-

[1] Хәмит Хөснетдин улы Ярми (Ярмөхәммәтов) (1904-1981), фольклорчы, 1942-1944 елларда — Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1944-1971 елларда — Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторы мөдире.
[2] М.Гайнуллин — Мөхәммәт Гайнуллин (1903-1985), әдәбият галиме, ИЯЛИнең директоры.
[3] ӨК — Өлкә комитеты.
[4] Разин — Гомәр Бәшир (1901-1999), язучы, 1933 елдан башлап Гомәр Бәшировның әдәби тәхәллүсе.

гельск хәрби-диңгез флоты мәктәбендә укый. Менә шул.

Синнән хат һәм фронт фольклорын көтеп калам.

Адрес: Казань, Б.Красная, 68.

Институт языка, литературы и истории. Сектор фольклора.

Иптәшләргә бик күп сәлам.

Кулыңны кысып, Хәмит.

P.S. Абдулга[7]*, Гыймади*[8] *иптәшкә күп сәлам, алардан да хат һәм материал көтәм.*

Х.Я.

Афзал Шамов
ЕРТЫЛЫП ТАШЛАНГАН ХАТ

Казаннан, Хәмит Ярмидән хат алдым. Шактый озак килгән. Кайдадыр аунап яткан булса кирәк, шулай да бик күңелле булып китте. Җыелышып укыдык. Туган илдән килгән хатлар гына түгел, шул яктан искән җил дә кадерле безгә!

Хәмит дускай миннән халык авыз иҗаты әсәрләре сорый: әкиятләр, бәетләр, җырлар, мәзәкләр. Җыентык төзи икән. Тиз арада җибәрүемне үтенә. «Сез анда окопларда йөрисез, илебезнең төрле өлкәләреннән килгән татар егетләре белән еш очрашасыз, — дип яза. — Яңа җырлар да, әкиятләр дә, бәетләр дә күптер аларда...» — ди. Хатның килүенә шатлансак та, Ярминең бу сүзләрен укыгач, елмаймыйча булдыра алмадык. Ни әйтсәң дә, тыл кешесе ул. Безнең тормышны, хәлебезне, эш шартларын күз алдына китерә алмый. Аңынча без, газета корреспондентлары булгач, әкиятләр, бәетләр, җырлар җыю берни түгел безгә! Алгы сафтагы окопларда сугышчылар арасында йөрисең дә, аркаңдагы бөрмәле капчыкны чишеп, әкиятләрне, җырларны, бәетләрне чүмеч белән тутырасың гына. Шуның белән вәссәлам! Аннары аларны акка күчереп, тиз генә аңа күндерәсең. Әй, Хәмит дускай, Хәмит дускай, безнең хәлләрне белсәң иде син! Без монда газетабызга кирәкле утыз юллык хәбәрне дә кайчак ут эченнән алып чыгабыз. Яшермим, шундый чакларда фашист пуляларыннан йә корсагыбызга, йә башыбызга берәр тишек ясатмас өчен җирне кочып ятабыз. Күпме ятабыз? Бер минут... ике минут яисә ярты сәгать?.. Билгеләнгән срогы юк. Баш очыбыздан пулялар яки снаряд, бомба кыйпылчыклары сызгырудан туктагач кына, урыныбыздан сикереп торып, барыр юлыбызга таба иелә-иелә йөгерәбез...

Күптән түгел генә бер иптәшебез редакциягә бөтенләй кайтмады. Шунда ятып калды. Бик яхшы журналист иде. Сугышка алынганчы «Знамя» журналының редакторы булып эшләгән. Онытa алмыйбыз, исебездән чыгара алмыйбыз аны.

Һәрвакытта да болай булмый, билгеле. «Тынычрак» чаклар да була. Тыныч дигән сүзне тырнаклар эченә алдым, шуннан үзең аңларсың. Шулай да бер хакыйкатьне әйтим: сугыш барган җирдән хәбәр җыеп кайту ансат түгел. Ә син: «Әкиятләр җый, бәетләр җибәр», — дигән буласың. Бик ансат уйлыйсың! Окопта ятучы солдатның, сугышчының әкият сөйләргә түгел, йокларга да, ашарга да вакыты юк. Аның бары сугышырга гына вакыты бар. Бары сугышырга гына!

Сугыш ул — бик катлаулы нәрсә, бик авыр эш. Менә сугышчы шул авыр эшне, дөньяда чагыштырырлык үрнәге булмаган, элеккечә әйткәндә, мисле булмаган коточкыч авыр эшне башкара, ялны белми, йокыны белми... Шундый хәлне күрә торып, берәр сугышчыга: «Кара әле, иптәш, берәр әкият сөйләп җибәр әле», — дип ничек әйтим мин?

---

[5] Роза — Хәмит Ярминең кызы.

[6] Урал — Хәмит Ярминең улы.

[7] Абдул — Абдулла Әхмәт (1905-1976), язучы, «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасының хәрби хәбәрчесе.

[8] Гыймади — Минһаҗ Гыймадиев (1903-1970), журналист, «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасының редакторы.

Моңа телем ничек әйләнсен? Үпкәләмә, дускай, моны эшли алмыйм.

Дөрес, монда, алгы сафта, окопларда, кулларына корал тоткан егетләр арасында күп нәрсә, бик күп нәрсә җыярга була, бары тик... син сораган халык авыз иҗаты әсәрләрен генә җыеп булмый. Мәсәлән, атканнан соң бушап калган автомат, винтовка гильзаларын, мина, снаряд кыйпылчыкларын, чәлпәрәмә килгән пушкаларны, гаубицаларны, хәтта янган, шартлаган танкларны да җыярга мөмкин, тик син сораган әкиятләрне генә җыярга мөмкинлек юк. Орышма, Хәмит, сиңа бернәрсә дә җибәрә алмыйм.

Алгы позицияләрдән арткарак, резервка табарак китсәм, җырлар, хәтта кыска-кыска мәзәкләр дә табар идем, бәлки, бусына инде солдатның түгел, ә минем вакыт юк. Редактор безне сугышлар барган җиргә генә җибәрә. Бар, йөгер! Ут кебек атылып бар да, газетабызның киләсе саннары өчен яңа хәбәрләр, репортажлар, очерк язарлык материаллар алып кайт. Ян, көй, шартла, әмма алып кайт! Алып кайтмыйча калма! Приказ шундый. Приказны үтәмичә ярамый! Аны үтәр өчен утка да, суга да керәбез.

Менә бездә эшләр шулайрак тора, Хәмит дускай!..

Җавап хатымны мин Хәмит Ярмигә шундыйрак мәгънәдә яздым, җибәрер өчен өчпочмаклап катлый да башладым. Эшемне тәмамлап килгәндә каяндыр Абдулла Әхмәт кайтып керде (аның белән бергә хезмәт итә идек). Ярмигә хат язганымны белгәч:

— Миннән сәлам яздыңмы? — дип сорады.

— Юк, — дидем мин.

— Бир әле, үз кулым белән языйм.

Хатымны аңа суздым. Ә ул сәлам язу белән генә чикләнмәде, хатны да укыды. Шуннан соң миңа көлемсерәп карап торды да бик сәер сорау бирде:

— Хәмитне үпкәләткәнең бармы синең?

— Юк, — дидем мин, аның соравына гаҗәпләнеп. — Ник, әллә үпкәләтерлек сүзләр бармы?.. Бер дә үпкәләтәсем килми аны.

— Алайса, бу хатны җибәрмә син аңа, — диде Абдулла миңа шуннан соң. — Хәмитне мин яхшы беләм. Якын дустым ул. Берничә ел бергә эшләдем. Бик үпкәчән егет ул. Бу хатыңны алгач, бик үпкәләр... Син аңа йомшак кына итеп яз. Алай диген, болай диген, әлегә бер дә җыеп булмый бит, дускай, диген. Җыеп, бераз туплау белән үк җибәрермен, диген. Менә шулай яз.

Абдулланың киңәшен тотып, хатымны ертып ташладым да икенчене яздым.

1945.

ЯЗУЧЫ АФЗАЛ ШАМОВ ФОЛЬКЛОРЧЫ ХӘМИТ ЯРМИГӘ

Ярми туган!

...Бу хатың белән син мине ничектер уятып җибәргәндәй булдың. Без фольклор җыю эшенә монда бертөрле дә әһәмият бирмәгәнбез. Тынгысыз частьлар буйлап, ашыгыч эшләр артыннан йөгерә-йөгерә шундый әһәмиятле нәрсәне онытканбыз. Дөрес, минем бу турыда уйлаштыргалаганым бар, ләкин һәр юлы аны икенче, хәтта иң арткы планга куйгаларга туры килде. Шулай итеп, бүген минем биштәрле капчыгымда ике генә юл да материал юк. Хәзер мин сиңа бернәрсә дә җибәрә алмыйм, дус кеше. «Ах, бу бәндәне!» — диярсең инде син, ачынып. Нишлисең бит, бәндә гөнаһтан хали түгел (шулай диләр шикелле, онытыла да төшкән).

Кызың институтта, улың хәрби мәктәптә укый торган булгач, бик зур карт булгансың икән инде син. Балаларыңа бәхет телим, ә үзеңә тыныч «картлык»! Ах, гомер, гомер, уза да уза! Чынлап картаябыз, Ярми. Артыбызга әйләнеп карасак, озын, тар сукмак. Гомер сукмагы. Анда безнең ялангач аякларыбызның эзеннән башка бернәрсә дә юк. Коры эзләр генә.

Сез миңа Тукай томын җибәрткәнсез, дип ишеткән идем. (Шушы урында ручкамның карасы бетте. Каһәр төшкән

немец ручкасы! Караны аз ала. Хәзер инде гади ручка кебек итеп манып кына язам. Кул астында андый кара юк. Бу хатымны өйдән чыгып киткән җирдә язам.) Искә төшереп, китап җибәрүең өчен шушы көнгә кадәр сиңа да һәм Агишка[9] да рәхмәт әйтергә туры килгәне юк иде. Бу хатым белән бергә минем чын күңелдән әйтелгән рәхмәтемне дә алыгыз.

Яңа эшеңдә уңыш телим. Материаллар табылу белән үк җибәрә барырмын.

Сәлам белән, А.Шамов.
6 февраль, 1945 ел.

Афзал Шамов
«ОРХОН ЯЗМАЛАРЫ»

Гомәр Разиннан да (Гомәр Бәширов) хатлар килгәләп тора. Еш килми, билгеле, әллә нигә генә. Шулай да без аңа рәхмәтләребезне яудырабыз. Иптәшләр белән элемтәне өзәсебез килми.

Гомәр хатларын сызыклы, юка, яхшы кәгазьгә яза. Бу кәгазьне безгә 1939 ел ахырында Язучылар союзыннан биргәннәр иде. Финляндиядә яисә Эстониядә эшләнгән кәгазь булса кирәк. Минем дә бар андый кәгазь. Тик өйдә, Казанда, мин кайтканны көтеп ята. Кайтырбызмы икән?

Гомәрнең язуы котсыз түгел, ләкин хәрефләре бик вак, хәтта шулчаклы вак, хатны бер укыганда гына танып бетереп булмый. Кат-кат укыйбыз, шулай да танып бетерә алмыйбыз. Бу юлы да шундый хәл булды. Ниндидер бәрәңге турында язган. Нинди бәрәңге? Ни булган? Әллә Казанда безнең гаиләләргә бераз бәрәңге өлешкәннәрме, ягъни каян булса да Союз бәрәңге алып кайтып биргәнме? Һай, шулай булса иде! Балаларым рәхәтләнеп бәрәңгеле аш ашар иде. Дүрт бала бит анда — дүрт кашык. Карчыгым белән биш кашык. Бәрәңгенең килосы йөз сумнан да кыйбатрак, дип язалар. Ә минем аларга аттестат белән җибәрә торган айлык хезмәт хакым 600 сум гына.

Ниһаять, Гомәр хатын тәмам укып бетердек шикелле. Абдулла Әхмәт фотокорреспондентлардан лупа алып кайтты. Шуның белән укыдык. «...Язучыларга җир бирделәр. Консерва тартмалары, чүлмәк китекләре, кирпеч ватыклары белән ашлап, бик тырышып бәрәңге утырттык. Бәрәңге ашарга кайт», — дигән икән.

Моны укыгач, Абдуллла Әхмәт шатланып кычкырып җибәрде:

— Ох ты, бик шәп булган бит бу, ә? Болай булса, безнекеләргә дә җир биргәннәр. Ничек уйлыйсың, бирделәрме икән?

— Нигә бирмәсеннәр, — дидем мин. Шулай уйлагач, ничектер, йөрәгемә җылы кереп китте. Утыртырлык бәрәңгесе булса, Гадиләм дә утыртыр...

— Гаҗәп бит бу — Гомәр хаты! — диде Абдулла Әхмәт. — Укыган саен яңа хәбәр чыгып тора. Я әле, бир әле! Тагын бер шатлыклы хәбәр юкмы икән? Лупа тотып, башыннан ахырынача укып чыгыйк әле.

Чыннан да, Гомәр хатын кайчак лупасыз укып булмый, хәтта лупа белән дә танымаган сүзләр калгалый. Шулай тырышып, азапланып укыйбыз аның хатларын.

XVIII гасыр башында галимнәр Себердә Орхон-Енисей язмаларын тапканнар. Төрки телдә сөйләшүче ниндидер кабиләләр VII-XI гасырларда шундый язуны кулланганнар, дип саныйлар. Галимнәр ул язуны укыр өчен күп тырышканнар, күп тир түккәннәр, бары XIX йөзнең ахырында гына укый алганнар. Кайчак без, шаярып, Гомәр хатларын «Орхон язмалары» дип тә атыйбыз. Ничек кенә булмасын, без аның хатларын көтеп алабыз, чөнки алар безгә Казан хәбәрләрен, дусларыбызның сәламнәрен алып килә.

1944 ел.

Хатларны һәм искәрмәләрне басмага ***Әлфия Шамова*** *әзерләде.*

[9] Якуб Хәлил улы Агишев (1899-1972), әдәбият белгече, текстолог.

«ИЛЕМӘ БУЛГАН СӨЮ ЯЛКЫНЫ»

Шәфигулла Гарипов,
«Казан арты» тарих-этнография музееның директор урынбасары

«Арча кичләре», «Акталныш таңнары», «Балкый Шәйморза утлары», «Бөдрә таллар», «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Киек казлар китә» кебек әдәби-музыкаль мирасыбызның җуелмас ядкярләре кальбендә татар рухы булган һәрбер инсанның хәтерендәдер, мөгаен. Әлеге әсәрләрнең авторы, шагыйрь, тел галиме һәм тәрҗемәче Мостафа Ногман 1912 елның 22 декабрендә Арча районы Кызылъяр авылында туган. 1931 елда Казан педагогия техникумын тәмамлаганнан соң, берничә ел Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә укытучы, 1935-1937 елларда Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда сәркатип булып эшли. 1937-1941 елларда Дүшәмбе педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бөек Ватан сугышында юстиция өлкән лейтенанты дәрәҗәсендә гаскәри хезмәт юлын үтә. Сугыштан соң, 1947-1951 елларда Мәскәүнең Көнчыгышны өйрәнү институтында фарсы-төрек телләре бүлегендә, 1953-1957 елларда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый. 1964 елдан — филология фәннәре кандидаты, 1965 елдан — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 1960 елдан — вафатына кадәр — Казан дәүләт университеты студентларына фарсы һәм иске татар теле укыта.1976 елның 4 сентябрендә Казанда вафат була.

Арча шәһәре «Казан арты» тарих-этнография музееның әдәбият-сәнгать бүлегендә Мостафа Ногманның 1944 елда дөнья күргән иң беренче китабы — «Давыллы еллар лирикасы» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы саклана. Китапка автор тарафыннан «Нечкә моңнарны дулкынландыручы Җәүдәт Фәйзи иптәшкә өйрәнчек җырларымның беренче бәйләме», — дип истәлек тә язылган. Үз вакытында укучылар тарафыннан җылы кабул ителгән бу китап басылганнан соң 70 ел вакыт үткән. Бөек Җиңүне якынайтуда, рухи азык буларак, әдәбият зур роль уйнаган. Игътибарыгызга әлеге җыентыктан «Каен яфраклары» шигырен тәкъдим итәбез. Лирик шигырь ул. 1943 елның дәһшәтле көннәрендә язылган бу шигырьдән чын мәгънәсендә ихласлык бөркелә.

Мостафа Ногман

КАЕН ЯФРАКЛАРЫ

Зифа каен саргылт шәл бөркәнгән,
Җил искәндә салмак иелә,
Ука яфраклары берән-сәрән
Иренеп кенә җиргә сибелә.

Ул яфраклар салган яшеллеген,
Югалтканнар җәйге көчләрен,
Хәзерләнә алар чуарлатып
Бизәр өчен җирнең өсләрен.

Җәйләр буе алар яшәрделәр —
Тын алдырып зифа каенга,
Уяттылар керфекләрен сирпеп,
Ул әкертен тынган саен да.

Шыбыр-шыбыр җылы яңгыр яуса,
Тавышын тыңлап тора иделәр,
Тамчылары белән ак каенның
Зифа буен юа иделәр.

Җилпеделәр алар салкынча җил
Аңа көннең бөркү чагында,
Көйләделәр иркен яшәү моңын
Ямьле җәйнең назлы таңында.

Гашыйк булды алар ак каенга
Тудырганы өчен үзләрен,
Бөре килешеннән яфрак итеп —
Үстергәнгә кадәр түзгәнен.

Көн аралаш шулай, көн саенмы,
Көзге җилләр шаулап исәләр,
Ә яфраклар сөеп ак каенны
Ялкау гына җиргә төшәләр.

Хөрмәт белән шаулап алар шулай
Саубуллаша моңсу каеннан,
Мин язмышны әрлим, яфракларны
Туган илләреннән аерган.

Нинди бәхет, минем ил халкымның
Яфрак кебек түгел язмышы,
Һаман да яз, һаман яфрак ярган
Хисләренең кайный язгысы.

Нинди бәхет, минем азат халкым
Һаман яши туган илендә,
Кайгы төшсә аңа, уртаклаша
Авырлыгын алып иңенә.

Агуларын чәчеп аждаһалар
Зәһәрләвен илнең күкләрен,
Илебезнең тылсымланган чиген
Юлбасарлар бозып үткәнен —

Белгән генә иде батыр халкым
Бер туган күк торып беррәттән,
Бабайларның намусын даулау өчен
Яу кырына чыкты кинәттән.

Кем сөймәсен туган авылларын,
Мул игеннәр үскән кырларын,
«Шүрәлеләр асрап ята торган»
Әкияткә бай, күксел урманын.

Мин, туган ил дисәм, җитез генә
Идел буен айкый уйларым,
Һәм ашкына кочып алыр өчен
Киң Союзның чиксез буйларын.

Мин солдаты менә шушы илнең
Һәм язмышым аның кулында,
Каен яфрагы күк саргайсам да,
Сынатмамын данлы юлында.

Нинди бәхет, минем ил халкымның
Яфрак кебек түгел язмышы,
Гел яшәреп яши үз илендә,
Хисләренең кайный язгысы.

Хәрәкәттәге Армия.
Сентябрь, 1943 ■

1979 елнын 27 декабрендә Совет гаскәрләре Әфганстан Республикасына кертелде. БМО мәгълүматларына караганда, 1979 елның декабреннән 1989 елның февраленә кадәр вакыт эчендә ике миллион әфганлы һәлак булган, ике миллионнан артыгы яраланган, биш миллионы мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр ителгән. Тетрәндергеч саннар.

ХАКЫЙКАТЬНЕҢ ТӨСЕ НИНДИ?

Марат Закир

Әрәм ителгән халык байлыгы турында исә әйткән дә юк! Феодаль тәртип хөкем сөргән илдә социализм төзибез, дигән булып, Әфганстанга миллион вә миллионлаган сумлык матди байлык агылды. Халык вә дәүләт малының мәгънәсезгә сарыф ителүенә бер генә мисал: кул урагы белән генә урырга мөмкин булган эреле-ваклы кишәрлекләргә «Дон», «Нива» ише совет комбайннары кертелде…

1989 елның 15 феврале… Ул көнне совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты, Женева халыкара килешүләрендә каралганча, Әфганстан Республикасыннан тулысынча чыгарылды. Әфган сугышын кичкән һәркем өчен, аларның гаиләләре өчен фаҗига белән үрелгән кадерле көн бу!

Шәхсән минем үземә дә әфган таулары һәм далалары аша узарга, яу кырында дары иснәргә туры килде. Бу сугышта Татарстаннан гына да ун меңнән артык ир-егет катнашты. Шуның өч йөзгә якыны яу кырында һәлак булды. Гарипләнеп, яраланып кайтучылары да байтак. Инде Ватанга кайткач, тыныч тормышта (тынычмы соң ул?!) җәфа чигеп, яуда алган яралардан үлүчеләр, үз-үзенә кул салучыларның да саны йөздән ашты… Ә бит солдат сугышны үзе сайламый, сугышны да ул игълан итми. Әфган афәтен заманында кемнәрдер «батырлык мәктәбе» дип атадылар. Аны шулай дип, минемчә, бары тик ахмак кеше генә атый ала. Ләкин андыйлар бик тә зирәк булып чыктылар: үзләренең улларын әлеге «мәктәп»кә җибәрмичә, тизрәк йолып калу ягын карадылар. Әфган сугышындагы

дөреслекне дә югары даирәләрдә яшерергә маташтылар. Әмма дә хакыйкать сәгате барыбер котылгысыз...

Хакыйкатьнең төсе нинди? Мөгаен, аның төсе, рәвеше күптөрледер. Вәләкин ул үзе — бердәнбер!

35 ел элек башланган сугыш... Тугыз ел да бер ай һәм унтугыз көнгә генә (1979, 27 декабрь-1989, 15 февраль) сузылдымы соң бу сугыш?! — Һич тә юк! Ул бүген дә дәвам итә. Әфган афәтендә катнашырга мәҗбүр булган егетләрнең инде үз балалары да үсеп җитте... Аларны да Рәсәй-Чечен авантюрасында катнашу фаҗигасе көтеп торган икән. Нинди каһәр суккан ил бу: буын саен бер сугыш?! Инде янә — табутлар, кан дәрьясы, җир куенына керә алмыйча, еллар буе суыткычта ятучы мәетләр, әсирлек... Тыныч кына яши башлыйбыз да... Янәдән... Инде бу юлысы Украинада дөнья болгаталар. Соң, нинди илдә яшибез без, киләчәктә тагын ниләр күрербез?! — Җавап юк. Әмма җавап

бар. Ул — хакыйкать. Тик бу хакыйкать алга таба гел кан төсенә — кызыл төскә генә буялмаган булсын иде! Хәер, ишетергә теләгән җаваптан да өстен хакыйкать бар. Ул соңлабрак иңәргә яратса яки мәҗбүр ителсә дә, аны җиңгән кеше юк әле!

Бу рәсемдә чираттагы рейдка кузгалучы «шурави»-яугирләр тасвирланган. Янә берничә минуттан, сәгатьтән, көн вә төннән соң, киләчәктә ни көтә аларны? Анысын бер Ходай үзе генә белә.

«Кадалыплар гына инде
Китсен лә бу дөньясы!
Үлә-нитә калсак әгәр,
Чыгар безгә кем ясин?» — дип, авыз эченнән генә пышылдый сыман алар... ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Берсе — язуны бик әйбәт бетекче,
Һәм берсе ялавач — сүз, тел белгече.

Якынмы — еракмы, илләр арасы
Бозылу, гадәттә, болар бәласе.

Хәл яхшырса, болар була саваплы,
Хәл хөртәйсә, болар була җаваплы.

Бетекче ялгышса язган сүзендә,
Ялавач төзәтә алсын тиз генә.

Бетекче шундый зат булсын, и, илбик,
Аңар ышанырлык булсын кул биреп.

Шундыйларны ал ки инанып элек.
Аларда булсын чын кешелеклелек.

Менә шушы нндe минем белгәнем,
И, илбик, бурычым, ахры, төгәлде.

Илбик әйтте: — Барсын тыңладым, белдем,
Тагын бер соравым — сүзем бар инде.

Хәзинәче тиеш нинди булырга,
Таки тапшырырлык бар малны шуңа.

Аңарда сакланса мал, алтын-көмеш,
Үтәлсә аңарга төшкән һәр йомыш.

ҮГДЕЛМЕШ ХӘЗИНӘЧЕ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕКНЕ ӘЙТӘ

— И, котлы илбигем, — диде Үгделмеш, —
Җан кебек нәрсә ул — алтын һәм көмеш.

Күңелдән ышансаң, бер гадел ирне
Хәзинәче итеп куясың инде.

Ни ди, ишет, безнең сартлар[1] башлыгы
(Дөнья гизеп җыйган шунча байлыгын):

«Кадерлеләрдән иң кадерле — ул җан,
Ләкин кадерлерәк алтының җаннан.

Йомшата көмеш иң корыч күңелне,
Бөгелдерә көмеш бөгелмәс билне.

Көмеш күреп, шуңа күңел бирмәсә,
Шундый зат, мөгаен, фәрештә кемсә.

Алтын күрсә йомшый иң кырыс ирләр,
Түбәнчел булалар горур-эреләр».

Тугры хәзинәче булмасын комсыз,
Иминлектә күрсен бәхетен-котын.

Мал-мөлкәтләрне күп күргән дә булсын,
Һәм Алладан курка торган да булсын.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Сарт — борынгыча «сәүдәгәрләр», соңрак шәһәр үзбәкләрен белдергән; бу сүздән сату сүзе ясалган.

Күрсә яшь чактан ук алтын-көмешне, Артык комсызланып котырмый кеше.

Ачык аерсын ул хәләл-хәрамны
Һәм дә яраганнан ярамаганны.

Канәгать инсаннар «малым аз» димәс,
Хирысланып кеше хакына кермәс.

Күрсә яшь чактан ук алтын-көмешне,
Артык комсызланып котырмый кеше.

Әгәр курка торган булса Тәңредән,
Тугрылык юлыннан чыкмас ул бер дә.

Тугры булу һәрчак күңел пакьлеге
Һәм мәңгелек алчак яшәү татлыгы.

Тугры кешенең һәр көне изгедер,
Мәңгелек бәхеткә ул юл эзлидер.

Ишет миннән — әйтим миһербанлы сүз,
Шул сүз буенча эш ит, и, күңле төз.

Бөтен — тугры булсын кылыгың — телең.
Шул чагында дөнья дәүләте килер.

Тугры булсаң, бәхтең артыр көннән-көн,
Булсын гына саулык-сәламәтлегең.

Миһербанлы кеше, уяу, әдәпле,
Мең эш булдырырлык көчле-сәләтле.

Зирәк, акыллы һәм иҗтиһадлы бул,
Оятсыз кешедән ерак тор, түңел.

Оят ул — ярамас эштән кисәтү,
Бозык күңелне дә оят төзәтер.

Һәм кеше тыелсын, эчмәсен хәмер,
Хәмер эчмәгәннәр бәхетен табыр.

Эчкече әйберен өләшә, бирә,
Ләкин бәрабәрен алмый, тилмерә.

Хәзинәче булсын аек һәм саран:
Икътисадчы өчен саранлык таман.

Тугры хезмәткәр, күр, бәген үз итәр,
Тугры хезмәт илә байлыкка илтәр.

«Кешенең яхшысы — тугры кешедер,
Тугрыларны күтәр, илбик — асыл ир.

Хәзинәче уяу булса, эш төзек,
Мөлкәтең саклаулы һәм тыныч үзең.

Ушлы булса кеше — бозылмас эше,
Дөрес булыр хисап, китмәс ялгышы.

Күргәнен онытса, ялгышса һаман,
Нинди хәзинәче чыксын, ди, аннан.

Исәп-хисап өчен кирәк аек баш,
Түнек баш ни кирәк, шуны аермас.

Бетекче күп төрле язуны белсен,
Исәбен язуда беркетеп килсен.

Бетекче күзәтә керем-чыгымны,
Язып куя төрле ыбыр-чыбырны.

Хәзинәче булсын аек һәм саран: Икътисадчы өчен саранлык таман.

Көне, ае, елы билгеле булсын,
Күләм-санын төгәл белерлек булсын.

Хисапсыз, язусыз һич эш булалмый,
Язу капка ачып, гамәл юл алыр.

Илтифатлы инсан болай дип әйтер
(Хадимнәрнең эшен төгәл белеп тор):

Язусыз теркәлмәс, шиксез булып, уй.
Хәтеремдә, димә, углым, язып куй!

Язылса, сүз калыр, юкса югалыр,
Гафил хадим авыр әхвәлдә калыр.

Ничә төрлесен бел, углым, язуның,
Шуннан мөмкин булыр гамәл кылуың.

Гафил булса хадим язу-хисапта,
Авыр хәлдә калыр башлык күп чакта.

Хөкемдарның белеп уй-палламасын,
Хадим үз исәбен алдан уйласын.

Хөкемдар уена бап чара күрсен.
Һәндәсә шикелле төгәл уй йөртсен.

Күзең илә күргәч, күңелең теләр,
Күңлең теләгәч, сине кем тыяр?

Беләсең, һәндәсә ул үтә нечкә,
Төгәл саннар куя ул җир вә күккә.

— Вакытны ганимәт бел, — ди әнә белкә, —
Көндәлек аш итеп кара белемгә.

Ә һәндәсә гыйльме бик тә тирәндер,
Күп хәкимнәр мәшгуль шуның белән гел.

Җиде кат күктә ул адымлап баса
Һәм кылны кырыкка яра, теләсә.

Белемле һәм зирәк, холкы төз кирәк,
Зирәкләр һәр эштә була өлгеррәк.

Белемле кешеләр, була чын тугры,
Шундыйлар кайда да булырлар нурлы.

Зиһене булмаса, кеше беләлми,
Белеме булмаса, бер эш кылалмый.

Хәзинәче эше кирмән[2] эчендә,
Күзәтчәнлек кирәк аның эшендә.

Телен, күңлен тыйса һәм холкы бөтен
Булса, аңар тимәс ут-ялкын, төтен.

Күзен уйнатмаса, бикләсә сүзен,
Акыл илә уйлап, тыйса нәфесен.

Күзең илә күргәч, күңелең теләр,
Күңлең теләгәч, сине кем тыяр?

Күңел җиде әгъза өстеннән бийдер.
Бий кузгалса, коллар артыннан йөгерер.

Шәп әйткән бер галим менә бу сүзне:
— И, егет, аздырма, күңел вә күзне».

Тән-буй, җиде әгъза күңелгә күндәм.
Күңлең калдырмасын бик авыр көнгә.

Күңеле юк кеше — бары тик шәкел,
Күңелсез кешедә булмас чын акыл.

Саран булсын казна мөдире бик тә:
Юмарт булса, казна таралып бетәр.

Юмартлык бик әйбәт ул, ансы, ләкин
Кеше малы белән юмарт булма син.

Сату да бик әйбәт, тик белеп сатсаң,
Югыйсә һич килмәс ич табыш-аслам.

Товарның төрлесен танырга кирәк:
Кыйбатын-арзанын табарга кирәк

Бәяләрне белсен — алданмасын ул,
Кирәгеннән артык мал алмасын ул.

Соллы булсын үзе алыш-бирештә,
Татлы булсын сүзе олы-кечегә.

Вакытында бирсә сорап алганын,
Кирәк-хаҗәтенчә бирерләр тагын.

Гаделлекле булса сату-алуда,
Кирәкле таварын табар тагы да.

Юмартлык бик әйбәт ул, ансы, ләкин
Кеше малы белән юмарт булма син.

Әгәр бий сораса гаскәргә азык,
Җитештерсен шундук тоткарсыз табып.

Сүв[3] күңеле сына җитмәсә ризык,
Бийгә каршы куба бер ризасызлык.

Ни ди, ишет, әнә юмартлар башы:
«Күңеленне киңәйт, и, кысмыр кеше».

Сөйгәненне сөймәс итим дисәң, күр,
Бирим дигәненне бирмә өч тапкыр.

Бирмәсенне вәгъдә итү ярамый,
Вәгъдә итсәң инде, бир син аямый.

[2] Кирмән — кальга эчендәге ныгытылма, кремль.
[3] Сүв — гаскәр.

Сүздә тормаса бәк, ышаныч бетә,
Ышаныч бетсә, һәр шәй артка китә.

Сүлпән зат кирәкми, кирәк өлгер зат,
Сүлпәннәр белән эш сузыла озак.

Бийләргә хезмәттә булган һәр бәндә
Капуда торадыр моңайган хәлдә.

Хезмәткәрнең авыр хәлен, зар-моңын
Бий ишетсен — язсын ярдәм ярлыгын.

Казначы бу эшне озакка суза,
Һәм мескен хезмәткәр өметен өзә.

Кирәгендә тапса бәндә хаҗәтен,
Сычкандай булса да, булыр филгә тиң.

Сиңа ни ди, ишет, бер аксакал карт:
«Тәүдә моңайганны, пәһлеван, коткар.

Вакытында тапса бик теләгәнен,
Кеше барсын бирә, бирми тик җанын.

Сычкан филдәй булыр кирәк чагында».
Бу сүз даир һәммә нәрсә заңына[4].

Инде илбик тапса шундый кешене —
Намуслы, белдекле, ушлы, иплене,

Шуңа биреп була казна байлыгын.
Инанып күтәрсәң аның абруен.

Илбик әйтте: — Белдем, ачтың күземне,
Тагын бер сорау бар — әйтеп бир инде.

Савыт-саба белән эш итүчеләр
Бар. Әйт — нинди булсын ашчы-сучылар.

Ничек шиксез ашыйм аларның ашын,
Таки мәшәкатьсез сау булсын башым.

Хәтта ашау-эчү хәвефтән азат
Түгел, әзерләсә аны шикле зат.

Хәзер шул хакта да миңа сөйләп бир,
Сүзеңне бер тыңлап белим, баһадир.

Сүздә тормаса бәк, ышаныч бетә,
Ышаныч бетсә, һәр шәй артка китә.

ҮГДЕЛМЕШ ХАНСАЛАР[5] — ИЛБИКНЕҢ БАШ АШЧЫСЫ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕН СӨЙЛИ

Җаваплап Үгделмеш әйтте: — И, илбик,
Бу эштә ир кирәк сөлекләр кебек.

Хадимнәрдән рәтле, юньле кешене
Сайлап кую кирәк аш-су эшенә.

Бу эшкә куела тугрылыклы бер
Бөтен, чын вөҗданлы, оятлы шәп ир,

Тугры хезмәт итеп сыналган кеше,
Бәге өчен җанын бирердәй берсе.

Илбиккә хәтәрләр була һәряктан,
Һәм иң мәкерлесе — тәгам, тамактан.

Үзен илбик һәрчак сакларга тиеш:
Белеп эчәргә һәм ашарга тиеш.

Ил башына дошман кеше мең булыр,
Дошманның тозагы һәрчак корулы.

Тугры һәм булдыклы булмаса ашчы,
Хәтәрдә калачак бийләрнең башы.

Монда күпне күргән булу да кирәк,
Ачыны-төчене белү дә кирәк.

Хезмәте күп булса төрле чорларда,
Аңарга ышанып була чыннан да.

Ни ди, тыңла, мәгълүм изге белкәне
(Таң калырлык аның гыйльме-белгәне):

«Кеше нәрсәгә күп эш-хезмәт куйса,
Шуны сөя, гашикъ була ул шуңа.

Гомрен сарыф кылса ни эшкә инсан,
Шул эш аның өчен, гүя, тән вә җан.

Дәвамы бар ■

[4] Заң (КБ-да яң) — «гомуми закон».
[2] Хансалар (фарсыча) — монархның ашау-эчүен хәстәрләүче (хан монда «хан, патша» мәгънәсендә түгел, «ашъяулык» мәгънәсендә килә).

МАҖАРАЛЫ ХИКӘЯТЛӘР

Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль,
борынгы татар әдәбияты белгече, текстолог

Журналда бастырырга тәкъдим ителгән татар әдәби мирасы әсәрләре Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында без әзерләгән (әле дә әзерли торган) «Борынгы татар прозасы» сериясенең 5 нче китабыннан алынды.

Моңа кадәр басылып чыккан китаплардагы кебек («Мәҗмугыл хикәят» — 1994 нче ел; «Фазаилеш-шөһүр яки саваплы гамәлләр» — 1994; «Гыйбрәтле хикәяләр» — 2004; «Кәлилә вә Димнә» — 2008) бу җыентыкта да борынгы Көнчыгыш әдәбиятларыннан — гарәп һәм фарсыдан үтеп кергән, татар теленә тәрҗемә ителеп, күптөрле күчермәләр нәтиҗәсендә төрле үзгәрешләр кичереп, татар тормышы-яшәешенә яраштырып, татарның үз әдәбияты булып киткән, вакыт сынавын үткән сәнгати югарылыктагы, нәфис зәвыклы чын әдәби әсәрләр тупланды.

Җыентыктагы хикәятләрнең күп өлеше төрле маҗаралар, көтелмәгән үзгәрешләр, кискен борылышлар белән тулы сюжетка корылган әсәрләр булганлыктан, китапны «Маҗаралы хикәятләр» дип атадык.

Хикәят — ул урта гасырлар татар прозасының иң танылган, популяр төп жанры.

Хикәят татар әдәбияты тарихында шактый озын чор: чама белән XIV гасырдан башлап, XX йөз башына кадәр вакытны алып тора.

Хикәят әкияткә бик якын, анда еш кына әкият фантастикасы белән хикәя, повесть реальлеге берләшә, бу — үзенә күрә бер синтез; ләкин хикәятнең әкияттән төп аермасы — аның язма матур әдәбиятка тартымлылыгы. Нәкъ менә шуның аркасында анда сәнгатьчеллекнең күп билгеләре чагыла, шуларның иң мөһиме — әдәби телдә һәм стильдә гәүдәләнеш табуы. Ике юллыклы шигырьләрдән торган, әмма хикәяләргә корылган шигъри әсәрләрнең дә кайберләре хикәят дип аталган. Бу җыентыкта да атаклы бер маҗаралы хикәятнең кульъязмада ахыргы өлеше югалган булганлыктан, без аның шигъри вариантын өстәп куйдык.

Күп кенә хикәятләр үзләренең эчтәлекләре, жанр табигатьләре белән хәзерге хикәя, новелла, мәзәкләргә якын торалар. Повесть, роман, мәсәл, әкият, кыйсса, легенда, ләтыйфә, гыйбрәт кебек жанр төрләренә туры килгән, яисә якын торган әсәрләрне дә элек «хикәят» термины белән атаганнар. Шуңа күрә дә без аны рус теленә дә үз яңгырашында «хикәят» дип, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрдек.

Маҗаралы хикәятләрнең үзенә хас композицион схемасы бар. Ул эпизодларның күплеге белән характерлана. Традицион башлам һәм бетем формулалары бар. Сюжетлары катлаулы, кайберләрендә берничә сюжет берләшкән. Сюжет көтелмәгән маҗаралы вакыйгаларның чиратлашуына корыла. Очраклылык — маҗараларның төп сыйфаты, маҗараны китереп чыгара торган сәбәп. Очраклылык шулай ук Алланың тәкъдире белән дә раслана.

Маҗаралы хикәятләрнең тагын

бер төп сыйфаты — үзәктә актив герой булу. Герой һәрвакыт максатына ирешә, җиңеп чыга. Маҗаралы хикәятләрнең жанрын билгели торган төп характерлы сыйфатлар шулар. Үзәккә уңай герой куелу, шәхеснең көчен, акылын мактау — маҗаралы хикәятләрнең төп эстетик кыйммәте.

Җыентыкның бер өлешен гыйбрәтле кыска хикәятләр тәшкил итә. «Гыйбрәт» — хикәяләүгә корылган үзенчәлекле жанр.

Гыйбрәт — нинди дә булса мисалдан, тормыштагы яхшы һәм яман күренешләрдән сабак алу, нәтиҗә ясау, үгет-нәсыйхәт бирүне аңлата. Гыйбрәттә (притчаны без шулай атыйбыз) иң элек нинди дә булса тормышта булган берәр вакыйга сурәтләнә (еш кына ул вакыйгалар мөселман дөньясындагы күренекле шәхесләр белән бәйле була), ахырда исә берике җөмлә белән шуңа нәтиҗә ясала, мөселман әхлагына туры килгән үгет-нәсыйхәт әйтелә. Кайвакытта исә мондый нәтиҗә ясалып та тормый, чөнки сөйләгән вакыйгадан ачыктан-ачык гыйбрәт күренеп тора. Кайбер гыйбрәтле хикәятләрдә маҗара элементлары да күзәтелә.

Шунысы мөһим: бу хикәятләрдә күтәрелгән гуманистик идеяләр, кешене әхлакый камилләштерү проблемалары бу заманда да әһәмиятләрен югалтмый, чөнки бүген дә ул мәсьәләләр — якыннарыңа, дусларыңа, гомумән, бөтен кешегә яхшылык итү, хөрмәт күрсәтү, юмарт һәм киң күңелле булу, яхшылыкның кадерен белү, шәфкатьлелек һәм ярдәмчеллек, намуска, вәгъдәгә, сөйгән ярларга тугрылыклы калу, һөнәр белү һәм эшчәнлек, тырышлык һәм максатка омтылучанлык, гомумән, һәрьяктан әхлакый камиллеккә омтылыш — барысы да бу заман кешесен дә кызыксындыра, борчый, дулкынландыра. Шуңа күрә дә бу әсәрләр хәзерге укучы өчен дә кызыклы, файдалы, гыйбрәтле булыр, дип исәплибез.

***

Җыентыктагы хикәятләрнең күбесе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә»сендә саклана торган кульъязма китаплардан (XVIII-XIX гасырлар) һәм Казан Дәүләт университетының Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә Сирәк китаплар бүлегендә булган ике кульъязмадан сайланып алындылар.

Төрле чордагы күп санлы кульъязма китаплардан алынган бу хикәятләрнең телләре шактый чуар, алар хәзерге заман кешесенә авыр аңлаешлы иске грамматик формалар, диалекталь сүзләр белән чуарланган, гарәп, фарсы алынмалары күп. Шуңа күрә дә без, аларның барысын да хәзерге әдәби телгә адаптацияләп, ягъни яраштырып әзерләдек; бары тик тарихи сүзләр, алыштырып булмый торган дини терминнарны гына калдырып, астөшермәләрдә тәрҗемәләрен, аңлатмаларын күрсәтеп бардык. Кайбер тарихи шәхесләр, географик атамалар хакында киңрәк шәрехләү — аңлатмалар ахырда китерелде. Оригиналларда байтак хикәятләрнең исемнәре күрсәтелмәгән, биредәге исемнәр, эчтәлектән чыгып, безнең тарафтан шартлы рәвештә куелды. Шулай ук әүвәлге телебезнең кабатланмас ямен, кыйммәттен укучыларга җиткерү өчен хикәятләрнең стиль-өслүбен, бәян итү рәвешен оптималь төстә сакларга тырыштык.

Гасырлар сынавын үткән бу әсәрләрдәге мәңге сүрелмәс кешелеклелек идеяләре, яхшылык белән явызлыкның көрәше, кешедә камил әхлак һәм иман тәрбияләү кебек, хәзерге заман өчен аеруча актуаль булган мәсьәләләр берәүне дә битараф калдырмас, бик яхшы сабак бирер, укучылар тарафыннан яратып укылыр, дип ышанып калабыз. ■

БИМ ШӘҺӘРЕ ТӨЗҮЧЕСЕ ҺӘМ ГҮӘШИР ПАДИШАҺЫНЫҢ ВӘЗИРЕ

Риваятьләр сөйләүчеләр һәм хикәятләр күчерүчеләр шуны бәян иттеләр:

Кирмән[1] тирәсендә борынгы бер шәһәр бар иде, аны Бим[2] диярләр иде. Эчендә бер бик оста төзүче бар иде, шул һөнәрдә тиңдәше юк, дөньяда мәшһүр иде. Әмма, шуңа карамастан, эшсез йөри, кулына һичнәрсә керми иде. Башка төзүчеләр әллә ни белмәсәләр дә, һәрвакыт эштә иделәр.

Ул төзүченең тугрылыклы, намуслы бер хатыны бар иде, чибәрлектә, сөйкемлелекә тиңе юк иде. Беркөн төзүче хатыны белән аулакта сөйләшеп утыралар иде, байлык-юксыллык хакында сүз чыкты.

Хатын әйтте:

— И, шәһрияр! Еллар кичә, һичбер эшкә ябыша алмыйсың, Ходай көндәлек ризыкны бирүче, кодрәтледер, ризыгыбызны ким итмәс. Әмма, шулай да, кулаякны тибрәтә тору яхшы булыр.

Төзүче әйтте:

— Бу җирдә юк-бар эшләр генә бар, юк-бар, вак-төяк эшләргә ябышырга минем теләгем юк, башка шәһәрләргә сине калдырып китәсем килми, — диде. — Әгәр каршы килмәсәң — китәрмен, башка бер шәһәрдә эш башкарырмын, аз гына вакытта күп нәрсә кулыма кертер идем, — диде.

Хатыны:

— Бу җәһәттән күңелеңне тыныч тот, бу дөньяда тыныч, имин торырга мөмкинлегем бардыр, Хак Тәгаләнең юмартлыгына өметем бар. Әгәр еллар буе югалып торсаң да синнән вә Хак Тәгаләдән оялачак җирдә булынмам, — диде.

Төзүче бу сүзләрне ишеткәч, күңеле хуш булды, догалар кылды, сәфәр кирәкярагын әзерләде, юлга керде. Шулвакыт хатыны төзүчегә саф һәм таза самшит[3] ботагы бирде:

— Миннән сиңа бу ядкяр булсын, әгәр моны таза күрсәң — мине исән-сау, тугрылыклы дип белерсең, әгәр сулган булса — тугрылык даирәсеннән чыккан булырмын, — диде.

***

Төзүче юлга чыгып, тукталыш арты тукталышлар үтә-үтә Гүәшир шәһәренә килеп җитте, һөнәрчеләр турында сорашты. Бер кеше әйтте:

— Бу шәһәрнең төзүчеләре падишаһ зинданында тоткынлыкта яталар, — диде. Төзүче моның сәбәбен сорады, әйттеләр:

— Падишаһ бик зур һәм кыйммәтле бина төзергә боерды, төзүчеләр ул куйган шартлар буенча эшли алмадылар, шуңа күрә падишаһ зинданга салды, сәбәп шулдыр, — диделәр.

Төзүче зиндан юлын сорады. Күрсәттеләр, зиндан ишегенә барды, керергә рөхсәт сорады. Эчкә керде, төзүчеләрне тапты, белештеләр, сораштылар. Кем икәнен белгәч, остага хөрмәт күрсәттеләр һәм әйттеләр:

[1] Кирмән — Иранның көньягындагы шәһәр.
[2] Бим — Иранның көньягындагы шәһәр. Бим хәзер «Бам» рәвешендә йөртелә.
[3] Самшит — көньякта үсә торган кыйммәтле агач төре.

— И, җиһанның остасы! Сине Хак Тәгалә безне коткару өчен биргән икән, хуш килдең. Бел һәм аң бул: бу падишаһыбыз безгә бер күшек[4] һәм сарай төзергә боерды. Без: «кулыбыздан килмәс» — дидек. Безгә әйтте: «Инде күпме заман шәһәремдә төзү эшләре башкарасыз, минем эшем булгач кына кире чигенәсез. Эшемне башкарыгыз, төзегез!» — диде. Эшне башлап җибәрү өчен акчалар бирде. Әмма бу эш һичберебезнең кулыннан килмәде. Шул сәбәптән безне зинданга боерды. Инде менә күпме вакытлар төрле җәфасын чигәбез. Килдең, инде эшебезне җайга сал, — диделәр. Оста әйтте:

— Күңелегезне хуш тотыгыз. Минем турында падишаһка белдерегез һәм эшкә алыныгыз, иншаллаһ, падишаһ күңеленә ошардай эш башкарырмын, — диде.

Төзүчеләр шат булдылар. Оста падишаһка җитеште, тиешле мактау сүзләрен әйтте, лаеклы догалар кылды. Мәлик аны сыйлады, кадер-хөрмәт күрсәтте.

— Минем өчен лаек булырлык бер күшек һәм бер сарай төзесәң икән, — диде. Оста:

— Падишаһның хөкеме баш өстемә, боер, эшлим, — диде. — Падишаһ һәм барча халык гаҗәпкә калсыннар, — диде.

Боерды, кирәкле коралларны әзерләделәр. Эшкә мәшгуль булдылар. Мәлик остага зур вәкаләтләр бирде, хилгат[5] кидерде, калган төзүчеләрне аңа хезмәт итәргә боерды. Кыска гына вакытта падишаһларга хас бер сарай, бер күшек һәм әйван[6] төзеде ки — һичбер мәмләкәттә моның кебек юк иде. Падишаһ һәм барча халык күреп, сокландылар. Падишаһ шат булды. Төзүче остага бер янчык алтын һәм үзе генә кия торган алтынлы бер хилгат бирде. Болардан тыш та күп нигъмәтләр багышлады, һәм тагын «сарайда утыртачакмын, күп нигъмәт бирәм», дип вәгъдә итте, һәм даимән падишаһ вәзирләренә һәм хаҗипларына останы үрнәк итеп, аның акылын, фәһемен, холкын мактап сөйләр иде.

— Вәзирлеккә лаектыр, белемледер, моны җибәрергә ярамас, йорт-җир бирәм, моның кебек кешене илдән чыгару яхшы булмас, — диде.

Бу сүзләрне падишаһ сөйләде, тора-бара арттырып та җибәрә башлады.

Ул падишаһның өч вәзире бар иде. Бу сүздән бик каты кимсенделәр, төзүче остага дошман булдылар, мәкер белән йә үтерергә, йә качып китәргә мәҗбүр итәргә уйладылар.

Көн дә килеп, яңа төзелгән сарайны карар иделәр, бу эшне бер-бер төрле гаебен эзләрләр, падишаһ янында останы яманлар иделәр. Ләкин падишаһның карашы үзгәрмәде. Һичбер төрле юл белән сылтау табалмыйча, гаҗиз калдылар.

***

Бу оста ул күшектә бер бүлмә төзегән иде, чиксез күркәм иде. Падишаһ аны затлы келәмнәр, паласлар белән бизәтте, анда утырыр, әңгәмәләр кылыр иде.

Беркөн оста падишаһ белән сөйләшеп утырганнан соң, шул бүлмәдә ялгызы калды. «Ни булыр иде: бу бүлмә минеке булса, хатыным белән бергә утырсам иде», — дип, сагышланып утырды, самшит ботагын кулына алды, елады, утыра торгач, йокысы килде, ятты, йоклады.

Алланың тәкъдире белән, вәзирләрнең берсе аның шул хәлдә икәнен белде, сөенде:

— Төзүчене падишаһ күзеннән төшерергә яхшы форсат һәм яхшы сылтау таптым, — диде. Шунда ук шәраб, бер шәш[7] кәбап[8], бераз кабымлык әзерләде, тәхет һәм урын-җиргә, келәмнәргә һәм эскәтерләргә шәраб түгеп чыкты, шәраб

[4] Күшек — җәйге сарай, павильон.
[5] Хилгат — асылташлар белән бизәлгән, парчадан тегелгән, башка киемнәр өстеннән киелә торган кыйммәтле өс кийеме, халат.
[6] Әйван — ачык галерея.
[7] Шәш — ит кыздыра торган тимер чыбык.
[8] Кәбап — шәшкә тезеп кыздырылган ит, шәшлек (шашлык).

эчә торган пыяланы ватып, шунда ташлады һәм ул урынны тәмам пычратып, буяп бетерде; өстеннән ишекне бикләп, шаһ хезмәтенә китте.

Шаһ катында төзүчене мыскыллап, телен ачты һәм агулар чәчте. Әйтте:

— И падишаһ! Ышанычлар күрсәткән остаң падишаһның үз җирендә, мендәр-ястыклар өстендә лаякыл исереп, аунап ята, эчкән һәм коскан, тәхет һәм җиһазлар буялып беткән, бөтен җирдә кабымлыклар тузып-таралып ята. Бу оятсызлык безгә хуш килмәде, барып, бу ахмаклыгы өчен җәзасын бирергә ният иттек. Бу вакыт уйладык, «падишаһның күңеленә хуш килмәс» дидек, шуңа күрә тукталып тордык, — диде.

Падишаһ бу сүзне ишетеп, борчылды:

— Бу сөйләгәнегез дөрес булса — аның бәхетсезлеге билгеседер, — диде. Вәзирләр әйттеләр:

— Әгәр падишаһның бу маҗараның булуында шиге бар икән, ышанычлы кешеләрен җибәрсен, хәлне ачыкласын, — диде.

Падишаһ ышанычлыларын бирде. Бардылар, күрделәр: хәл харап. Килделәр, падишаһка хәбәр бирделәр. Останы китерделәр, хурладылар. Падишаһ төзүчегә әйтте:

— Әй, үзеңнән хәбәрсез булып, нинди ачудан моның кебек оятсызлыкта булдың?! — диде. — Минем шундый кадерле булган урынымда миннән соң син утырдың, эчтең, хараплыклар иттең. Сиңа шундый бер җәза бирәм ки — илләр гыйбрәт алыр, — диде.

Гөнаһсыз төзүче чарасыз булып, башын җиргә куйды, әйтте:

— И, җиһанның падишаһы! Хак Тәгалә үзе белер, бу сез әйткән эштән минем хәбәрем юктыр. Бары шуны беләм: дөньяда бер хатыным бар, тугрылыклы һәм тәкъвадыр, шуңа күрә күңелем аңа бәйләнгәндер. Киткәндә бер самшит ботагы бирде, «сиңа ядкяр булсын», диде. «Бу сулса, аягым тугрылык даирәсеннән тышка басканын белерсең», — дигән иде. Бу көн ул сарайга кердем, ул матур, яхшы бүлмәне күрдем һәм күңелемдә: «Минем дә моның кебек урыным булса иде, мин анда сөйгәнем белән утырсам иде», — дип уйладым. Самшит ботагын кулыма алдым, уйланып, сагышланып утырдым. Шул арада йокы алган, йоклап киткәнмен. Шуны гына беләм: синең ышанычлыларың килделәр, мине тоттылар, шулай мыскыл итеп катыңа китерделәр. Билләһи газыйм, башка хәбәрем юктыр. Мәлик бүлмәсендә миннән кабымлыклар калган, дигән сүз чеп-чи ялгандыр, тупа бер яладыр. Ни шәраб эчмәктән, ни кабымлык, ни азык-төлектән һич хәбәрем юктыр, — диде, елады, аннан тынып калды.

Падишаһның остага эче көенде, дуслыгы күңеленә килде. Әйтте:

— Әй, оста! Син шәраб эчмәдеңмени? — диде.

Оста әйтте:

— Һич тә эчмәдем! — диде.

Падишаһ боерды, авызын иснәделәр, «һичнәрсә юк», диделәр. Падишаһ вәзирләрнең ялган сөйләгәннәрен белде, башка нәрсә әйтмәде.

— Барыгыз, кайтыгыз. Бу эштә фикер итәм, — диде, төзүче оста белән өенә китте.

Вәзирләр эшнең ни белән бетәсен аңыштылар, иртәгесен фикергә мәшгуль булдылар: төзүчене аулак өйгә чакырыйк, эчертик, исертик, шул хәлдә торган җиренең, гаиләсенең һәм дус-ишләренең билгеләрен алырбыз, кем икәнлекләрен белербез. Аннан соң күршеләре авызыннан төзүчегә хат язарбыз. Эчтәлеге шул булсын: «Хатының оят эшләргә кереште, тиз арада өеңә кайт, хәлнең ни икәнен күр, юкса, йорт-җиреңнән аерылырсың, вәссәлам». Бу төзүченең хатынына мәхәббәт бар, әлбәттә, ул язуны укыгач, монда торырга карар итмәс, торыр, китәр, аның аркасында башыбыз авыртуыннан котылырбыз, диделәр.

Шунда ук мәҗлес кирәк-яракларын әзерләделәр. Төзүчене чакырдылар, ашаттылар-эчерттеләр, исерттеләр, эч серләрен алдылар. Ул алдан уйланган хат-

ны күршеләре авызыннан яздылар, мөһерләп, берничә көннән соң бер ят кешегә биреп, төзүчегә җиткерделәр.

Төзүче хатны алды, өенең билгеләрен һәм күршеләренең исемнәрен язуда күргәч, дөрес дип санады. Торды, падишаһ катына барды, җир үпте, өенә кайтырга рөхсәт сорады. Падишаһ аны вәзирләр сүзеннән кәефе киткән, дип санады, аннан үтенде:

— Аларның сүзенә карама, китмә, — диде.

Төзүче хатны күрсәтте. Мәлик әйтте:

— Ник кайгырасың, әгәр хатының ярамас булды исә, җанына ләгънәт укы. монда сиңа изге күңелле, саф хатын табып бирәм, йорт-җир иясе итәм, — диде.

Төзүче:

— Булмас, бу эш аннан булачак эш түгелдер, — диде.

Болар бу сүздә икән, вәзирләр килделәр, падишаһ сүзен кабатладылар:

— Китеп нишләрсең, без үзебез барып, ул хатынның хәлен белербез, аңа нигә яңадан кайтып торырга, ярамас нәрсәне ни өчен телисең? — диделәр. Төзүче әйтте:

— Минем самшитым тазадыр, димәк, хатыным намуслыдыр. Әмма мине бу хат шиккә төшерде, шуның өчен мәликтән китәргә рөхсәт сорыйм, — диде.

Шулвакыт вәзирләр:

— Ул хатын белән сыйлашып, күңел ачып торабыз, ә инде билгеләрен сорасагыз — әйтеп бирәбез, — диделәр. Төзүченең исерек вакытта әйткән билгеләрнең һәммәсен сөйләделәр: төзүченең өе кайда икәнен, хатынының, хезмәткәрләренең исемнәрен бәян иттеләр.

— Әгәр падишаһ боерса, беребез бара, яңа билгеләр китерә, — диделәр. Бу сүзләрдән соң төзүченең фикере үзгәрде, падишаһ уңында җир үпте, дога кылды.

— Болар моның кебек сүз әйттеләр, инде шартыбыз шул булсын: әгәр болар барып хатынымның бер ачык билгесен китерсәләр — бөтен сүзләре растыр, мин аңа талак бирермен, үзем монда торырмын, калган бөтен гомеремне падишаһ хезмәтендә кичерермен, — диде.

Вәзирләр бу шартны барысы да кабул иттеләр, ләкин тагын шундый шарт куйдылар: «Падишаһ төзүчене ун көн төрмәгә салсын, без ул хатыннан билге китергәнче», — диделәр.

Падишаһ останы төрмәгә ябарга боерды. Вәзирләрнең берсе әзерләнде, күп алтын вә җәүһәрләр, хилгатьләр алды, Бим шәһәренә юнәлде. Шәһәргә килеп җиткәч, ишеткән билгеләре буенча оста торган мәхәлләгә барды, кунакханәдә кунды.

***

Мәгәр ул мәхәлләдә Дәлилә[9] кебек бер карчык бар иде, меңләп шәкерте, шымчылары бар иде. Вәзирнең килгәнен белеп, янына килде, хезмәт итте. Вәзир аңа якты йөз күрсәтте.

— Ни кеше син? Безне кайдан белдең, күрергә килдең? — диде.

Карчык:

— Хезмәтчемен, бу мәхәлләдә торамын, ирләргә коллык итәмен, кулымнан килгән эшне башкарамын, алар миңа нәрсә дә булса бирәләр, шуның белән көн итәмен. Вәзирнең бу урынга килгәнен ишеттем, хезмәтенә килдем. Әгәр минем кебек карабашка[10] эш булса, кулымнан килгәнчә тырышыр, башкарыр идем, — диде.

Вәзир әйтте:

— И, ана! Бик читтән килгән кешемен, бу шәһәрдә берничә көннәр торырга килдем. Әгәр бер гүзәл тапсаң, беркеме дә булмаса, безгә коллыкчылык итсә, аңа

[9] Дәлилә — күп хикәятләрдә сурәтләнгән, хәйләкәрлеге белән дан тоткан хатын.
[10] Карабаш — кол яки хезмәтче хатын. Яулыксыз йөргәнгә «кара баш» дигәннәр.

да, сиңа да мин дә меңнәрчә коллык итәрмен, — диде. Карчык фикер итте, әйтте:

— Төзүченең хатыны бу эшкә ярар, ул гаять күркәм һәм сөйкемледер, — диде. Вәзир:

— Мин аның сыйфатларын ишеткән идем, миңа ул ярар, әгәр аны катыма китерсәң, ни сорасаң да бирәм, — диде.

Карчык:

— Башым вә күзем өстенәдер! — диде.

Торды, төзүче өенә барды, әйтте:

— Әй кадерлем! Бер олы кеше шушы мәхәлләдә кунып ята, синең белән бергә булырга күңеле тели. Әгәр бер-ике кичә аның белән аулакта булсаң, назлар күрсәтсәң, ни булыр икән? Ул күп бүләкләр белән килгән, әгәр боерсаң, барам, алып киләм, — диде.

Төзүченең хатыны бу сүзгә күңеленнән бик каты гарьләнде. Шулай да ачуланмады, фикер итте: «Монда Хак Тәгаләнең бер хикмәте бардыр. Ул яшерен җирдән ни гаҗәп эш пәйда булды», — дип уйлап, карчыкка:

— Фәрман синекедер! — диде. Карчык шат булды, торды, кайтып китте.

Төзүче останың бер колы һәм бер карабашы бар иде, аларны өйдә калдырып киткән иде. Бу ханым җариясенә[11] әйтте:

— Карчык вәзиргә хәбәребезне җиткермәс борын, белешеп кайт, ул кешенең әхвәлен бел: ник килгән, кайда китәр? — диде.

Җария барды, вәзирнең хезмәткәрләреннән сорады. Әйттеләр:

— Бу кеше Гүәшир падишаһының вәзиредер, үз ниятләре белән килде, мөһим эше бар бугай, әмма безгә мәгълүм түгелдер, — диделәр.

Җария кайтып, ишектән хәбәрен ханымга әйтеп бирде. Ханымга хәбәр килгән иде, иренең Гүәширдә икәнлеге, күшек һәм сарай төзегәне һәм падишаһ янында дуслык мөнәсәбәтләрендә торуы мәгълүм иде. Бәс, ханым җариядән бу хәбәрне ишеткәч, уйланып утырды, аңлады, вәзирнең ни өчен килгәнен белде. Аңа тиешле гамәл кылырга, нык торырга уйлады. Голәменә[12] һәм җариясенә:

— Гафил булмагыз, уйлап эш итегез, серне саклагыз. Күрербез, Кадыйр[13] ни тәкъдир иткәндер.

Бәс, белер бу сүздә икән, карчык килеп керде, бер кисәк алтын алып килгән икән, вәзирдән сәлам җиткерде. Төзүче хатыны бүләкне күрде, сөенде, аяк өсте торды, сәламгә җавам бирде. Карчыкка әйтте:

— И, миһербанлы ана! Ул олыга бездән сәлам әйт, шуны җиткер: без түбәнчелекле кәнизәгегез күпме кирәк аларның күңелләрен хозур итә. Әмма төзүче сәфәргә киткәннән бирле бер дә өйдән чыкканым юк. Ике шартым бар: берсе шул — ул минем өемә килсен, икенчесе — ялгыз килсен. Шулвакыт бер-беребез белән аулакта сөйләшеп утырырбыз, — диде.

Карчык кире кайтты, сәламне һәм хәбәрне җиткерде. Вәзир кабул итте:

— Шулай булсын! — диде. Аннан соң төзүче өенә шәм һәм шәраб җибәрде. Төзүче хатыны боерды, төрле-төрле ризыклар пешерделәр, ширбәтләр хәзерләделәр.

Кич җитте. Төзүче хатыны ахшам намазына кереште, намазлыгы өстенә утырып, укып торганда карчык килеп керде:

— Рөхсәт бармы? — диде. Төзүче хатыны:

— Ястү намазын укыганнан соң, караңгыда килсен, — диде.

Кыскасы, вәзирне китерде, үзе кайтып китте. Төзүче хатыны вәзир килгәнгә шатланганын белдерде, эчкәре алып керде. Вәзиргә каршы аяк өстендә торды,

[11] Җария — хезмәтче кыз.
[12] Голәменә — хезмәтче ир-егет.
[13] Кадыйр — Аллаһның мактаулы исеме: кодрәтле көчле.

хезмәтләр кылды. Вәзир күрде: ай сыман бер гүзәлдер, нур бөркелеп торадыр, хәйран булды, тәкәллеф белән: «Утыр яныма», — диде. Ханым белән утырды, назлы сүзләр сөйләде, ханым да аңа кадер-хөрмәт күрсәтте. Бераздан ширбәт китерделәр, ханым татып карады, аннан вәзиргә сузды, аннан соң тәгам китерделәр. Табаклар күтәрелде, аннан шәраб китерделәр. Вәзир ханымнан бергәләп эчүне үтенде. Ханым әйтте:

— Синең хезмәтеңдә эчәрмен, әмма бу кичә әле азат булыйм. Артык кыюланып китәрмен, дип куркам, кардәшләрем килеп чыксалар, оятлы булырмын, — диде.

Вәзир бу сүзне тыңлады, ул кичә азат куйды. Җария килде, сакыйлык итте[14]. Берничә касәдән соң шәрабка йоклата торган дару салды. Вәзир:

— Әле бу кичә кочакламый-нитми генә күңел ачыйм, киләсе очрашуда тәнен күрермен, бөтен билгеләрен дөрес күрермен, — дип фикер итәр икән. Шул арада дару әсәр итте, һушсыз булды.

Хезмәтчеләр вәзирне күтәрделәр, өй янында бер бакча бар иде, анда бер баз бар иде, өстендә бикләнә торган капкачы бар иде, вәзирне шул базга куйдылар, капкачны бикләделәр, аннан азат булып, урыннарына яттылар, йокладылар.

***

Менә таң атып, кояш җиһанны нурландырды. Вәзир исереклек йокысыннан уянды, дару тәэсиреннән котылды, күзен ачты, үзен бер базда күрде.

— Бу ни икән? Бу нинди бәла, нинди вакыйга икән? — дип торды. Йөрде, капкачны күрде, ачарга тырышып карады, булдыра алмады, өметен кисеп утырды.

Төзүче хатыны бакчага керде, бер җирдә утырды. Җария баз янына килде, вәзир аны күреп, кычкырды:

— Бу базда нишләрмен?! — диде. Җария:

— Ханым синең белән аулакта булды бит, — диде. — Кардәшләре авылдан килделәр, сез исерек идегез, бернәрсә тоймадыгыз, алар кермәс борын, сезне монда яшерде. Сабыр ит, кардәше киткәч, сезне өйгә илтербез, бергә утырырсыз, — диде. — Таңга кадәр утырдылар, сөйләштеләр, ханымны алдылар, авылга киттеләр, туй бар икән, бер атна шунда булса кирәктер, — диде.

Вәзир бу сүзне ишеткәч, ни эшләргә дә белмәде:

— Бу нинди сүз?! Шул кирәк: капкачны ач, чыгып китим, — диде. Кәничәк әйтте:

— И, хөкемдәр! Минем кулымда ни бар?! Мин бер карабаш кешемен, ханым ачкычны үзе белән алып китте. Ул килгәнче түзеп тору кирәктер, кайбер кешеләр бер теләк өчен бер ел йөрерләр, син аңлы кешесең, бер атна сабыр итмәссеңме? Түз, ханым бер килер, диде.

Вәзир бу сүздән бик нык борчылды, «аһ!» итте:

— Аһ, ялгыштым. Кирәкмәс сүзләр сөйләдем, кирәкмәс хәрәкәтләр ясадым, бу хәлгә төштем, әмма дә каты төштем… — диде.

Кыскасы, вәзир өйләгә тикле ач һәм сусыз утырды, хәле бетеп, тәкате так булды, ягъни түземе бетте.

Төзүченең хатыны җарияне яңадан бакчага җибәрде:

— Кара, дошман нишләр? — диде.

Вәзир, җарияне күргәч, еларга һәм ялварырга кереште:

— Кешелек ит, мине бу зинданнан коткар, гомерем буенча бүтән монда килмәм. Мин бер юлчымын, читтән килгән кешемен, миннән ни телисең? — диде. Җария:

— Ул эш минем кулымнан килмәс. Үгет бирәм — тотарсың. Кичә лаякыл яткан вакытыгызда безнең бер усал колыбыз артыңны «өшкерде», боерсаң, су китерәм, өстеңә түгәм, пычранган килеш утыру читен булыр, — диде. Вәзир:

[14] Сакыйлык итү — эчемлекне салып, касәләрне тутырып тору, кыстап эчертү.

— Аһ, бу барысыннан да артыктыр, бер мордар кол мине мәсхәрә иткән, — дип, үзен-үзе җирдән-җиргә орды...

Ханым җариягә кушты:

— Куеп китмә, көлә бир, тамаша итәм, — диде. Җария кире бакчага керде, әйтте:

— И, хуҗа! Бибием[15] сиңа күп коллык итте, туйдыңмы? — диде. Вәзирнең көче киселде, кычкырды:

— Ләгънәт сиңа, тагын да бибиеңә! — диде. — Вә ул алласыз төзүчегә, аның шомлыгыннан бу казага очрадым, — диде.

Ханым бу сүзне ишеткәч, әйтте:

— Мин сезгә әйтмәдемме: «Бу сүзнең, әлбәттә, бер сере бардыр», — дип. Тәңре Тәгаләгә мин зәгыйфәгә гыйнаяте[16] бар икән — мине дошманнар мәкереннән коткарды, — диде. Шундук йөзен җиргә куйды, сәҗдәгә тезләнеп, шөкерләр итте.

Әйтте:

— Мин түбәнчелекле җарияңә мәгълүм булды: бу эш минем иремә дошманлык йөзеннән булган икән, бу кеше явыз ният белән мине аздырырга килгән икән. Чарабыз шул: моны яхшы саклыйк, иремнән хәбәр, йә үзе кайтып җиткәч, эшнең нидә икәнен белербез, — диде. Аннан соң җарияне тагын бакчага җибәрде. Вәзир елады, коткаруын үтенде. Җария шундук җавап бирде:

— Бу өстеңә капланган капкачны Тәңре ачса — чыгарсың. Миңа чыгарырга әйтмәделәр. Йорт-җиреңнән нигә аерылдың, төзүчене ни өчен сүктең, эш нидә, чынлыкта ни булды соң? — диде.

— Әгәр теләсәң, турысын сөйлим, тик миңа белдер: бибиең кайда?

Карабаш әйтте:

— Мең тапкыр әйттем ич: кардәшләренә туйга китте, ачкычны үзе белән алды, миңа васыять итте; ул кайтканчы янныңа килмәскә, һәм «кардәшләремне китереп, бу ирдән морадымны алам», дип китте.

Вәзир сорады:

— Миндә ни максады бар?

Җария әйтте:

— И, хуҗа! Колак тот, хәлне сиңа белдерәм.

Вәзир:

— Әйт! — диде.

Җария әйтте:

— Минем сиңа эчем көйде. Кулымнан килсә, коллыклар итәр, гафулар сорар идем. Әмма нишлим — кулымнан килми. Бу минем бибием шулхәтле күп мәкерледер, эче тулы хәйләдер, ирләрне сөймәс бер сихерчедер. Бу сиңа иткәнне инде йөз кешедән артыкка итте. Бу базны да шул эш өчен казытты, һаман тозак корыр, синең кебекләрне аулар. Карчык та моның коралыдыр, тәмле сүз, якты йөз белән агуны күктән иңдерер. Бу минем бибием бөтен тапканын бер өйдә куяр, алтын вә көмештән ни булса — барсын алыр, анда куя барыр. Аннары кардәшләрен чакырыр, канәчкеч җиде кардәше бар, килерләр, ул бичара тоткынны җиргә тотып атарлар, өстеннән чират үткәрерләр. Аннан соң бер бикле коеда эшкә кушарлар, аннан чыгарырлар, бер төпсез коесы бардыр, шунда салдырыр. Мин бу эшләргә хәйранмын, кызганыч ки, аларны мин тыя алмыйм, кулымнан һичнәрсә килмәс. Менә мин рас сөйләдем, син дә минем кебек дөресен сөйлә һәм миңа әйт: кайдан килдең, кайда китәсең һәм бу шәһәргә ник килдең? Әгәр дөресен сөйләсәң, барам, өйдә ни гомердән бирле бу юл белән казанган мал бардыр, аны алам һәм сине качырам, бергә китәрбез, — диде. Вәзир бу сүзләрне ишетте, «аһ» итеп әйтте:

[15] Биби — хуҗа хатын, хуҗабикә.
[16] Гыйнаять — булышлык, кайгырту.

— И, кыз! Миңа ярдәм ит, мине ул упкыннан коткар! — диде. Җария әйтте:

— Инде хәлнең ничек булганын, тугрысын сөйлә, аннары мин — җария — синең эшеңә мәшгуль булырмын, — диде.

Вәзир мескен хикәятен — төзүче остага хөсетлек итеп, падишаһка чакканын, ахырда падишаһ белән вәзирләрнең үч алырга карар итүләрен тәмам сөйләде. Төзүченең хатыны ул сүзләрне ишетеп, гаҗәпкә калды. Аннан җария:

— Хәзер барам, сизенгән җирләремнән ачкычны эзлим, аннары киләм, сине коткарам, бергә китәрбез, — диде.

Китте-барды, икендегә[17] тикле йоклады. Икендедән соң торды, кире бакчага барды. Вәзир яңадан кычкыра башлады:

— Кайда ачкыч?! — диде. Җария:

— Шулвакыттан бирле эзләдем, эзләмәгән җир калдырмадым, таба алмадым. Шулвакыт бибиемнең кардәше килде, минем белән тарткалашты: «Кичәге ирне миңа китер, бер эш күрсәтәм, берьеллык ачуны аннан чыгарам», — диде. Мин бер сылтау табып, көчкә котылдым, «хәбәрем юктыр», дидем.

Әйтте:

— Һай! Ни сөйлисең, туганым мине шул эш өчен көндерде, әлбәттә, мин дә, юлдашларым да аннан ачуыбызны алабыз, — диде. Шулай сөйләшкән арада, исереклеге җиңде, ятты да йоклады. Куркамын, айныгач килер, сиңа әйткәнен эшләр, — диде.

Вәзир бу сүзне ишетте, «ләхәүлә»[18] укыды. Аннан җария:

— Мине бу кич бүтән чакырма, — диде.

Вәзир әйтте:

— Ни өчен?

Җария:

— Шуның өчен: бибиемнең кардәше һәм җәмәгате бик усаллар, кан эчкечләрдер, алар монда булганда, кулымнан эш килмәс, — диде. Вәзир өметен кисте.

Аннары:

— Ачлыктан үләрмен, — диде.

Җария:

— Бибием авылга киткәндә ун батман[19] икмәк һәм ун батман мамык калдырды. «Мамыкны язсын, чистартсын, эрләсен, әгәр шуны эшләсә, әҗеренә икмәк бирерсең, — диде. — Күршеләрдә дә эшләр кеше күп, тик синең хәтереңөчен генә бирәм, мамыкны эшкәрт, икмәкне аша», — диде. Вәзир чарасыз булды:

— Бер батман икмәгең белән бер батман мамыкны китер, эшкә мәшгуль булам, — диде.

Җария икмәк һәм мамыкны тимер рәшәткә аша ташлады, китте. Бер атна буе кире килмәде. Вәзир мамыкны эшкәртер, эрләр, икмәкне ашар иде.

***

Бу якта вәзирнең нукәрләре хәлне белмәделәр, вәзирнең эзен-билгесен тапмадылар. Аннан әйттеләр:

— Бу хәлне ачсак, белдерсәк, безне тотмагайлары, «хуҗагызны нишләттегез!» диярләр, казага очрарбыз. Шул яхшы булыр: таралыйк, һәрберебез бер якка китик, — диделәр, төрле якка сибелделәр, атларны, дөяләрне һәм тукымаларны үзләре белән алып киттеләр.

Вәзир мамыкчы булып китте. Вакыты-вакыты белән җария янына килеп, сакалыннан көлер иде.

[17] Икенде — өйлә белән ахшам (кичке намаз) арасындагы вакыт.
[18] Ләхәүлә — «Ләхәүлә вә лә куәтә иллә Билләһи-л-галийу-л-газыйм» («Бөек вә олуг Аллаһтан башка һич көч юктыр») догасының беренче сүзе.
[19] Батман — авырлык үлчәү берәмлеге, 2,5-8 килограммнар арасында.

***

Килдек бу якка. Гүәшир мәлиге күрде: вәзире ун көндә килмәде.

— Ни булды, гаҗәп? — диде. Баягы вәзирләр:

— Мәгәр төзүченең хатыны белән кавышулары хуш булды, берничә көннән соң кайтып җитәр, — диделәр.

Бу вакыт тагын ун көн үтеп китте, вәзир кайтмады. Падишаһ вәзирләрне шелтәләде. Вәзирләрнең берсе тагын рөхсәт сорады:

— Барыйм, хәлнең ни икәнен ачып кайтыйм, — диде.

Бу тагын китеп, ун көн торды. Бер-ике нүкәре белән Бим шәһәре ягына йөзләнде. Берничә көннән Бим шәһәренә килеп җитте. Төзүчедән билгеләрен алган мәхәлләдә кунды.

Карчык, гадәтенчә, килде, хезмәт итте. Вәзир:

— Ни кеше син? — дип сорады. Карчык үзен аңа белдерде:

— Олыларга хезмәт итәмен. Бер олы монда килгән иде, аңа хезмәт иттем, ни кирәк булса шуны эшләдем, шуның өчен миңа күлмәк багышлады. Бу җирдән шөкерләр кылып китте. Менә сезгә килдем, хезмәт итәм, ни бар исә, шуны башкарам, — диде.

Вәзир сорады:

— Ул кеше нindиерәк кеше иде?

Карчык билгеләрен сыйфатлап бирде. Вәзир үзенең дусты икәнен белде. Сорады:

— Инде ул кеше кайдадыр?

Карчык:

— Кайда киткәнен белмәдем, — диде. Вәзир күңеленнән: «Шаять, башка юлдан кайтып киткәндер, шуның өчен очрашмадым», — диде. Аннан карчыкка әйтте:

— И, апа! Мин берничә көн монда булам. Минем әгәр йомышым бар икән, сиңа әйтсәм кирәк, синең белән килешербер, син миңа бер гүзәл табып бир, — диде. Карчык:

— Монда күршедә бер гүзәл бар, ире төзүчедер, сәфәрдәдер, ул теге әүвәл килгән олы белән күрешеп, күңелен күргән иде. Боерсаң, синең өчен дә сөйләшермен, — диде. Вәзир әйтте:

— Ул әйткән кешең минем кардәшемнең углыдыр, аннан мирас итеп, ул гүзәлне миңа җиткерсәң, яхшы булыр иде, — диде.

Карчык торды, яңадан төзүче хатыны янына барды. Әйтте:

— И, кызым! Син миңа җанымнан газизсең, галәмнең яхшылыкларын синең өчен бирер идем. Бел: бер кеше килде, баягы кешедән дә мең тапкыр баерак, хезмәт итәр, сине сорар. Боерсаң, барам, биргән бүләген китерәм, — диде.

Төзүче хатыны бу сүзне ишеткәч, белде: вәзирләрнең берседер, хәбәрләр ишетергә килгән.

— Ярар, хуш килде! — диде, аннан карчыкка әйтте:

— И, апа! Үзең беләсең, минем тышка аяк басканым юк, чөнки дошманым күп. Әгәр ул кешенең теләге бар икән, монда үзе килсен, — диде.

Карчык бу сүзне вәзиргә кайтып әйтте. Вәзир кабул итте.

— Кулыма мәгълүмат керер, мәлик катында сүзем өстен булыр, — диде. Шундук бер кисәк кыйммәтле тукыманы карчык артыннан биреп җибәрде.

Ул да төнлә ханым катына барды. Элгәреге хәлләр аның да башыннан кичте. Баз ишегенә китерделәр. Тоткын вәзир «авылдан хатынның кардәшләре килде», дип уйлады, бер почмакта шыпырт кына утырды. Икенче вәзирне дә баскычтан аска тәгәрәтеп төшерделәр, капкачны бикләп куйдылар.

***

Икенче вәзир гафләт йокысыннан уянды, үзенең җир өстендә ятканын күрде. Үзе белән нәрсә булганын белмәде.

Менә кояш нуры бакчага төште, рәшәткәләр аша базны яктыртты. Вәзир ул почмактан карады, үзенең дустын күрде, таныды.

— Монда ни эзлисең? — диде. Ул әйтте:

— Син ни эзләсәң — мин дә шуны эзлим, — дип, хәлен, хикәятен — һәммәсен сөйләп бирде. Әүвәлге вәзир бу вакытка тикле җария сүзенә өмет тотар иде, әмма бу мизгелдә хакыйкатьне белде: барысы да мәкер икән. Өметләрен кисеп утырдылар, елаштылар.

Бераздан соң ханым җарияне бакчага җибәрде.

— Нишлиләр икән? — диде. Җария килгәч, икенче вәзир аны күреп, ялварды, һаман ялыныч сүзләрен әйтте. Җария һаман җавап бирде, һаман каннарын йоттырды. Хәл шуңа җитеште, икенче вәзирнең карыны ачты, үзен кызгандыра башлады, шикаять кылды. Беренче вәзир әйтте:

— Бер батман мамык эшкәртсәң, бер батман икмәк бирерләр, — диде. Икенче вәзир әйтте:

— Мин җариягә берәр нәрсә багышлармын, күңеле хуш булыр, безне коткарыр, — диде. Беренче вәзир:

— Һай, бу уйдан азат бул, мондый сүзләргә алдана торган дошман түгелдер, нәрсәң бар — барысын аңа багышласаң да. Безнең яшәү чыганагыбыз аның кулындадыр. Бәла вә каза күптер, әмма барысыннан да яманрагы шул булыр: авылдан усаллар килсәләр, безне җиргә ташларлар, өстебездән чират кичерләр. Безгә үлсәк — яхшырактыр, ул бәладән котылырбыз. Күзеңне ач, ни оерсың! — диде. Вәзир кычкырып елый башлады, үзен-үзе куралмыйча, үрсәләнеп-корсаланып торганда җария тагын килде. Икенче вәзир елады:

— Ачлыктан үләм, — диде. Җария әйтте: — Бибием авылга китте, миңа шуны кушты: «Ул тоткын мамык эшкәртергә риза булса, ул эшне куш, эшләсә, икмәк бир, башкарырга теләмәсә, башка кешегә бир, эшләсен», — диде.

Икенче вәзир чарасыз булды:

— Бар, китер, — диде. Җария тагын бер батман икмәк белән бер батман мамык китерде. Мамыкны эшкәртерләр, эрләрләр, икмәкне ашарлар иде. Җария һәрвакыт килер, боларны куркытыр иде:

— Менә авылдан усаллар килер, сезне шулай-шулай итәрләр, — диер иде.

Бу хәлгә бер атна үтеп китте. Икенче вәзирнең нукәрләре дә әсбапларны бүлештеләр, төрле якка таралыштылар.

***

Икенче вәзирнең вәгъдә иткән кайтыр көненнән берничә көннәр үтеп китте, әмма хәбәре беленмәде. Өченче вәзир борчылды, ул да китәргә рөхсәт сорады, ун көннән кайтырга вәгъдә итеп, китеп барды.

Яраннарын эзләп әлеге шәһәргә килде. Тегеләр белән булган вакыйга моңа да иреште. Кыскасы, эш шул хәлгә җитте: аны баз ишегенә китерделәр. Эчтәгеләр тавышларны ишетеп, курыктылар, җария сөйләгән башкисәрләр килде, дип уйладылар, почмакка качтылар, Төзүченең хатыны, кәнизәк һәм хезмәткәр өченче вәзирне ул михнәт урынына ташладылар, капкачны бикләп, кире киттеләр.

Менә таң атты. Өченче вәзир:

— Бу нинди җирдер? — диде. Әхвәлне белдерделәр, таңга калды.

— Чарабыз нидер? — диде. — Хатынның әллә фәйләсуф ташы[20] бар микән, кем явыз ният белән килә — һичшиксез тотыла, кем хөсетлек итсә — менә шундый хәлгә төшә, өмет агачының җимешен татый алмый, — дип елаштылар. Өченче вәзир:

— Бу мамык белән орчыклар нидер? — диде.

[20] Фәйләсуф ташы — борынгы алхимиклар ышануынча, төрле металлдан алтын ясый торган, кешенең ниятен белдерә торган мистик таш.

— Бераздан карының ачкач, белерсең, — диделәр.

Болар бу сүздә икән, җария бакчага керде:

— И, хуҗалар! Зәхмәтләрдән арынып, мунча керәсегез килсә, бу төшкә килегез, өстегезгә су сибәм, коеныгыз, — диде. Баштагы вәзирләр моңа күнеккәннәр иде инде — көлештеләр. Өченче вәзирнең ачу уты бугаз төеренә тыгылды, әйтте:

— Әй, утларга салучы мәкер иясе! Сиңа ни явызлык иттек? Бездән алганыгыз сезгә хәләл булсын, безгә юл бир, җаныгызга башка борчу китермәбез, — диде. Җария әйтте:

— Мине нигә сүгәсең, ник кагасың? Менә авылдан канәчкеч башкисәрләр килсә, күрмәгәнегезне күрсәтерләр. Хуҗабызга ялганлап, шундый яман фикерләр белән вәзирлек итәр идегез, инде менә шуның үчен сездән алырлар. Йокламагыз, бераз сабыр итегез, — диде. Аннан китте.

Кире килде. Эшчеләргә эш һәм икмәк китерде.

— Яхшы эшләгез! — диде. Өченче вәзир әйтте:

— Миңа да эш һәм икмәк китер, эшлим, — диде.

Җария:

— Бибием миңа кушты: «Әгәр бу азгын тоткын сораса, игелегең өзмичә, аңа эш бир, әгәр риза булмаса — бирмә», — диде. Ни диярсең, әгәр риза булсаң, эш китерәм, — диде.

Өченче вәзир риза булды, аннан җария каба, орчык, бер батман җеп эрләрлек мамык һәм шул ук микъдар икмәк китерде.

Болар шул хәлдә калдылар. Өченче вәзирнең хезмәткәрләре, вәзир китеп югалганнан соң, шактый вакыт көтеп тордылар да, аннан калган малларны бүлешеп, төрле якка киттеләр.

***

Гүәшир мәлиге күрде: эш болай булды, вәзирләренең һичбере күренмәде, гаҗиз калды. Әйтте:

— Бу эшкә үзем бару кирәктер, хәл нидер — үземә күреп кайту кирәк, — диде.

Атланды, биш-алты голәм һәм бер өстәмә ат белән Бим шәһәренә юнәлде. Шул ук мәхәлләдә кунды. «Шәһәргә йәнә бер олы килде» дип, ыгы-зыгы купты. Шундук теге карчык килеп, шаһны тәбрикләде һәм догалар кылды. Мәлик карчыктан:

— Ни кеше син? — дип сорады. Карчык үзен белдерде, һөнәрләреннән хәбәр бирде. Падишаһ әйтте:

— Менә шундый сыйфатлы кешеләр килдеме?

Карчык әйтте:

— Бу сез сораган кешеләр монда утыз-кырык көн эчендә аерым-аерым килделәр. Аларга хезмәтчелек иттем, төзүче хатынын әзерләп бирдем, ашадылар-эчтеләр, гыйшрәтләр иттеләр[21], дүртешәр көн торып, саулык белән кайтып киттеләр.

Падишаһ күңеленнән әйтте:

— Аһ, кызганыч! Ул фетнәчеләр барырлар, мин анда булмагач, төзүчене ышандырырлар. Иртәгә иртүк кайтып китәм, — дип фикер итте. Әмма шулай да, төзүченең хатынын күрмичә, китмәскә карар итте.

Бәс, карчык баягы юл белән падишаһны ул урынга җиткерде.

Менә төзүче хатыны падишаһны күрде, белде: шаһиншаһлык нуры йөзендә чагыла иде. Падишаһны бик яхшылап, кадерләп каршы алды, тәхеткә кичерде[22], үзе кулын кушырып, каршында торды. Падишаһ ишарәт итте, утырырга кушты.

[21] Гыйшрәт итү — күңел ачу, кәефләнү.
[22] Тәхеткә кичерде — «тәхет» биредә биек урын, кресло.

Аннан җария ширбәт китерде, төзүче хатыны тәмләп карады, шаһка сузды. Аннан тәгам килде — ашадылар. Шәраб килде, җария падишаһка сузды, падишаһ алды, эчте, һәр мизгел саен төзүче хатыны падишаһка яңа хезмәт күрсәтер иде. Падишаһ аның күркәмлеге һәм кешелегенә гаҗәпләнде.

— Ни булыр иде: бу изге ханым минем хатыным булса, — диде. Аннан бергәләшеп эчәргә ханымны кыстады. Ханым әйтте:

— Авылдан кардәшләрем киләчәктер, зинһар, бүген мине бу эштән азат тот, — диде. Падишаһ кабул итте, сәрхуш булганчы эчте, (һушны җибәрә торган даруны бирмәделәр, падишаһ булганы өчен хөрмәт иттеләр).

Төннең яртысы җиткәч, хезмәткәргә куштылар, ул тыштан килеп, капканы шакылдатты. Капка каккан тавыш ишетелгәч, хатын падишаһтан түбәнчелек белән гафу үтенде. Падишаһ:

— Ни булды? — диде. Ханым:

— И, хуҗа! Аһ, ул кардәшләрем килде, — диде. Падишаһ әйтте:

— Йә, мин инде кая барыйм?!

Ханым әйтте:

— Шушында, бакчада бер аулак җиребез бар, боерсагыз, шунда илтәм, — дип, тордылар, шунда бардылар. Җария култык астына керде, ханым биленнән алды, капкачны ачтылар, падишаһны эчкә куйдылар. Капкачны бикләделәр, бакчада яшеренеп тордылар, ни сүзләр кичсә — барысын да ишетерләр.

Падишаһ эчкә килеп кергәч тә, тоткыннарның берсе әйтте:

— Орчыгымны сындырма, саклан! — диде.

Икенчесе:

— Мамыгымны таратма! — дип кычкырды.

Өченчесе:

— Шүре тактасына басма! — дип акырды.

Падишаһ эчкә карап әйтте:

— Бу әллә мамыкчылар базарымы, йә булмаса, авыл мәхәлләсеме? – диде.

Бер-берсенең авызыннан һәм сүзеннән белештеләр, бер-берсен таныдылар, вәзирләр тордылар, падишаһның аягына егылдылар.

— И, хөкемдар! Монда нәрсә эзләрсең?! — диделәр, хәлләрен кыскача һәм төгәл сөйләп бирделәр. Падишаһ әйтте:

— Әй, затсызлар вә ялганчылар! Әшәкелекне минем хакымда һәм ул мескен төзүче хакында чигенә җиткердегез. Инде ул бу хәлләрдән гафил булып, белми утырыр, ә сез рисвай булып, дәүләтсез калып, монда бу хәлләргә дучар булып, тормышыгыздан кул юдыгыз. Менә мин дә сезнең шомлыгыздан монда төшеп, кол булдым. Бу төзүче хатыны минем тәкъдимем һәм сезнең сакалыгыздан көлеп, бер эш эшләде ки — кыямәт көненә кадәр дастан итеп сөйләрлек булды. Ул ак йөзе һәм гөнаһсыз күңеле белән көлеп, ә сез оятка калып, елап утырасыз. Тәңре Тәгалә миңа моннан котылу бирде исә — сезгә кыен ашатырмын, галәмгә гыйбрәт булырсыз, моннан соң һичкем мөселман хатынына падишаһлар янында яла ягарга кыючылык итмәс. Әгәр монда калсам — кулымнан җаныгызны коткардыгыз, — диде.

Төзүченең хатыны бу шелтәләрне ишетте исә, белде: чынлап та падишаһның үзе икән. Шундук кәнизәккә боерды, шәм һәм күн мендәр китертте, капкачны ачып керде. Шәмне падишаһ каршында куйды, мендәрне астына салды. Аннан йөзен җиргә куйды, әйтте:

— Әй, бәхетле хөкемдар, вай, атаклы падишаһ! Яшең озын булсын; хатыннар әгәр кабыргадан яратылган икән, әгәр кемлегенә карамыйча, бу хатынның әйткәне һәм эшләгәне акылдан һәм кануннан тышта икән — бу кыючылык һәм әдәпсезлек бу җариядән сезнең хакыгызда белмәгәнгә күрә пәйда булды, кичерегез, — диде.

Мәлик әйтте:

— Йөз-мең афәрин пакь табигатеңә булсын! Җиһан ирләренә шул тиешледер: коллыгың гашиясен[23] түшләрендә, ихласың алкасын колакларында тотсалар, һәм кыямәт дәверенә тикле бу хикәятне сөйләсәләр: һич гаеп итәчәк эшең юктыр, хуш иттең, җаныңа сыйхәт булсын! Бу дәүләтсезләрнең хакыннан көлдең, болар синең иреңне хуш тотканым өчен көнләделәр, аягын элмәккә тыгарга теләделәр, әшәкелекләрен бу урынга җиткерделәр. Ходайдан вакыты килсә, күрерсең, тиешенчә җәзаларын бирермен, — диде. Ханым яңадан башын түбән икеп, алкышлар[24] итте. Падишаһны алды, тышка чыкты, капкачны бикләп куйды. Ханым падишаһ алдыннан шәм тотып барды, өйгә керделәр, йәнә мәҗлес төзделәр, утырдылар. Падишаһ шәраб касәсен кулына алды, аяк өсте торып, тугрылыклы хатын шатлыгына эчте. Аннан әйтте:

— Ханым! Син минем ахирәткәчә кыз кардәшем булырсың, инде моннан соң бу өйдә утыру миңа ярамас, кайтып китәм, өемдә ятармын, — диде һәм йөрде. Ханым алдыннан шәм белән барды, капкага кадәр падишаһны озата чыкты.

***

Мәлик шулвакыт кунакханәгә кайтты, иртәгесенә тикле ул хатын исеменә шәраб эчте. Һәрдәм ул хатынның сыйфатын сөйләде, акылын, изгелеген мактап, хуш күңел белән утырды.

Таң атканда төзүче хатыны, төрле яхшы нәрсәләрдән бүләкләр әзерләп, гафу үтенеп, падишаһка җибәрде. Падишаһка бу хәрәкәт хуш килде.

Аннан падишаһ боерды, ул өч тоткынны чыгардылар, йөкләр өстенә ныгытып беркеттеләр, шул көнне үк Бим шәһәреннән чыктылар, Гүәширгә юнәлделәр. Төзүче хатынына якты йөз, ягымлылык күрсәттеләр, иренең котылуына өмет белдерделәр.

Менә Гүәширгә кайтып җиттеләр, мәйданда өч дар агачын бастырып куйдылар, бер-беренә каршы ул өч вәзирне асып куйдылар... Игълан иттеләр: «Кем дә кем гөнаһсызга явыз ният итә — җәзасы шушы булыр!» — дип.

Аннан соң падишаһ төзүчене чакыртты, күңелен күрде, юатты. Вәзирлекне аның исеменә беркетте, өч вәзирнең йорт-җирен, әсбабын: милкен аңа багышлады. Аннан утырып йөрү өчен җиһазланган йөк хайваннары, хадимнәр бүләк итте.

Падишаһ боерды:

— Төзүче өенә кайтсын, сагынган кешесен күрсен, — диде.

Төзүче өенә кайтты, хатыны белән күреште, кулын һәм аягын үпте, шат күңел белән елмаеп-көлеп утырдылар, хатыны башыннан кичкәннәрне хикәят итте, төзүче тыңлап, сөенде, Тәңрегә шөкерләр итте.

Падишаһ Гүәширгә күчеп килергә тәкъдим итеп, хат җибәрде. Риза булдылар. Падишаһ тарафыннан кәрван килеп, төзүче белән хатынын Гүәширгә алып кайттылар. Җәннәт кебек сарайда ул изге хатынны кундырдылар. Сарайның бөтен эчке эшләре, хәраме[25] белән идарә итүне аңа тапшырды. Төзүче оста тыштан, ул эчтән хаким булдылар.

***

Бу хикәят алардан ядкяр булып калды. Бу хикәяттә күп файдалар бардыр. Афәрин язучысына, күчереп язучыга, укучыга һәм тыңлаучыга булсын!

Текстны басмага

***Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль** әзерләде.* ■

[23] Гашия — ияр астына куела торган киез.

[24] Алкышлар — мактау.

[25] Хәрам (гарем) — кол кызлар, кәнизәкләр, хатыннар тотыла торган яшерен бүлмәләр.

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

XV

Полициядә ике кич кунгач, Садыйкны исправник янына дип чакырып алдылар. Садыйк, исправникка үзенең гаебсезлеген исбат кылырмын, урядникның дошманлык берлә арестовать итүен сөйләп аңлатырмын да, үземнең Лодзьдагы нутренний врак берлә сугышта медаль алуымны әйтермен дә, чыгарып җибәрерләр, дип уйлый башлады. Ул исправникка ничек сөйләүләр хакында планнар кора, сүзләр хәзерли башлады. Баштан ук солдатча бик тәгаззем белән мөгамәлә кылып аңарга эшнең ни икәнен аңлатмакчы булды. Һәм дә күңеленнән: «Исправник зур кеше, үрәтник түгел! Хәзер аңлар да, кайтарып та җибәрер. Аннары туй итәрбез, Гайниҗамал белән кавышырбыз», — дип уйлый башлады. Шушы уйлар брлә бер коридорга барып керде.

Коридорны карарга өлгермәде, аны әллә кем сугып екты. Ул, ни эшләргә белмәенчә, бу эшнең ни икәнен аңламаенча, як-ягына карарга тотынды. Үзен чөгендер кебек кып-кызыл стражниклар арасында күрде. Ни эшләргә?! — дип уйлап бетермәс борын, берсе бик каты тибәргә, таптарга, икенчесе муеныннан күтәреп колагын кыйнарга тотынды.

Садыйкның күз алды караңгыланды, ни эшләргә белмәде. Стражникларның кыйнаган саен куллары кызып, кыйнауларын һаман арттыра бардылар. Ахырдан Садыйкны тагын сугып идәнгә ектылар. Өстенә менеп таптаганнан соң, читкә китеп утырып, сүгенә башладылар. Кайсылары арыш сугып чыккан кеше кебек арып, кесәләреннән махоркаларын алып тартырга хәзерләнә башладылар. Берсе, Садыйкның анасын ядка алып: «Солдат, солдат, ә нутреннич врак?» — дип сүгенде дә «тфү», дип Садыйкка таба төкереп, тәмәке тарта башлады.

Садыйкның исправникка чакырган солдаты Садыйкка: «Тор! Тор! Әйдә!» — дия башлады. Садыйк акрын гына торды.

Аның йөрәге кайный, бәгъре яна. Ул үзенең шулкадәр эт төсле кыйналуыннан, шул сатлык, исерек стражниклардан изелүеннән, үзенең бөтен тормышы, бөтен правосы шул исерекләр кулында булуыннан хурлана. Аның күңелендә шул кабахәтлекләргә каршы бик зур ачу үсә, шулардан үч алу уе урынлаша иде.

Ул шул уйлар белән акыртын гына исправникка таба китте. Ишеге төбендә бераз торганның соңында аны исправникка алып керделәр. Исправник ул уйлаганча булып чыкмады.

Ул Садыйкның үзен йоларга теләп сөйләгән сүзләренә ирек бирмәде. Ул, аяк тибеп, аның өстенә кычкырып, моның тавышын туктатты.

Садыйкның тагы өмете өзелде. Ул, эченнән генә: «Монда шул губернатор юк! Монда барысы да сәнәктән көрәк булган нәрсәләр шул!..» — дип губернаторның гына моны коткара алуына ышана башлады. Ул ара да булмады, исправник звонок бирде. Аягының өстенә генә басып, бер пеләш рус керде. Исправник: «Әхмәдиевнең бумагасы хәзерме?» — дип сорады.

Теге рус: «Хәзер, хәзер!..» — дип чыгып китте. Исправник тагы Садыйкны

Дәвамы. Башы журналның 8 нче санында.

сүгәргә, солдат булган кешенең патшага, мәмләкәткә дошман булуының начарлыгын сөйләргә тотынды. Садыйк тагын, үзен йолар өчен, җавап бирмәкче булды.

Исправник: «Молчать!..» — дип кычкырды. Бүлмәнең тәрәзәләре чыңрап китте. Шул арада теге рус, тагы кәгазь күтәреп килеп керде. Исправник кулын куйды. Садыйкны алып чыгарга кушты.

Садыйк теге рус артыннан чыкты. Аны — бер рус, помощникмы, надзирателеме янына туктаттылар. Анысы сүгенмәенчә генә моңарга теге рус токкан язуны укырга тотынды.

Садыйк бик рәтләп ашамады. Алай булса да, язу аның хакында икәнлеге, аннан соң өендә табылган ватык мушкадан — бик зур гаепкә хисапланганлыгын аңлады. Ул укып бетергәч, помощникка мылтыкларын кайдан алганын, ни өчен алганын сөйләргә тотынды. «Безнең туйларада мылтыктан ату гадәт», — дип, үзенең бикәчкә барыр өчен алганлыгын сөйләде. Помощник, кашларын киереп: «Закон буенча, мылтык тотарга ярамый», — диде. Тагын аның халыкны котыртуы, халыкка җир кирәк, дип сөйләве тугрысында укыгач, Садыйк үзен йолар өчен, җирнең чыннан да кирәклеген сөйләргә тотынды!

Помощник бу юлы чыдый алмады. «Молчать!» — дип кычкырмаса да, аны бик каты туктатты да, стражникка: «Төрмәгә илтегез!» — диде.

Садыйк тагы агарып-кызарып китте.

Ул: «Ваше благородие, минем туем...» — дип, туй хакында сөйләргә тотынды. Помощник акыртын гына көлде дә, стражникка: «Бар, бар!» — дип әмер бирде. Стражник төрткәләп, моны алып чыгып китте.

Күңелендәге ачу белән, Садыйк кая барганлыгын белмәенчә, тагын баягы коридорга килеп керде. Үзен бу коридорда күргәч тә, ул куркып китеп, тирә-ягын карана башлады. Коридорда бер карт городовойдан бүтән кешене күрмәгәч, күңеле тынычланыбрак китте. Озак үтмәде, аны извозчикка утыртып төрмәгә алып киттеләр.

Ул бер чаттан борылганда, әтисе белән әнисен күрде. Аларга борылып карап башын иде. Әнисе яулык берлә күзен сөртә-сөртә, елый башлады. Бу күз яше Садыйкка да тәэсир итте. Аның да күзләреннән яшь мөлдери башлады. Ул әтиләрен, әниләрен, Гайниҗамалын кызгана башлады.

Менә төрмәгә дә килеп җиттеләр. Капка да ачылды. Садыйк акрын гына капкадан үтте. Аңарга бу минут, бу капка аша атлау бик авыр төсле тоелды. Бу капка аша атлавы тормышының теге ягына чыгу төсле булды. Ул бөтен көчен җыеп үзен-үзе тыярга, үзенең яшен туктатырга тырышты. Дөбердәп, капка ябылды.

Садыйкның бөтен сәгадәте, бөтен рәхәте, бөтен тормышы, бөтен өмете капка артында калган төсле булды. Ул шул уй белән төрмә конторына керде.

XVI

Садыйкны бер учитель, бер писарь янына кертеп яптылар.

Алар икесе дә Садыйкка: «Иптәш!» — дип, Садыйкның ничек ябылуы тугрысында, кемнәрнең доносы белән тотылуы хакында сораша башладылар. Садыйктан: «Чәй эчтеңме? Ашыйсың киләме?» — дип, аны үз балалары кебек карый башладылар.

Садыйкка бу кыланмыш кына булып күренеп, бу кадәр дуслык берлә мөгамәлә аны аптыратты. «Алдау-фәлән өчен түгел микән?» — дип ул шикләнә башлады. Тышка чыкканда, кесәсендәге акчасын чалбарының урынтын кесәсенә салып куйды. Озак үтмәде, звонок булды. Болар өчесе дә йөрергә чыктылар.

Йортта тагы әллә никадәр кшеләр, Садыйк белән күрешеп: «Иптәш!» — дип чормап алып, сораша башладылар. Аның татар булуы аларның дикъкатьләрен тагын да җәлеп итә төште. Бер яшь учитель: «Иптәш, се-с-рмы с-дмы?» — дип сорады. Садыйк, әлбәттә, җавап бирмәде.

Ул ара да булмады, хатыннар бүлегеннән, кызлар тәрәзәгә менеп, Садыйк белән: «Исәнме, иптәш, исәнме?» — дип исәнләшә башладылар.

Боларның барысының да Садыйк белән дусча мөгамәлә кылуы, Садыйк белән, бер атадан, бер анадан туган кеше кебек кыйланулары Садыйкка гаҗәп төсле күренде. Бу кадәр яхшылык, төрмә халкыннан бу кадәр дуслык — нутренний врачлардан бу кадәр туганлык Садыйкның гакылына сыймаганга, Садыйк та «Монда бер-бер хәйлә бардыр, бер-бер начар уй бардыр», дип, тагы саклана башлады. Ләкин боларның бөтен кыланышлары, бөтен эшләре хәйләгә бер дә охшамаганга, Садыйк аптырабрак калды... Садыйктан сорап бетергәч, күп кеше үзләренең ничек тотылуларын, ни өчен гаепле хисаплануларын, нинди статья белән судка бирелүләрен сөйләделәр. Йөрүнең ахырына таба гына берсе килеп: «Синең, иптәш, акчаң бармы?» — дип сорады. Садыйк: «Ә-ә, менә болар ни өчен шулкадәр кыланалар икән!» — дип, баш ваткан бу мәсьәләне хәл кылды да, үзен-үзе алдатмас өчен: «Юк!» — дип җавап бирде. Теге тагы чәй, шикәр тугрысыннан сорады. Садыйк барсына да бертөсле «юк» дип җавап бирде.

Шуннан соң теге кеше болар бүлмәсендәге писарьне чакырып: «Сезнең бу иптәшне бүгенгә ашатырга чәй-шикәрегез җитәрлекме? Күмәчегез бармы?» — диде.

Писарь: «Чәй, шикәр бар, күмәч юк», — диде.

Теге кеше: «Иптәшләр, кемдә күмәч бар?» — дип кычкырды. Бер егет: «Миндә бар», — дияргә өлгермәде, икенче, өченче, дүртенчесе: «Бар», «Бар», — дип кычкырдылар.

Теге иптәш аларга йөрү беткәч, Садыйкка бирергә кушты. Аның соңында, Садыйктан: «Чәй чынаягың бармы?» — дип сорадылар.

Садыйк: «Юк!» — дигәч, теге тагы: «Кемдә стакан, кружка бар?» — дип кычкыра башлады. Бер төркем егетләр белән тәрәзә аша сөйләшә торган кыз: «Миндә бар!» — диде. Ул ара да булмады, кыз тәрәзәдән югалды. Бераздан соң, епкә бәйләгән кружка төшерә башлады. Егетләрнең берсе кружканы алып, Садыйкка бирде. Звонок булды, йөрү дә бетте.

Камераларга кергәч, учитель аш алырга төшеп китте, писарь аш урыны хәзерләргә тотынды. Садыйкка дигән тарелканы юарга, сөртергә тотынды. Шул ара да булмады, башка иптәшләре, Садыйкка дип, күмәч китерә башладылар. Күмәч бик күбәйгәч, писарь алмый кире кайтарып бирә башлады. Менә учитель аш алып менде. Аш башланды. Аштан соң чәй эчелде. Чәйдән соң учитель книга укырга тотынды.

Писарь Садыйк янына килеп: «Әтиең-әниең, дус-ишең бармы? Күрешергә киләләрме? Килсәләр, прошение биреп, рөхсәт сорарга кирәк», — диде. Садыйк «прошение» дигәч, үзенең яңлыш кына ябылуын белдереп: «Исправник өстеннән губернаторга жалоба язарга кирәк», — дип сөйли башлады. Писарьның соңында учитель Садыйкка: «Аннан бер файда да булмас», — дип язмаска димли башлады.

Садыйк: «Тагы бер-бер хәйлә булмасын», — дип үз сүзендә каты торды. Ахырдан писарь ике прошение язды. Учитель тагы: «Алар бар да бер чыбык белән куган. Аннан бер файда булмый», — дип Садыйкны прошениесен бирдермәскә тырышты. Садыйк тагы карыша төште. Писарь: «Әйдә, бирсен. Аның әле начальствога ышанычы бетмәгән», — диде.

Шулай итеп, тагы бераз вакыт үтте. Тагы йөрергә чыгардылар. Бу юлы башка арестантлар һәммәсе баягы теге русның чакыруы буенча, бергә җыелдылар. Теге рус әллә нәрсәнең хисабын укый башлады: «Күмәч — өч пот. Шикәр — ун кадак. Ит — унбиш кадак...» Аннан соң башкалар сөйләде. Аннан соң күпме акча барлыгы бәян кылынды.

Садыйк эченнән генә: «Бу теге паёк акчасы микән әллә?» — дип уйларга тотынды. Ахырдан: «Кассада 39 сум 41 тиен акча бар», — теге рус собраниене ябарга өлгермәде, тәрәз форточкасы аша, кырыккан башлы бер кыз: «Виктор! Виктор!»

— дип теге русны чакырып, «Мин бүген 12 сум акча алдым, аны да санагыз», диде. Виктор: «Алай булса, 51 сум була», — дип кычкырды.

Шул ара да булмады, бер егет бер тәрәз тугрысына барып: «Саша! Саша!» — дип кычкыра башлады. Форточка ачылды. Теге егет: «Еп төшер!» — дип кычкырды. Саша таш бәйләгән епне төшерде. Теге егет шуңарга кечкенә генә варенье банкасын бәйләп: «Тарт!» — дип кычкырды. Саша әкрен генә тартып, вареньены алды. «Рәхмәт!» — дип тәрәзәне япты. Ул ара да булмады, кызлар ягыннан тагы бер кыз, форточканы ачып: «Виктор!» — дип кычкыра башлады. Виктор килде. Теге кыз: «Өченчегә бер кадак шикәр, бер кадак күмәч, дүртенчегә әсмуха чәй, бер кадак күмәч, бишенчегә махурка, бер кадак күмәч», — дип яздыра башлады. Йортның икенче кырында, кычкырыша-кычкырыша көлешә башладылар. Садыйк алар янына барды. Аларның шатлыклары, аларның кайгысызлыклары Садыйкка сираять итте. Ул да көлә башлады...

Шулай итеп дүрт-биш көн үтмәде, Садыйкның күңелендәге һәммә шөбһәләре бетеп, боларның барсын да, эченнән дус күреп, төрмәнең иске кешесе кебек тора башлады. Ул да болар кебек уйный, көлә, кычкырыша башлады. Башкалар кебек ул да үзенең өе, үзенең эти-энисе, Гайниҗамал тугрысында мөмкин кадәр аз уйларга тырыша башлады. Ул төрмәдәге эш-хәрәкәтләр белән үзен-үзе юата башлады.

XVII

Бер-ике атнадан соң, Садыйкның ул көнге биргән прошениесенә каршы губернатордан җавап килде. Губернатор Садыйкның хатын җавапсыз калдырудан башка, рөхсәтсез корал тоткан өчен, аны өч айга төрмәгә ябарга хөкем иткән иде.

Садыйкның моңарга исе китте. Ул үзен-үзе аз гына да гаепле дип белмәгәнгә, тагы губернатор өстеннән министрга прошение бирергә уйлый башлады. Ләкин губернаторга биргән прошениесеннән зарар гына булганга, ул, министрга бирсәм, ул да җәзаны гына арттырыр, кем белсен, өч айны өч ел ясар, дип уйлап, прошение бирмәскә булды. Чыккач, эшләячәк эшләренә планнар кора башлады.

Менә озакламады, аңарга атасы-анасы, карендәш-кабиләсенә күрешергә килергә рөхсәт бирелде. Шул атнада ук Әхмәди абзый, әнисе, энесе күрешергә килделәр. Әтисе-әнисе, күрешү вактында туктаусыз елап, авылдагы күңелсез хәбәрләрне сөйләп, Гайниҗамалны сөйләп, аның йоклаган кайгысын уяттылар.

Ул күрешүдән кочагына әллә ни кадәр күмәчләр, майлар күтәреп кергән кебек, күңеленә дә әллә ни кадәр яңа хәсрәтләр тутырып, иске кайгыларны сипләп керде. Ул көнне үткәрү Садыйк өчен бик авыр булды. Аның күз алдына тагы әтиләре, әниләре, энеләре, Гайниҗамал килеп, аның кайгысын озайтканнан озайтып, аның кәефсезлеген ныгытты. Кич белән яткач та, ул бик озак йоклый алмады. Аның башына әллә ни кадәр фикерләр килеп, әллә ни кадәр планнар килеп, уйлый-уйлый йөдәп бетте. Ул һәрвакытта: «Менә өч айдан чыгам... Ике атна булды...» — дип ямьсез уйны томаларга теләсә дә, аның хиссияте гакылына баш сонмаганга, аның уйлары һаман ямьсезләнгәннән ямьсезләнә барды.

Ул эчтән үзенең өч айдан соң чыгуына ышанмый башлады. Аңарга ул бу төрмәдән чыкмас кебек, чыкса да тагы стражниклар килеп алып китәр кебек булды. Шул уйларның өстенә еглый-еглый күзләре беткән Гайниҗамал килеп кушылып, уйны тагы икенче бер тарафка агыза башлады. Ул үзенең аерылуын Гайниҗамладан тәмам аерылу дип ышана башлады. Гайниҗамал белән актык күрешүләрен, актык кочышуларын, актык үбешүләрен хәтеренә төшерергә тотынды. Аның колагына Гайниҗамалның тавышы ишетелгән кебек, аның муенына Гайниҗамалның кайнар авызы тигән кебек булды. Ул шул хыялы белән шатлана, шул хыялый кочулар, хыялый үбүләр белән ләззәтләнә башлады. Ул үзен-үзе белмәенчә, хыял белән хакыйкатьне аермаенча, тәмам шул Гайниҗамал дөньясына китте.

Коридордагы аяк тавышы аны бу фикердән уятты. Ул як-ягына карангаларга, үзенең кайда икәнен белмәенчә исәпләргә тотынды.

Моң гына яна торган лампа, рәшәткәле тәрәзә Садыйкның бу авыр мәсьәләсен хәл итте: ул үзенең төрмәдә икәнен хәтеренә төшерде. Шуның артыннан ук Гайниҗамал белән хәзер генә үбешүе хәтеренә килеп, андый үбешүләр, андый кочышулар бетте кебек күренде. Бу фикер аның башына шулкадәр урынлашты, ул үзенең Гайниҗамалдан аерылуы өчен, ул үзе Гайниҗамалны үбә-коча алмавы өчен, ул үзенең Гайниҗамал белән ирле-хатынлы булып тора алмавы өчен, ул Гайниҗамалның Садыйктан аерылуы өчен, Гайниҗамалның сөйгәненнән — дүрт ел көткән сөйгәненнән аерылуы өчен, мәңгегә аерылуы өчен елый башлады. Ул шул уйларның барысы өчен дә еглады, барысы өчен дә сыгылып-сыгылып еглады. Еглый-еглый арып беткәч, ул үзенең шул фикре берлән үзенең шул мәңгегә аерылуы берлә бераз килешеп, бераз тынычланып, йокыга китте.

Иртәгәсен Садыйкка жандармскийдан эше губернаторга бирелүен игълан кылдылар. Иптәшләре Садыйкка моның мәгънәсен сөйләп, аны өч айдан чыгармауларын, аны административный порядок белән Себергә сөрелүе ихтималы барлыгын белдерделәр.

Садыйк күңеленнән Себергә китүенә тәмам ышанып куйды. Бу уйдан соң үзен-үзе Себергә хөкем ителгән иттереп хис кылганнан соң, Садыйк бераз тынычланып китте. Ул янындагы учительдән русча укырга тотынды һәм дә хәзер үзен «чын политик» хисаплап, политикларның чынлап та хөкүмәтне яратмаулары тилелекләреннән генә түгел икәнен күреп, алардан политиклыкка өйрәнә башлады.

Аңарга бик простой сүзләр белән «партия» ни дигән сүз икәнен, партияләрнең ниндиләре булуын, менә монда, бу төрмәдә ята торган шул учительләр, писарьлар, студентлар, эшчеләр, крестьяннарның ни теләүләрен — һәммәсен сөйләделәр.

Алар арасында ике партия барлыгын, шул ике партиянең аермаларын бәян иттеләр. Садыйк ике партия арасындагы аерманы рәтләп аңламаса да, икесе дә яхшы партия — халык партиясе икәнен аңлады. Шуның өстенә шул арада гына тотылган тагын бер татар шәкерте Садыйкка бик күп ярдәм итте. Садыйкка русча аңламаганнарын татарча сөйләп аңлатты. Үзе белән китергән кечкенә-кечкенә татарча рисаләләрен сөйләп-сөйләп, Садыйкка укытты.

Садыйк шул партия мәсьәләләре белән, шуларның программалары белән, шуларның тактикалары белән бөтенләй күмелде. Ул бик тырышып шуларны аңларга, шуларны белергә тотынды.

Аның күз алды иркенләнде. Ул үзенең хәзер белгәннәрен, үзенең солдат вакытындагы ишеткәннәрен уйлый башлады. Ул анда теге газета укыган солдатлар, теге казакларның кыйнавын яратмаучылар партия кешеләре икән дип уйлап, үзенең анда кылган эшләренең хаталыгын аңламаудан килгәнлеген уйлый башлады.

Лодзь вакыйгалары аның башында әллә нинди бик ямьсез фикерләр уятканга, алар Садыйкның күңелендә бик тирән җәрәхәтләр ачканга, ул алар хакында уйламаска тырыша башлады.

Тагын шуның өстенә беркөнне теге иптәш писареның әлгәре взятка алганын ахырдан, менә шул холык өчен урыныннан мәхрүм булып төрмәгә ябылуын сөйләп, кешенең фикере үзгәрүенә гаҗәпкә калуы Садыйкның да аяк астын тазартты. Ул да: «Булган эш булган. Менә моннан соң үземнең ул гөнаһларымны йөзләп кайтарырмын», — дип уйлый башлады. Ул шул фикере белән үзен-үзе киләчәктә халыкка хезмәт итүче иттереп уйлап, шул халык хезмәте өчен, менә шул учительләр, менә шул писарьлар, шул кызлар кебек авырлыклар күрүче, атасы-анасы, өе, хатыныннан аерылучы дип беркетеп куйды.

Шул халыкка хезмәткә тугры юллар табар өчен, бик тырышып укый башлады.

XVIII

Садыйкның ябылуына өч ай тулып үтсә дә, Садыйкны чыгармадылар. Садыйкка эше губернатордан соң, министрга йибәрелде, диделәр. Иптәшләре министр актык статья дигәнгә, Садыйк һәр көнне министрдан җавап көтә башлады.

Айлар үтте. Яз булды. Министрдан җавап килмәде. Садыйкның әтиләре күрешергә килә-килә арып беттеләр. Әнисе дә күмәч ташый-ташый йөдәп бетте. Юллар бозылды. Күрешүләр тукталды.

Төрмәнең тәрәзәсеннән ямь-яшел кырлар, яшәрә башлаган урманнар, киң озын итеп һаваланып җәелгән Идел күренә башлады. Озак үтмәде, пароход тавышы ишетелде. Җәй тәмам башланды. Төрмә халкы иртәдән кичкә кадәр тәрәзәләрен ачык тота башладылар. Йөрү вакытында бер туктамаенча туп уеннары уйный башладылар. Менә беркөнне Садыйкка әнисе күрешргә килде. Ул авыл хәбәрләрен сөйләп, Гайниҗамалны сөйләп, иртәгә сабан туе дип, ашыга-ашыга авылына китте.

Төрмәнең тормышында тагы бүгене — кичәгә, кичәсе — берсекөненә охшаган көннәр үтә башлады. Халыкның бер-берсе белән сөйләргә сүзләре бетте. Бер туктамаенча кычкырыша торган моназара кылыша торган кешеләр дә моназараларыннан туктадылар. Бер туктамаенча җырлый торган учитель да сирәк кенә җырлый башлады.

Һәммә кеше бертөрле яңалык, бертөрле үзгәреш көтә. Күбесенең эшләре министрда булганга, министрдан җавап төрмәдән чыгу җавабы көтә башлады.

Менә беркөнне иртә белән төрмә капкасыннан бик күп кешеләрне керттеләр. Политиклар тәрәзәләргә менеп, бер-берсе белән сөйләшә башлады. Биш минут вакыт үтмәде, төрмәдә этап белән 40-50 политикның китерелүен белделәр. Шуннан соң ук төрмә коридорында аяк тавышлары, начальниклар тавышы ишетелә башлады. Тагын бераздан тәрәзәдән: «Исәнмесез, иптәшләр!» — дип кычкырышу тавышлары белән 30-40 кеше коридорга керә башлады. Бөтен төрмә тавыш белән тулды. Ишекләр ачыла башлады. Начальниклар бүлмә саен кереп: «Иптәшләр керә, бүлмәгезгә алыгыз! Урын юк!» — дип йөри башладылар. Озак үтмәде, этапны бөтен төрмәгә тараттылар. Садыйкларга да дүрт кеше бирделәр.

Учитель, писарь яңа кешеләрдән кайдан икәнлекләрен, нинди партиядән идекләрен сораша башладылар. Яңалар белән искеләр арасында бик тиз дуслык, иптәшлек мөнәсәбәте урнашты. Яңалар Польшадан Вяткага җибәрелгән поляклар, еврейләр, руслар булып чыктылар. Төрмәдә Польша хәлләре сөйләнә, андагы партияләр хакында низаглар башланып китте.

Садыйк та бик тиз яңа иптәшләр белән танышып китте. Бу танышу аның күз алдын тагын киңәйтте. Аның күңелендәге тартышучы Русиягә тагын тартышучы Польшаны китереп бастырды. Шуның өстенә этап хәлләрен, этап солдатлары кыланышларын сөйләү аның элгәреге солдат вакытын — «чын солдат» вакытын хәтеренә төшерде.

Төрмә тагын гөрли башлады, тагы яңа тормыш белән тора башлады.

XIX

Садыйк үзенең иптәшләре белән мунчадан кайтканда, кояш баеган иде. Камераның ачык тәрәзәсеннән салкын гына саф һава бүлмәнең эченә таба ага. Бүлмәдәге яңа төшеп килә торган караңгылык бүлмәдәге әйберләргә үзенә бертөрле җуанлык, тупаслык төсе биреп, бүлмәнең моңлыгын арттыра. Тәрәзәнең дә тимер рәшәткәсе калынрак кебек. Ансыз да кечкенә тәрәзәдән кысылып керә торган яктылыкны ул да кыса, ул да яткылыкның каймагын сөзеп, тышка калдыра кеби сизелә иде. Шулай булса да, яшел үлән исе, яңа яфрак исе стражниктан курыкмаенча, начальниктан сорамаенча, Садыйкларның бүлмәсен тутырып керә, аларның күңелләрендә элгәреге үткәргән язларын хәтерләренә китерә, аларның тамырларыннан йөгереп йөреп, аларны тазарта, ныгайта иде.

Озын киң Иделдән килгән пароход тавышлары Садыйкларга дөньяның барлыгын, Садыйклар һәм аларның иптәшләре төрмәдә булуына карап, дөньяның үзгәрмәвен, боларның төрмәдә һәрнәрсәдән мәхрүм булып торуларына карамастан, иректәгеләрнең, электәгечә яшәүләрен, элеккечә пароходларда йөрүләрен, гүя бөтен дөнья аның шул кечкенә эшенә генә терәлеп тора кебек итеп, бөтен гайрәтен шуңарга гына сарыф кылып, тормышның шул кечкенә эшләре өчен тартышуларын, шулар өчен кычкырышуларны хәтергә китерә, аларны шул биек диварлар белән бүленгән, шул тимер рәшәткәләр белән аерылган дөнья берлә куша иде.

Күктәге аязлык, күкнең саф зәңгәр буяуларында ялтыраган йолдызлары Садыйкның уйларын үзләре белән еракка алып китеп, аны әле үзенең малай чакларындагы уйнаган уен мәйданына илтәләр, әле үзенең яшь вакытында озак эшләрдән арыганнан соң лапаска аскан хәл җыя торган озын казарманың сәкеләренә ташлыйлар иде.

Садыйк боларның һәммәсендә дә бик озак торган кебек, бу үткән тормышның бу бүлмәләрендә яшәүнең ачысын-төчесен татыган кебек булып, берсеннән берсенә күчә бара иде.

Менә ул хәзер үзен төрмәдә күрә башлады. Биек диварлар, тимер рәшәткә аның уен туктатып кала алмады. Ул бик тиз алар аша сикереп, үзен этапта күрә башлады, этап авырлыкларын җилкәсе белән күтәрә башлады.

Уй ага-ага Себергә барып җитте. Садыйкның күз алдында әллә нинди зур-зур аюлар күренгән кебек булды. Андагы суыктан аның куллары туңа, тәннәре калтырый кебек булып китте.

Ул Сибириянең суык сахраларында да туктамады. Ул тагы Русиягә әйләнеп кайтып, Садыйкны тагы үзе авылына, үзенең туган-үскән авылына китереп ташлады. Тагы стражниклар. Тагы полиция. Тагы төрмә күренә башлады. Шул ара да булмады, яңа иптәшләренең берсе сөйли башлады. Бу тавыштан Садыйк яңа йокыдан уянган кеше кебек булып сискәнеп китте. Үзен тагы төрмәдә күргәч, Сибириядән әйләнеп кайткач, бу икенче төрмәдә ятуы кебек күренде.

Яңа иптәшләрнең берсе: «Нинди матур кич! Былтыр мин бу вакытта иректә идем», — диде дә авыр иттереп сулады. Садыйк һәм аның иптәшләре әүвәл әллә нәрсә әйтергә теләсә дә, әйтми калган кебек иттереп, аның күзенә карадылар. Агарып килә торган сакаллы полякның ялтыраган күзләре чынлап та боларга әллә ниләр әйтергә теләгән кебк, әллә ниләр белән боларны таныштырырга уйлаган кебек булып күренде. Поляк боларга илтифат итмәгән тавыш белән: «Менә былтыр шундый матур көндә, беренче май бәйрәм иткәндә, урамда минем углымны атып үтерделәр», — диде. Тамагына әллә нәрсә тыгылган кеше кебек, сүзен бүлде. Аның бу сүзе, аның бу сүздән соң тамагының гырылдавы бөтен бүлмә халкына бик авыр тәэсир итте. Алар барысы да менә шул карт поляк егетенең урамда үлеген күргән кебек булдылар. Барысы да ул яшь егетнең елы канының исен иснәгән кебек булдылар. Барысы да хәзер генә менә болар алдында менә шунда гына шул җинаять эшләнде кебек хис иттеләр.

Поляк тагын күзләрен әйләндерде, тагын көчен җыйды да, бик авыр эш эшләгән кеше кебек бик күп көч сарыф кылганнан соң, көчкә генә җиңгән кеше кебек, дерелдәгән тавыш белән: «Аннан элгәре фабрика йортында агамны үтерделәр. Биш баласы калды. Быел, менә мине йибәрделәр... Унике кешене ач калдырдылар», — диде дә, тагы туктады, тагы әллә нәрсә йоткан кебек, тавыш чыгара башлады.

Бу сүзләр бүлмә халкына шулкадәр тәэсир иттеләр ки, алар барысы да үзләренең матур һәм ямьсез тормышларын онытып, татлы һәм тәмсез уйларын ташлап, карт полякның ачы кайгысын кайгырта башладылар. Аның шул киң җилкәсенә өелгән шул хәсрәтләрен күңелләреннән бүлешергә тотындылар. Барысы да төрлечә уйладылар. Барысы да төрле юл белән полякка ярдәм итәргә вәгъдәләр кылдылар.

Барысы да үзләренең уйларының агымы белән китеп, тагы да төрмәнең диварларына килеп бәрелделәр. Барысы да эчләреннән генә, бу төрмәләр булганда, бу идарә булганда, мондый полякларның исәбе-хисабы юклыгын уйларга, ярдәм итсәк тә, бу полякны шул хәлдән чыгарсак та, башкаларның шул хәлгә төшүе хәтерләренә килде.

Садыйк алай уйламады. Аңарга полякның бу ялтыраган күзе, бу хырылдаган тавышы Исрафил суы кебек тоелды. Ул тавышның һәр селкенүе, ул күзләрнең һәр ялтыравы аның күңеленә электрик кебек тәэсир итеп, аның күңелендә әллә нинди, моңгача хис ителмәгән курку уен уятты.

Бу тавыш аның әллә нинди бик авырта торган җиренә тигән кебек булды. Ул үзен бөтен, иң оят йирләре берлә ялангач калган кебек хис итә башлады. Ул үзен-үзе күрергә җирәнгән кебек була башлады. Ул да бик зур көч сарыф кылып, калтыраган тавыш берлә: «Кем үтерде? Кем фабрикасында?» — дип сорады. Аның да тамагы хырылдарга тотынды. Ул да әйтеп бетерә алмаслык бер авырлык белән, теге плякның җавабын көтә башлады. Аның күз алдына үзенең солдат вакытында фабрика йортында чәнчеп үтергән эшченең ялтыраган күзләре күренгән кебек, аның бөтен карны кызартып аккан канының исе тоелган кебек булды.

Теге поляк авызын ачарга өлгермәде, ул аны үтерүче Садыйк икәненә, аның биш баласын ятим калдыручы үзе икәненә шулкадәр ышанды... Ул үзен хәзер генә шул корбанын үтергән кебек, хәзер генә менә шул иптәшләр арасында шул гөнаһсызның җанын койган кебек, шул биш баланы хәзер генә ач калдырган кебек, «чын солдат» булыр өчен, медаль алыр өчен, менә шуның кебек күзләре ялтыраган, эшли-эшли арып беткән бала-чагаларын тукландырырга тырышкан балалар атасын үтергән кебек хис итте.

Полякның фабрика исемен әйтүе һәм дә ачуланган тавыш белән «Солдат үтерде», дию аның бу фикерләрен тәмам урынлаштырды.

Ул хәзер үзенең шул эшченең агасын үтерүчелегендә аз гына да шөбһәсе калмады. Аның күңеленә әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык тартышу башланды. Хәзерге политик Садыйк белән чын солдат Садыйк талаша башладылар. Берсен-берсе үтерүче, кан эчүче гөнаһсыз балаларны ач калдыручы, дип сүгә, тирги башлады. Әллә нинди зур җәзалар белән үзен җәзаларга тели башлады.

Элгәреге солдат Садыйк политик Садыйкка: «Мин начальство кушканны эшләдем», — дип үзен йоларга теләсә дә, озак үтмәде, политик Садыйк үзенең дәлилләре белән бөтенләй җиңә башлады... Политик Садыйк куәтләнгән саен солдат Садыйк, зәгыйфьләнә барып, ахырдан ул бөтенләй җиңелде.

Садыйк аңгардан тартына, аңгардан җирәнә башлады. Аның күңелендә үзен ул Садыйктан аеру фикере, үзен шул кан өчен хәзерге политик Садыйктан өзеп ташлау фикере урнашты. Ул аларның икесен шулай аерырга юл эзли башлады.

Учительнең: «Ул солдатны үтерделәрме?» — дигән соравы Садыйкка җавап булып төште. Садыйк: «Аны үтерергә кирәк», — дип хөкем итте. Кем үтерсен? Иптәшләрме? Ул аларга хәзер ничек иттереп әйтсен? Ничек иттереп шул полякка: «Синең агаңны үтерүче мин идем, аның балаларын ач калдыручы мин идем!» — дип ничек әйтсен?! Юк, булмый!

Ул үзен үзе үтерә. Ул политик Садыйк солдат Садыйкны үтерә. Ул кабахәттән үзе үч ала. Шулкадәр вөҗдан газабы чигәргә сәбәп булган Садыйкны үзе үтерә. Әйе, үтерә, үтерә, үтерә дип, үтерү планнарын кора башлады.

Поляк тагы сөйләргә тотынды. Аның тавышында хәзер элгәреге куркыныч ишетелми. Аның тамагыннан элгәреге ачу гырылдавы чыкмый. Ул: «Ул этне үтереп, ни эшлисең? Берсе бетсә, икенчесе туа. Аны үтереп, кулыңны канга буярга ярыймы?» — диде.

Бу сүзләр Садыйкның күңелендә тагын башка хисләр уятты. Чынлап та ул

элгәреге солдат Садыйкка үч итеп, хәзерге политик Садыйкны үтерергә ярыймы, дип уйларга тотынды. Аның күз алдына үзенең киләчәк өчен корган планнары килә башлады. Аның Себердән кайтып эшләүләре. Аның теге солдат Садыйк кылган начарлыклардан 40 өлеш артык яхшылык кылырга уйлаулары… Кыскасы, политик Садыйктан үсеп чыгачак киләчәк Садыйк күз алдына килә башлады.

Писарьның: «Нәрсәгә үтерергә? Менә мин взяточник идем. Хәзер чын кеше булдым. Ул да әле чын кеше булыр», — диде. Киләчәк Садыйк бизмәне басуына сәбәп булды. Ул киләчәк өчен, киләчәк эшләр өчен үзен үзе үтермәскә карар бирде.

Ул үзен үзе әллә нинди зур сугыштан чыккан кеше кебек арыганын хис иткәнгә, солдат Садыйк һаваны тутырып-тутырып сулый башлады. Аның кулы кесәсендәге каты нәрсәгә тиде. Бөтен тәне дерелдәп китте. Ул тагы үзен бик зур җинаять кылганда тоткан кебек булды. Ул бик тиз кесәсенә тыгылды да, кесәсендәге менә шул полякның агасын үтергән өчен, менә шул полякның агасының биш баласын ятим калдырган өчен бирелгән медальне алды да, ни эшләргә белмәенчә, аны кулында әйләндерә башлады. Ул медаль хәзер моңгарга мөҗәссам кан (канга әйләнгән) кебек, мөҗәссам күз яше, мөҗәссам җинаять булып күренде. Ул тиле кеше кебек, бик каты куәт белән аны күтәреп бәрде дә, үз урынына килеп ятты.

Аның күзеннән кайнар яшь ага башлады. Аның күзе генә түгел, аның бөтен әгъзасы — аның гәүдәсе елый. Хәзерге Садыйк кына түгел, киләчәк Садыйк та елый. Ике Садыйк берләшеп, ачы күз яше белән элгәреге Садыйкның гаебен юа башладылар.

Иптәшләре дә Садыйкның күңелендә бик зур революция барганын сизеп, Садыйк тарихында да шундый канлы вакыйга барлыгын уйлап, үз ихтыярында калдырдылар.

Аларның да күңелләрендә Садыйк өчен кайгыру башланды. Озакламады, Садыйкның яңару шатлыгы, Садыйкның тәмам яңару шатлыгы аларның күңелен күтәрде. Аларның күз алларыннан баягы үтерелгән поляк югалып, яңа туган татар — таза Садыйк күренә башлады.

Акрын гына искән җил берлә тәрәзәдән хуш ис керде. Шуның белән боларның барысында да яңа өмет уянды. Барысының да күз алдында киләчәк балкый башлады.

XX

Киткән көнне күрешкән вакытта теге карт полякның башка иптәшләр бер буйдан, Садыйкны да үбеп хушлашты. Аның күз каравыннан әллә нәрсә аңлаган кебек иттереп, Садыйкның күзенә карап: «Хуш, яшь егет. Синең фикереңүзгәрүенә шатлануым агам үлгән кайгыны оныттырды», — дип, кулын бик кысып күреште. Садыйкның күңеле бушанды. Аның вөҗдан газабын киметте.

Ул, үзенең кылган җинаяте өчен, һаман бик озын эч пошуларга мөбтәла булса да, хәзер җинаяте гафу кылынганлыгы аның иманының ныгуына сәбәп булды. Шуның өчен хәзер ул үзен авырудан сәламәтләнә торган кеше кебек, тормышның һәр бүлегеннән ләззәт сизә башлады. Киләчәкнең өмидләре белән тулып, киләчәк өчен план кора, киләчәк өчен шатлана, киләчәк өчен кайгыра — киләчәк белән тора башлады.

Яңа өмид, яңа иман, яңа тормыш аңарга әллә никадәр гайрәт бирде. Аның әллә ни кадәр көчен арттырды. Ул хәзер бик күп иттереп укый, күп иттереп уйлый, рухан бик тирән иттереп тора башлады.

Ул хәзер бик җентекләп тормышның начар якларын тикшерә, аның начарлыгының сәбәпләрен, аларны яхшырту өчен ниләр кирәклеген эзли башлады. Аның янындагы укымышлы учитель белән писарь, хәзер аның төрле-төрле сорауларына җавап бирә-бирә, аңа аңлый алмаган нәрсәләрен аңлата-аңлата арып бетсәләр дә, ул үзе

һаман арымады. Ул алты көн ач торып, җиденче көнне ашарга тотынган башкорт кебек, 40 көн ялкаулыкта ятып, 41 нче көнне торып, сугыш сафында күрсәткән батырлыгына исе киткән хорасан кебек эшкә тотынды.

Аның 20-25 ел тик яткан башы, 25 ел селкенми торган мие шул 25 ел артка калганын куып җитәр өчен ашыга, үзенең башында 25 ел әвәләгән чүп-чарын ташлар өчен миен яңалар өчен бар куәтен сарыф кыла. Шуның өчен аның рухан тәрәккый итүе простой аршин белән санарлык, простой бизмән белән үлчәрлек түгел. Ул кеше ел үскәнне ай үсә, ай үскәнне көн үсә иде.

Ул башыннан аякка кадәр үзенең сөальләре белән күмелгәнгә иртәдән кичкә кадәр шуның белән мәшгуль булганга, аның башында үзенең төрмәдәлеген уйларга, үзенең төрмәдәлеге өчен хәсрәтләнергә бик аз вакыт кала иде.

Бер авыр мәсьәләнең хәл кылынуыннан яңа мәсьәлә килеп чыкканга, берсе артыннан берсе чылбыр боҗралары кебек тезелгән ул мәсьәләләр чылбырына ябышып, бер мәсьәләдән икенче мәсьәләгә, бер боҗрадан икенче боҗрага күчкән үрмәкүч кебек күчә, мәсьәләдән мәсьәләгә сикерә иде. Мәсьәләләрнең иге-чиге күренмәгән кебек, Садыйкның да дәртенең, Садыйкның да гайрәтенең очы күренми иде.

Садыйкка төрмәдәге урыны Садыйк төсле тагын бер революционерга кирәк булмаса, Садыйк бәлки үзенең шул мәсьәләләре белән, еллар буенча да төрмәдә яткан булыр иде. Еллар буенча үзенең чиксез-чиксез мәсьәләләр белән мәшгуль булган булыр иде. Россиядә төрмәнең азлыгы, Садыйк шикелле революционерларның чиксез күплеге аның эшенең тиз йөрүенә сәбәп булды. Ябылуының алтынчы аенда ул үзенең эшенең тәмам булуы хакында приговор алды.

Бюрократия аның туйга хәзерләнүен дә, аның ватык мылтык белән мушкадан тотуын да, социаль-революционерларның (эсер) боевой дружиналарына катышу дип караганга, аны өч елга Нарымский крайга йебәрергә хөкем иткәннәре мәгълүм булды.

Бу эш аның аз гына да кәефен бозмады. Бу гаделлек аның аз гына да ачуын китермәде. Ул хәзер мондый гадәләтләрнең сәбәпләрен бик ачык белгәнгә, ул бу приговорны, гадәләтнең бу актын бик салкын кан белән каршы алды. Шулай булса да, бу яңалык аның әлгәреге тынычлыгын бозды, аны үзенең мәсьәләләреннән аерып алып, тагы простой тормышка кайтарды.

Ул да барлык төрмә кешеләре белән этапка хәзерләнә башлады. Башкалар кебек ул да әтиләренә хат язды. Ул да башкалар кебек мендәрләрен алты вершокка кадәр кечерәйтергә, багажларын хәзерләргә тотынды.

Бик күп кеше Садыйк белән бер көнне приговор алганга, төрмәнең бөтен почмагында юл кайгылары кайгыртыла башлаганга төрмә хәзер элгәреге төсен тәмам югалтты. Этапка китүчеләр әйберләр хәзерләргә тотындылар. Калучылар китүчеләргә акча табар өчен, хатлар яза башладылар. Кызлар китүчеләргә капчыклар, мендәр тышлары, күлмәкләр тегә башладылар. Йөрү вакытларында бер буйдан икешәр сәгать акча мәсьәләсе тикшерелә, кемгә күпме бирү мөләхазә кылына башлады.

Төрмә сугышка хәзерләнә торган гаскәр кебек үзенең иптәшләрен кайсысын Архангельга, кайсысын Әстерханга, кайсысын Себергә йебәрергә хәзерләнә башлады. Озак үтмәде, язылган хатларга каршы шәһәрдән, күрше авыллардан күрешергә килә башладылар. Садыйк янына да әтисе белән әнисе килделәр. Кирәкле әйберләрен сорап, ни көн этапка чыгачакларын белешеп киттеләр. Менә этап көне дә җитте.

Садыйкның әтиләре хушлашырга килделәр. Әллә никадәр ашамлык-эчемлек әйбереннән башка, Гайниҗамалның күрешергә килү хәбәрен дә китерделәр. Садыйклар бөтен иптәшләре белән бикәч катына керергә хәзерләнгән егет кебек, этапны көтә башладылар.

Текстны басмага ***Мәсгуд Гайнетдин*** *әзерләде.* ■



«АЙКАЙ СИНЕ ИДЕЛЕМ...»

Шагыйрь Казтуган Сөенеч улы (Казтуган җырау) иҗаты (як.1440-1505 еллар)

Марсель Әхмәтҗанов



Аксак Тимер яулары, Идел буендагы татарларның шәһәр һәм авылларын яндырып, талап, халыкның эшкә яраклы өлешен Урта Азиягә Сәмәрканд шәһәре якларына куып алып киткәч, татар иле 20-30 елга бик хәлсезләнеп кала.

Аннары Түбән Идел буйларындагы Сарай-Бәркә, Сарай-Бату, Әстерхан шәһәрләре тирәсендә әкренләп тернәкләнү дәвере башлана. Олы Урда, Әстерхан ханлыклары торгызылып, тормыш дәвам итә. Әлеге дәүләтләрдә утрак тормыш белән яшәү традициясе дә көчле булып, халык игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, сәүдәгәрлек белән шөгыльләнеп көн күрә. Бирегә Аксак Тимер сәясәте белән җанланып киткән күчмә тормыш алып баручы мангыт-кыпчак кабиләләре дә килеп-китеп торган. Түбән Иделдәге утрак һәм күчмә тормыш белән яшәүче татарларның мәдәнияте, рухи кичерешләре, тарихи язма чыганаклардан тыш, җырчы шагыйрьләре иҗатларында да урын алып, безнең заманнаргача сакланып калган.

Билгеле булганча, бүгенге үзбәк, каракалпак, казах, мангыт (нугай) халыкларының уртак дәүләт башлангычы булган Нугай Урдасы Әбелхәер хан (1428-1468 елларда идарә иткән) дәвере — XV гасырның беренче яртысы һәм урталарында тернәкләнеп киткән. Бу дәүләт, нигездә, Үзбәк хан дәверендә, Алтын Урдадан Урта Азиягә күчеп килгән татарлардан тор-

ган. Мангыт кабиләсе булачак Нугай Урдасының башлангычын тәшкил иткән. Мангыт йорты 1420 елларда Идел белән Җим елгалары буйларын биләп, аның башкаласы булып Сарайчык шәһәре танылган [1].

Мангыт йортының морзалары, биләре Әстерхан һәм Олы Урда ханнарына хәрби көч булып ялланып, аларның бәкләр бәге вазифаларын үтәүчеләр булып хезмәт иткән.

1428 елда Әстерхан ханы Кече Мөхәммәд Сарайчык шәһәрен дә үз кулында тотып, анда даругачы итеп Айас исемле мангыт биен куйган. Айасның исеме Татарстанның Тау ягында мәгълүм Кошман, Бишбатман, Чирмешән авыллары белән бәйле татар шәҗәрәләре текстларында да очрый [2], нәселе бүгенгәчә дәвам итә.

Шулвакытларда Идел буенда танылган Казтуган Сөенеч улы исемле шагыйрь дә яшәгән. Аның шигырьләре Нугай Урдасы халкында сакланып калган. Әлбәттә, әсәрләре Әстерхан, Сарай, Азак кебек шәһәрләрдә дә мәгълүм булгандыр.

Казтуган Сөенеч улы мирасын беренче булып татар, нугай һәм казах галимнәре өйрәнә башлый һәм текстларын бастырып чыгара. 1912 елда татар галиме Габдрахман Гомәри нәшер иткән «Нугай җырлары» басмасына Казтуганның «Айкай сине Иделем, айкай сине Иделем» дип башланган әсәре теркәлгән, «Шолпан» җыентыгына кертелгән икенче шигыре «Толкыган Ана әдип» дигән юлдан башланып китә (18 юл тәшкил итә). Казах галимнәре тарафыннан төзеп чыгарылган «Алдаспан» (1971), «XV-XVIII гасырлардагы казах поэзиясе» (1982), «Бес гасыр җырлайды» (1984) китапларында Казтуган Сөенеч улының өч шигъри әсәре кабатланып басылып килә. Аларда нугай версиясе белән уртак юллар бар, ләкин структур яктан шактый нык аерылганнар һәм казах теленә күчерелгәннәр.

Нугай версиясе татар теленә якынлыгы белән аерылып тора:

Айкай (ай-хай – М.Ә.)
сине Иделем,
Айкай сине Иделем,
Балыгы суга йылкы йаптырмас,
Бакасы төн йокысын таптырмас,
Батлаувыгы (топинамбур – М.Ә.)
чүккән төйә таптырмас,
Ботлашыгы манарадай,
Бүз сазаны токлыдай
(бер яшьлек бәрәндәй – М.Ә.),
Тамыры йиргә тараган,
Ботагы күккә караган,
Ботагы сары алкадай,
Җапрагы камкадай,
Кайраным (хәйраным – М.Ә.)
суым Идел йорт,
Калганга хирлы (хәерле – М.Ә.)
булсын Иделдән.
Җаным Идел, җан Идел [3],
Җары берлә суы тиң,
Байы берлән йарлысы тиң,
Йалгызы берлән күбе тиң,
Мин бер китәндән китәрмен,
Сатайлыны [4] билдин итәрмен,
Анык йирдин Кызыл Комын [5],
Бер тулкынланып китәрмен,
Туры Атбаш, Акчатыр [6].
Торып киңәш итәрмен
Киңәшем бер йурыкга микән соң.
Атам йорты Ак Кубан
Аңарай кушып итәрмен.
Тулкынланган Ана Идел
Тулкышып минем
Урдам кунган йорт.
Ботлашыгы [7] манарадай,
Бүз сазаны токлыдай [8]
Батлавыгы чүккән дөйә
таптырмас,
Балыгы йылкы йаптырмас,
Бакасы белән шаяны,
Төн йокысын таптырмас.
Йатып калган бер токлы
Йайылып мең куй булган йорт,
Йабагалы йәш тайлак [9]
Йардай атан [10] булган йорт,
Атамыз безнең Сөенеч
Кийәү булып барган йорт.

Анабыз безнең Бүзтуган,
Килен булып төшкән йорт,
Инде бездән буш калды,
Айхай сине, Идел йорт.

Идел елгасы мотивы татар поэзиясе мирасында бай традициягә ия. Аның иң борынгы үрнәген XI гасырда мәшһүр төрки филолог галиме Мәхмүд Кашгари теркәп калдырган борынгы сүзлектә күрәбез:

Әтил суы ака торур,
Кыйа туби кака турур,
Балик талим бака турур,
Кулуң таки кушарур [11].

Кыпчак телендә мең ел элек үк иҗат ителгән шигырь, беренче чиратта, күчмә тормыш белән яшәүчеләр тарафыннан түгел, ә бәлки Идел буендагы утрак тормыш белән көн күрүчеләр мохитендә туган. Болар өчен балыкчылык яшәүнең төп чыганагы булып саналган. XI гасыр кыпчак һәм XVI гасырдагы Әстерхан татарлары тарафыннан Иделне, аның балыгын мактап җырлау ике дәвердә яшәгән халыкның уртак тойгы, хис-кичерешләр белән янганлыгын сөйли. Шунысы кызык: Казтуган Иделнең иң затлы балыгы сазанны образ итеп, беренчеләрдән булып, шигыренә керткән. Елга буенда, балыкчылык белән көн күргән халык кына балыкның төрләрен, тәмлеләрен таный. Аларның зурлыклары турында, холыклары турында хәбәрдар була. Татар халкында җәен балыгының тирән елга ярында торган бала-чаганы һәм кечерәк сарык кебек хайваннарны сугып, койрыгы белән суга бәреп төшерүе турындагы хикәятләр дә юкка гына барлыкка килмәгәндер.

Казтуган шигырендә бөтен табигатьнең — агачларның, балыкларның, яфракларның, тамырларның сыйфатлары татарча эпитетлар белән тасвирланып бирелә. Шагыйрь ата-анасы турында язып, аларның Идел буйларында яшәүләрен күрсәтә. Казтуганның иҗаты туган илне, торган җирне ярату, ата-анага хөрмәт хисләре белән тулган.

Алда тәкъдим ителәчәк шигырьләре казах телендә дә мәгълүм булып, аларны нугай басмасы белән чагыштырып караганда, аермалар күзгә ташлана.

Аләң дә (болын-М.Ә) алаң,
аләң җорт
Ага ла Урдам кунган җорт.
Атамыз безнең бу Сөйенеч,
Кийәү булып барган җорт,
Анамыз безнең Бүзтуган
Киленчәк булып төшкән җорт,
Каргадай менә бу Казтуган Батыр
туган җорт,
Кендегемне кискән җорт,
Кер-куңымны (күзәнәк)
җуган җорт,
Карагайдан садак будырып,
Кылчанымны (ук савыты)
сары җон укка тутырып,
Җанга саклау булган җорт.

Мисалдан биш йөз ел эчендә телдән-телгә йөреп шигырь нинди үзгәрешләр кичергәнен күзәтү мөмкин. Бу күчмә халык әдәбиятының текстологиясе өчен дә кызыклы. Нугай шагыйрьләре әсәрләренең казах теленә адаптациясе законнарын өйрәнү өчен дә яңа тема ача. Әлеге 500 еллык шигырьләр нугай, казах өчен генә түгел, татар мәдәнияте өчен дә әһәмиятле. Әйтик, нугай шагыйрьләренең XX йөз башында язып алынган шигырьләренең теле, бүгенге татар укучысына казах телендәге версияләрне аңлаудан шактый җиңел. Моннан без хәзерге татар теле белән Нугай Урдасы татарларының теле арасында зур уртаклык булуын ачабыз. Икенчедән, бүгенге казах теленең формалашуына Нугай Урдасы татарлары теленең тәэсир күләмен күзаллау мөмкинлеге туа.

Казтуганның казах галимнәре тарафыннан язып алынып, бүгенге нугайларда сакланмаган ике шигыренә күзәтү ясап китик.

МАДАК (МАКТАУ)

Будырайган [күпергән] ике кабыгы,
Баштан-аяк яхшы көбәле,
Мәхәббәтле карт
солтандай йөрешле,
Әдернәсенә хәтле җефәк,
укка керешле,
Әйдәсә куйның башлыгы,
Сөйләсә кызыл телнең чичәне,
Теләсә качкынны тоталган
озын корыгы,
Шомартылган куе кашлы
Урданың терәге.
Биләр атлы би нәселе,
Би улының кечесе,
Йәш дөянең куак чәйнәр азау теше,
Карчыганың күл югалткан ялгызы
Болыт булып айны каплаган.
Манара булып кояшны каплаган.
Мөселман белән гавернең
Арасын бозып үтеп, динне каплаган
Сөенеч улы Казтуган.

Бу шигырьдә, Казтуган Сөенеч улы үзен мактап яза. Шул ук вакытта шигырьдә аның борынгы биләр нәселеннән гаиләдә кече угыл булганлыгы, сугышка барса, яхшы нык коралланып баруы, сугышта оста яугир булуы, аның мөселманнар белән кяферләр арасындагы сугышларда катнашып, батырлыклар күрсәтүе тасвирлана.

Күккә җиткән биек тау,
Башыннан карга очырмас,
Ир каравыл карар дип,
Ерактан кара шәйләр дип,
Балдагы алтын-корыч-булат,
Ачылып чапсам, сулышым кысар,
Сусавым канга коелыр дип,
Аргамакның баласы,
Арган сайын тын йуртыр,
Аркамда кушып калыр дип.
Ак дәрйа дулкын көчәйтер,
Койрыгын көн күрмәгән балыгым,
Уртамнан вәйран салар дип.
Азамат ирнең баласы
Җабыкканын белдермәс,
Яманнар миннән көләр дип.

Казтуганның бу шигырендә горур, гайрәтле кешенең эстетик фикерләре тасвирлана. Ул үзен таудай бөек кеше, аның өстеннән вак адәмнәр (каргалар) йөрергә лаек түгел, дип саный. Каравыллар, күзәтүчеләр, шагыйрьнең иреген буар кешеләрдән үзен өстен хисаплый. Шагыйрь үзен ашыгып, тыны бетеп эшләүчеләрдән югары булырга лаек, дип саный. Батырларның бөек фәлсәфәсе — «Авызың тулы кан булса да, дошман алдында төкермә», дигән фикер белән яши. Шагыйрь 1440-1505 елларда яшәгән, дип чамаларга була.

Казтуган Сөенеч улының иҗатында, урта гасыр мәдрәсәләрендә белем алып үскән шагыйрьләрдән аермалы буларак, дин, оҗмах, гөнаһ, үлем фәлсәфәләре бөтенләй юк. Ул гасырлар дәвамында хасил булган мәкальәйтемнәр, чичәннәрнең каламбур сүзләре моделендә иҗат итеп яшәгән. Кешелеклелек идеалларына тугры, горур шагыйрь булган.

Казтуганның иҗаты, нәсел тамырлары Нугай Урдасына бәйләнешле татар, үзбәк, каракалпак, кыргыз, казах һәм башка төрки кардәшләребезнең уртак хәзинәсе булып, әлеге халыкларны рухи мәйданда берләштерүгә хезмәт итәргә тиеш.

Чыганак:

1. Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. — М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 2001.
2. Кошман силсиләләреннән бер өзек. Мөхәммәт Хәмитов шәҗәрәсе Һ.б. // Әхмәтҗанов Марсель. Татар шәҗәрәләре. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.
3. Бу шигырьне Әстерханда Габдерахман Гомәри язып алган булган. Габдерахман Гомәри. Җыентык. — Казан: «Рухият» нәшр., 2003. — Б.132-133.
4. Сатайлы — елга исеме.
5. Кызыл Ком — Төньяк Кавказдагы елга исеме.
6. Туры Атбаш, Акчатыр — тау исемнәре.
7. Ботлашыгы — биек чүп үлән.
8. Токлыдай — бер яшьлек сарык бәрәнедәй.
9. Йәш тайлак — ике яшьлек дөя.
10. Атан — зур, ата дөя.
11. Махмуд ал-Кашгари. Диван лугат ат-Турк. — Алматы: «Дайк-Пресс», 2005. — С.106. ■



БӘЯЛӘМӘ...

Рәмзи Вәлиев

XX гасырның 70 еллар башы. Хакимиятнең яңадан шәхес культын торгызып, янәдән зыялыларны эзәрлекләү башланган дәвер. Бер-береңнән шикләнүләр, кыю фикер ияләренә сары йортка такыр юл салулар, эштән куулар һәм башка төрле кимсетүләр ил буйлап киң таралган чор.

Нәкъ шушы чорда мин Казан дәүләт университетының СССР тарихы кафедрасына Татарстан тарихын укытуны оештыру өчен эшкә чакырылдым. Әлбәттә, аспирантураны уңышлы тәмамлаганнан соң, миңа — фәлсәфә, фәнни коммунизм предметларын укыткан кешегә — тиз арада Татарстан тарихын укытырга керешү әллә ни авыр булмады. Университетка кайткач, күңел күтәренке, ничектер барысы да уңай тоелды. Ул вакытта тарих-филология факультеты химия корпусының дүртенче катында иде. Бөтенебез дә бер коридорда мәж киләбез. Безнең кафедра каршында ук татар әдәбияты кафедрасы урнашкан. Андагы мөгаллимнәрнең шактыен студент чагыннан ук белеп, исәнләшеп йөри идек. Нигәдер безне башта ук Әнвәр Ахунҗанов, Зәет Мәҗитов, Мостафа Ногманнар үз итеп кабул иттеләр. Коридорда очрашып агымдагы сәясәтме, хәл-әхвәл сорашумы яисә анекдотымы — барысы да сөйләнә, тыңлана. Бу бәхәсләрдә гадәттә тарихчылардан минем якын дустым, бергә биш ел ботка пешерүчем Индус Таһиров, Мөхәммәт Мәһдиев, Илдус Гыйләҗев, Рүзәл Юсупов, Миркасыйм Госманов белән Әзһәр Мөхәммәдиевләр була иде. Соңгы икесе, филология бүлегеннән күчеп, тарихчы булып та киттеләр һәм югары гыйльми уңышка ирештеләр.

Сөйләшүләр вакытында Мөхәммәт, тыныч кына тыңлап тора да, сорау биреп куя. Кемдер җавап бирә алмаса гына, сүзен үлчәп, фикерен әйтә. Аның күп мәсьәләләр хакында үз фикере бар. Шул рәвешле, ул безне ничектер үзенә җәлеп итеп тора иде. Ул елларда, без, 60 нчы еллар җылылыгы белән эш башлаганнар, 70 нче елларның зыялыларга карата булган астыртын сәясәтен сизми дә калганбыз. Әмма дә тиз арада хакимият, партия органнары шәхес культының кайбер алымнарын безгә сиздерә башлады. Мөхәммәт, һичшиксез, сәясәтнең үзгәрүен беренчеләрдән булып тойгандыр. Шулай булса да, ул 60 нчы елларда башлаган фәнни хезмәтен ташламады, кыю рәвештә алга барырга теләде. Менә шушы елларда безнең барыбызга да, бигрәк тә сак була белмәүчеләргә, шактый авыр сынауларны узарга туры килде. Киресенчә, безнең ише ачык авызларны тәнкыйть итеп капитал җыючылар начар яшәмәде, әмма аларның күбесе бүген авыр хәлдә калды. Бик сирәге генә хәзерге тормышка ярашып рәхәт яшәүне дәвам итә. Без моңа ирешә алмадык, чөнки системага, югарыдагыларга юл тотмый, үз юлыбыз белән бардык. Башкача эшләүгә гакылыбыз да, рухи ихтыярыбыз да кушмады. Җилкәбезгә авыр йөкне салдык.

Тыштан шактый сак күренгән Мөхәммәт, дөреслек турында сүз барганда сакланмады — әйтәсен әйтеп салды, кире кайтып үз фикерен төзәтмәде, кызыллыкны ассызыклап күрсәтмәде, чөнки ул чын галим иде. Аның тәвәккәл кырыслыгы һәм шикләнеп эш итүе әтисенең утызынчы елларда тоталитар режим тарафыннан гаепсез хөкемгә тартылуыннандыр, диясе килә. Мәһдиев Сөнгатулла Бәдретдин улын 1933 елда контрреволюцион оешманың Арча районы ячейкасын җитәкләүче, диеп гаепкә тарталар.

1970 елларның бер корбаны Мөхәммәт Мәһдиев булды. Мөхәммәт, бернинди авырлыкларга карамыйча, XX гасыр башындагы җәмгыяви-сәяси процесслар турында катлаулы тема өстендә эшләп, докторлык диссертациясе әзерләгән иде. Аның хәле белән мин очраклы рәвештә таныштым. Шулай беркөнне, эшләремне тәмамлап кайтыйм, дип торганда гына кемдер: «Рәмзи Кәлимуллович, сезне Хатип Госманов үзенә чакыра», — диде. Әдәбият кафедрасы хуҗасына мин нигә кирәк булдым икән, дигән фикер белән күрше кафедрага ашыктым.

Хатип Госманович үз кабинетын-

да иде. Аның белән исәнләшкәч, мин ишек төбенәрәк утырып сүз башлавын көттем. Ул түрдә — ашыкмады. Креслосында уңайлырак утыру теләгеме яисә уңайсызлыктанмы, ул ничектер күзгә туры карамый, гәүдәсен креслосында боргалап, авыз-борыннарын сөрткәләп: «Рәмзи Кәлимуллович! Без кафедра утырышында Мөхәммәт Мәһдиевнең докторлык диссертациясен карадык. Тарихи-әдәби хезмәт. Менә шуңа күрә бер тарихчының аны укып, бәяләмә бирүе кирәк иде бит», — диде. Мин Мөхәммәт өчен шатланып: «Ярый, укырмын», — дидем. Ул өстәле артында боргалануын дәвам итеп: «Аның эшендә теоретик-методологик хаталар бар, шуларны исегездән чыгармагыз, Рәмзи Кәлимуллович!» — дип, утырган җиреннән торып басты. Бу инде — эш бетте, сез ирекле, дигән ишарәсе икәнен аңлап, кульязманы алып чыгып киттем.

Хатип аганың соңгы сүзләреннән мин шуны аңладым: ул Мөхәммәтнең эшен уздырмаска тели, чөнки 60 нчы еллар азагында һәм бигрәк тә 70 нче елларда теоретик-методологик хата ясау — синең хезмәтең марксизм-ленинизм күрсәтмәләренә туры килми, дигән сүз. Шулай булгач, мондый хезмәтнең язмышы бер — алар бер инстанциядән дә уза алмыйлар, уңышсызлыкка дучар булалар. Менә шуңа күрә дә инде, Хатип ага, минем кул белән Мөхәммәтнең марксизм кысаларына сыя алмаган хезмәтенә киртә салырга уйлый. Мин моны әле яшь булсам да аңлый алганмын. Аның кабинетында ук шундый фикергә килдем: болай булгач, уңай бәяләмә язачакмын, чөнки монда фән күзлегеннән чыгып фикер йөртелми, монда Хатип аганың үз сәясәте.

Шул ук кичне аның хезмәтен укып чыктым. Бик тә үзенчәлекле һәм чыганакларга бай хезмәт иде ул. Әлегә кадәр беркем тарафыннан да файдаланылмаган, «бик тә яшертен» билгесе астында сакланган жандарм идарәсе документлары нигезендә язылган. Ф.Кәрими, Ю.Акчура, Дәрдмәнд, Ф.Әмирхан, Г.Тукайга һәм башкаларга кагылган материаллар тупланган. Шулай ук Фәннәр Академиясе архивын яхшы өйрәнгәнлеге күренеп тора. Галимҗан Шәрәф, Нигъмәт Хәким, Җәмал Вәлиди, Г.Ибраһимов, С.Атнагуловлар хакында сакланган чыганаклардан да шактый киң файдаланган. XX гасыр вакытлы матбугаты да тирәнтен өйрәнелгән. Шул чордагы татар зыялыларының хезмәтләренә дөрес бәя бирелгән. Гомумән алганда, Мөхәммәт тоталитар режим алымнары белән санашмыйча дөрес, гадел итеп язуны алгы планга куйган. Әлбәттә, тарихчылар һәм әдәбиятчылар репрессиягә дучар булган татар зыялыларын белсәләр дә, алар турында язарга кыюлыклары җитмәде. Әлеге эш бары тик 1989 елдан соң гына башланды. **Күрәсез, Мөхәммәт Мәһдиев бу өлкәдә тарихчылардан бер ун-унбиш ел алда эш башлаган булып чыга. Аның бөтен «гаебе» дә менә шунда.**

Гомумән, 1970 елларда кыю фикер йөрткәннәрнең барысы да зыян күрде. Казан дәүләт университетыннан күренекле галимнәр китәргә мәҗбүр булды. Алар арасында остазым Әгъдәс Борһанов та бар иде. Тарих-филология факультетының күренекле галиме Шамил Мөхәммәдъяровның Якутиягә кадәр китеп, соңрак Мәскәүдә төпләнүе дә безнең өчен зур югалту булды.

Мөхәммәт Мәһдиевнең дә маҗаралары шушы елларга туры килде. Аның үзенә сүз бирик әле. 1990 елның ноябрендә Газинур Морат белән әңгәмәсендә Мөхәммәт Мәһдиев бу турыда түбәндәгеләрне әйтә: *«1972-1974 елларда миңа университет докторлык диссертациясе язу өчен 2 еллык түләүле ял бирде. Байтак эшем инде эшләнгән, материал җитәрлек тупланган иде. Ләкин бер бәхетсезлек килеп чыкты: 1971 елда мин «Фронтовиклар» дигән роман язып, кульязмасын «Казан утлары» журналына тапшырган идем. Иҗат ялымның икенче*

атнасында ук журналның 1 нче саны килде, ә анда — «Фронтовиклар»ның бер өлеше. Коллегаларым гаҗәпкә калды: «Ничек? — диде алар үзара фикер алышканда. — Ничек? Ул бит түләүле ялда, диссертация язарга тиеш, ә ул роман язып ята. Бу бит хөкүмәтне алдау!»

Һәм берничә көннән мине партия контроле комиссиясенә чакырдылар...

«Иҗат ялы» дигәнем әнә шулай җәнҗал белән башланды. 2 ел эчендә мин, әлбәттә, диссертациямне язып бетердем. Яклау өчен аны монография итеп бастырып чыгарырга кирәк иде. Кафедрада тикшергән вакытта Х.Госман хезмәткә «Сыйнфый подход җитеп бетми» дигән мөһер сукты, һәм ул берничә ел буе планга кертелмәде. Бары тик 1978 елда гына университет нәшриятының планына керттеләр. Көзен мин моның корректурасын укыдым. Х.Госманның «сыйнфый подход»ын истә тотып, хезмәтемне гел кызартырга тырыштым. Ләкин аның басылып чыгуына ышанычым юк иде. Чөнки аны, обком аппаратчылары кушуы буенча, 2-3 тапкыр рецензияләтеп алганнар иде. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты секторлары моны дөньяга чыгармас өчен байтак көч куйды. Шундый борчулы ыгы-зыгы белән кыш узды. Китап күренми дә күренми. Ул арада җәй җитте. Менә беркөнне миңа телефоннан бер кырыс кына тавыш: «Иртәнге 10га обкомга, фән бүлеге мөдире Миндубаев янына килегез», — дип әмер бирде».

Анда декан Д.Тумашева, проректор Ш.Хәбибуллин, партком секретаре һәм нәшрият директорлары да булалар. Нәтиҗә бер: монографияне чыгармаска!

Хатип Госмановичның үтенечен мин төгәл итеп үтәдем. Әлбәттә, бәяләмә уңай иде. Әле дә исемдә: мин анда «работа отвечает современным высоким требованиям» кебек сүзләр язган идем. Менә шуннан соң әдәбият кафедрасы җитәкчесе Хатип аганың миңа мөгаләмәсе үзгәрде... Кафедрада эшне тикшергәндә дә мине чакырмады. Күрәсең, ул миннән тискәре бәяләмә көткән. Билгеле булганча, Мөхәммәт докторлык диссертациясен яклый алмады. Әлбәттә, бу бик тә кызганыч хәл иде. Мин эш шуның белән тәмамлангандыр, дип уйлаган идем, соңрак, Мөхәммәтнең «Идел» журналында югарыда китерелгән әңгәмәсе[1] нәшер ителгәч кенә, мәсьәләнең нинди җитди булганын аңладык...

Шушы вакыйгалардан соң без Мөхәммәт белән шактый якынаеп киттек. Университеттамы, урамдамы — без аның белән рәхәтләнеп фикер алышабыз. Нәкъ шулвакытта ул романнар яза башлады һәм зур уңышларга да иреште. Соңрак Казанга Тәлгат Галиуллин да кайтты. Күп вакыт мин аларны бергә күрә идем. Бу вакытларда без сөйләшү генә түгел, шактый көлешә дә башлаган идек...

Тукай музеен аякка бастырган дустыбыз Госман Хәбибуллин тырышлыгы белән, беренче тапкыр Галимҗан Шәрәфкә багышланган кичә-очрашу уздырылган иде. Монда Мөхәммәт Мәһдиев тә килде һәм ялкынлы чыгыш ясады. Кичәдә Галимҗан Шәрәфнең туганнары, хатыны Әсма апа, улы Арслан да бар иде. Язучылардан Тәлгат Галиуллин, Җәвад Тәрҗемановлар да Совет власте тарафыннан репрессияләнгән татар галиме Галимҗан Шәрәф хакында кызык фикерләр әйтте. Бу кичә Ризаэддин Фәхреддин кызы Әсма һәм оныгы Арслан Шәрәфләр өчен бик тә үзенчәлекле иде. Гомер буе куркытылып яшәгән Арслан Шәрәф өчен дә мәңге онытылмаслык булып калды. Шушы вакыйгалардан соң ул ачылып китте, факультетка килеп, минем янда озак кына

[1] Әлеге әңгәмә 1991 елда «Идел» журналында басылып чыкты.

утырып, сөйләшкәләп, хәл белеп китә иде. Чыннан да, алар бу кичәдән соң кыюрак сөйләшә башладылар.

Заманалар уңай якка үзгәрде. Бу үзгәрешләрне Мөхәммәт тә җанытәне белән беренчеләрдән булып сизде. Шулай беркөнне эшкә килгәндә, университетның төп бинасы каршында очрашып, гадәттәгечә фикер алышканнан соң, миңа туры карап: «Рәмзи, минем теге хезмәтем китап булып чыга бит, бәяләмә язып бир әле», — диде. «Мөхәммәт, ә теге бәяләмә синдә сакланмаганмы соң?» — дип сорау бирүгә, ул елмаеп: «Сакланган», — диде. Үзе миңа карап көлә. Мин дә көлебрәк: «Алай булса, шуны яңадан бастырып алып кил әле, кул куярмын», — дидем. Шулай булды да. Аның әлеге «Социальные корни таланта» дип исемләнгән хезмәте 1990 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында дөнья күрде. Китапның титул битенә: *«Рәмзи дуска! Соңга калган китабым. Ихтирам белән, автор — М.Мәһдиев. 1990 ел. 22 октябрь»,* — дип язып бүләк итеп тә бирде.

Гыйльми хезмәт 1910-1917 еллардагы иҗтимагый-әдәби тормышка багышланган. Китапта татар әдәбиятында халыкара вакыйгаларның чагылышы, гомумватан һәм әдәбят, публицистикада тигез хокуклылык мәсьәләсе, татар демократик әдәбиятына «кара көчләр» һөҗүме, татар әдәбиятында «кара көч» образы кебек проблемалар тикшерелгән.

Автор үзенең китабы турында болай дигән иде: *«Еллар узды, мин әлеге монографияне урысчага үзем тәрҗемә итеп, бик тә әзерлекле бер мөхәррирдән укытып төзәттердем, һәм илдә ислах чоры башлангач, «обком» дигән аппараттан надан түрәләр очарга керешкәч, кульязмамны кабат университет нәшриятына илтеп бирдем. 1990 елның җәендә ул басылып чыкты. Китап «Социальные корни таланта» дип атала. Ләкин ул миңа бернинди дә шатлык китермәде. Чөнки*

андагы байтак мәгълүматлар урланган булып чыкты». Мондый хәлләр әле дә дәвам итә. Кандидатлык, докторлык диссертацияләре бары тик рус телендә генә кабул ителә. Габдрахман Хафизов, Гамирҗан Дәүләтшин, Фәридә Гафарова кебек галимнәр татарча язган хезмәтләрен русчага күчереп күпме көч түктеләр. Бу да факт.

Соңрак без Мөхәммәт Мәһдиев белән хезмәттәшлек тә итә башладык. 1980 еллар азагында мин партия архивында Галимҗан Шәрәфнең Сталинга язган хатын таптым. Ул русча язылган иде. Мөхәммәт ул хатны күргәч,

шаккатты. Галимҗан Шәрәфкә җылы мөгаләмәсен белдерде. Шуннан файдаланып мин: «Мөхәммәт Сөнгатович, әйдә, син бу хатны татарчага тәрҗемә итеп бир әле», — дидем. Ул аны тиз арада тәрҗемә итеп китерде. Нәтиҗәдә, 1990 елның май аенда булса кирәк, «Әлмәт таңнары» газетасында, шул елның 1 июнендә «Социалистик Татарстан»да «Тарихыбыз архивларда» исемле уртак мәкаләбез дөнья күрде. Мин Мөхәммәт Мәһдиевнең зирәк тарихчы икәнлеген аңладым, әмма ул әдәбият галиме булып киткән.

Без аның белән «Узган еллар авазы» дигән шактый зур күләмле уртак мәкаләбезне «Казан утлары» журналында бастырып чыгардык. Мәкалә «җидегәнче»ләргә багышланган иде. Әлеге тарихи ачыш та, һичшиксез, Мөхәммәт дусның тырышлыгы белән киң җәмәгатьчелеккә җиткерелде. Язучы Айдар Хәлим 2002 елның 2 августында язган хатында: «Җидегәнчеләр турында күземне ачтың, рәхмәт сиңа!» — дип язган иде. Бу рәхмәт сүзе Мөхәммәт Мәһдиевкә дә, чөнки әлеге мәкалә — безнең уртак иҗат җимешебез. Язучылар хакындагы материалларны мин язучы каләме аша уздырып дөрес эшләгәнмен. Рәхмәт аңа!

Шулай матур гына эшләп йөргәндә, Мөхәммәт белән сирәк очраша башладык, ә соңрак аның авырып китүе хакында хәбәр таралды. Соңгы мәртәбә мин аны трамвайда барганда, «горняк» кибете борылышында күрдем. Трамвайдан төшеп булмый иде, ул да китеп югалды. Мин аны халык арасына кереп югалганчы карап озаттым. Бу — аны соңгы күрүем булган икән. Алай авыруга да охшамаган, матур кара күн плащтан, йөзе генә бик кырыс, уйчан иде...

Озак та үтмәде, аның вафат булу хәбәре килде. Шулай итеп, талантлы әдәбият галиме, язучы, тарихчы — вакыты җитми торып, безне ташлап китте. Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын!

1953 елның октябрь азагында армиядән кайтып, туган ягымда өч-дүрт ел эшләгәннән соң, сентябрь аенда миңа военкоматтан: «3 айга хәрби сборга, Амур флотилиясенә барырга!» — дигән повестка җибәрделәр. Бер дә теләмичә ерак китәсем килмәде. Беренчедән, читтән торып, авыл хуҗалыгы институтында укыйм, чираттагы сессиягә бара алмавым ихтимал. Икенчедән, хатынымның беренче балабызны табу вакыты җитеп килә иде. Өченчедән, мин моряк түгел бит. «Нигә бик еракка — Амур флотилиясенә озатасыз?» — дип тә әйтеп карадым, җибәрмәүләрен сорадым. Үтенечемне кабул итмәделәр. «Син Тын океан флоты офицерлары резервында торасың, безнең башка кандидатурабыз юк», — дип җавап бирделәр. Авылдашым — военкомат хезмәткәре Сөнгатулла абый Яруллин мине Кукмарага кадәр озатты. Билет алып, поездга утыртып җибәрде. Бу юлы, пассажир поезды вагонында рәхәтләнеп, тәрәзәдән мәһабәт Урал тауларын, данлыклы Байкал күлен, иксез-чиксез урман-далаларны һәм шәһәр-авылларны хозурланып күзәтеп бардым.

Амур флотилиясенең укыту базасында үзебезнең чордаш офицерлар белән таныша башладык. Татарстаннан без элемтәчеләр ротасында өчәү булдык: Арчадан — **Мөхәммәт Мәһдиев**, Сарманнан — **Фәйзрахман Гыймазетдинов** һәм бу юлларның авторы. Берничә көннән соң, без яшәгән торакның икенче катында — механиклар ротасында — Балык Бистәсе районыннан килгән тагын бер егет табылды. Соңыннан аның якташым

ЯЗМЫШЫМ БҮЛӘГЕ

Миннәхмәт Кашапов*

булуы — Тәкәнеш районының Игенче авылында туган **Нургали Миңнеханов** (булачак Президентыбызның әтисе!) икәнлеге ачыкланды. Шулай итеп, Татарстаннан дүртәү булдык!..

...Амур флотилиясендә бергә булган чакта Мөхәммәт туган ягы Арча, аның булдыклы кешеләре, күргән-ишеткәннәре турында, төрле мәзәк хәлләрне дә өстәп, бик тә мавыктыргыч итеп сөйли белә иде. Коеп куйган укытучы икәнлеге, һөнәрен дөрес сайлаганы әллә кайдан сизелә. Өстәвенә, рус телен дә яхшы белә — шуңа рус егетләрен дә үз авызына каратып тота...

***

...Берзаман мин Мөхәммәт кордашымның «Торналар төшкән җирдә» дигән атаклы әсәреннән түбәндәге юлларны укып, бик тәэсирләндем, дулкынландым:

«...Тәпи йөри башлау белән мин гел үзебезнең авылдан көньякка — Кояшка таба чыгып китәргә кызыксындым. Хыял гел шул якка тарта иде. Моның сәбәбен мин илле яшемә җиткәндә генә белдем. Мине бабайлар туфрагы тарткан икән. Чөнки әти ягыннан бабай бездән көньяк-көнчыгышта урнашкан Тәкәнеш ягыннан күчеп килгән; әни — көньяктагы Симет авылыннан. Күрәсең, аларны да кан тарткан, ә ул «тарту» миңа да күчкән».

...Аның шул хакта язып калдыруы: «Ул да мине эзләгән, ахры», — дигән фикеремне, хисләремне көчәйтте...

Шулай итеп, мин Мөхәммәт кордашымның безнең Тәкәнеш ягыннан икәнлеген сиксән яшем тулгач

Мөхәммәт Мәһдиев – Хәрби-Диңгез флоты офицеры

кына белдем. Аның нәсел агачы тамырларының безнең яктан булуы минем аңа булган игътибарымны һәм ихтирамымны тагын да көчәйтеп, дәрт өстәп җибәрде.

Тәкәнеш районының Урта Тәкәнеш авылында туып-үскән, укыган, 32 яшемә кадәр Тәкәнеш районы үзәгендә яшәгән, эшләгән, районыбызның һәр авылында булып, бик күп якташларымны белгән кеше буларак, чиксез зур кызыксынуым белән, эзләнү эшләрен башлап җибәрдем. Шөкер, Мөхәммәтнең бабаларының кем исемле, кайсы авылдан булуларын да таптым. Миңа бу өлкәдә Татарстан Милли архивы хезмәткәрләре зур ярдәм

* Миннәхмәт Кашапов (1930) — Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Россия Федерациясенең атказанган экономисты; публицист.

Солдат Сөнгатулла Бәдретдинов (уңда) Сабаның Шәйрән Елга авылы егете Гыйльметдин Шәйхетдинов белән. Вильна (хәзерге Вильнюс шәһәре, Литва). 1907 ел, март

иттеләр. Аларга бик тә рәхмәтлемен!

Чыннан да, Мөхәммәтнең Мөсәлим, Мәһди һәм Бәдретдин исемле бабалары безнең Тәкәнеш районы, Югары Өскебаш (халык телендә — Казаклар) авылында туып-үскәннәр, яшәгәннәр икән. Хәзер бу авыл, Тәкәнеш районы беткәннән соң, Кукмара районы составына керә. Мин әлеге шактый зур, матур авыл турында «Чорыбызның данлыклы шәхесләре» дигән очеркымда язган идем инде. **Анда кордашым Нургали Миңнехановның хәләл җефете Васига Мөбарәкҗан кызы туган, балачак һәм үсмер елларын шул авылда уздырган. Нургали белән Васиганы — булдыклы, игелекле өч ул тәрбияләп үстергән шәхесләр буларак — халкыбыз яхшы белә.**

Советлар Союзы Герое Сабир Әхтәмовның да (1926-2014) туган авылы ул Югары Өскебаш! 88 яшенә кадәр Казанда яшәгән Сабир ага туып-үскән төбәгенә еш кайтып йөрде. Ул — Республикабызның Бөек Ватан сугышындагы иң яшь Герое иде...

Мөхәммәтнең Тәкәнеш ягыннан Арча якларына күчеп киткән бабасы Бәдретдин исемле була. Ул Югары Өскебаш авылында Мәһди Мөсәлимов гаиләсендә туып-үскән, укыган, дини белем алган — имам-хатыйп һәм мөгаллим дигән дини дәрәҗәләргә ирешкән. Аны 28 яшендә Мамадыш өязенең Сикертән авылына (хәзер Арча районы составына керә) 1857 елның 19 сентябрендә 100 ел элек төзелгән мәчеткә мулла итеп билгелиләр. Сикертән — ул вакытта 137 хуҗалыгы булып, 883 кеше яшәгән борынгы авыл. Мулланың еллык хезмәт хакы 140 сум булуы да билгеле архив документларында.

1885 елның 1 гыйнварында Бәдретдин мулла һәм Шәмсеямал абыстай Мәһдиевләр гаиләсендә уллары Сөнгатулла дөньяга килә. Ул, авыл мәдрәсәсендә укып, дини белем ала, мулла булырга әзерләнә, әтисенә ярдәм итә. Сөнгатулла 26 яшендә, Диния нәзарәтенә барып, сынаулар бирә. Аңа 1911 елның 15 июнендә «имам-хатыйб һәм мөгаллим булырга сәләтле» дигән сүзләр язылган 3877 нче санлы таныклык тапшырыла. Аңа кадәр Сөнгатулла Сатыш мәдрәсәсен, Арча татар башлангыч училищесын тәмамлый. 1906 елның 20 августында бирелгән 360 нчы санлы таныклык шуны раслый.

Сөнгатулла Бәдретдиновның 107 нче Троицк пехота полкында хәрби хезмәттә булуы да билгеле.

Казан губерна идарәсе тарафыннан 1915 елның 19 сентябрендә бирелгән 3466 номерлы карар нигезендә, Сөнгатулла Бәдретдин улы 30 яшендә Малый Муй (Гөберчәк) авылына мулла итеп билгеләнә.

Бу гаиләнең Гөберчәк авылында яшәгән чоры, анда булган фаҗигале хәлләр — әтисенә «халык дошманы» дигән нахак исем тагылып, кулга алынуы һәм 1938 елда аның атып үтерелүе

Миннәхмәт Кашапов: «Гүрең якты, рухың шат бул-сын, Мөхәммәт кордаш! Син – гел истә, халкыбыз хәтерендә...»

турында Мөхәммәтнең әсәрләрендә җаны, йөрәге әрнеп язылган юлларны яхшы хәтерлиләрдер укучыларыбыз... Аларны кабатлап язып тормыйм...

Бу нәселнең (Бәдретдиннең, Сөнгатулланың, Мөхәммәтнең) Мәһдиев дигән фамилиясе Мәһди Мөсәлимов (русча «Магадей Мусалимов» дип язылган архив документларында) исемле бабаларыннан башланган икән. Аның турында өстәмә белешмәләр табылды. 1834 елгы ревизия документларында Мәһди Мөсәлимовның Мамадыш өязе, Югары Өскебаш авылында йомышлы (служилый) татар икәнлеге, 45 яшьтә булуы, хатыны Газизә (43 яшь), кызлары Камилә (18 яшь), Хөсни (12 яшь), Шәмси (9 яшь), уллары Мөхәммәди (15 яшь), Хөснетдин (7 яшь), Бәдретдин (5 яшь), Җиһанша (3 яшь) икәнлеге язылган. (Фонд 3, опись 2, эш 69, 98-99 нчы битләр)

Мөхәммәт Мәһдиев муллалар гаиләсенең дәвамчысы булган икән. Дөньялар үзгәрмәгән булса, бәлки, ул да бик дәрәҗәле, хөрмәтле муллага әверелер иде.

Мөхәммәтнең нәсел агачы киң тармаклы: Мөсәлим — Мәһди — Бәдретдин — Сөнгатулла — Мөхәммәт — Искәндәр... Әлеге күркәм шәхесләрнең тамыры безнең Тәкәнеш ягыннан булуына, аларны табуыма бик тә шатландым һәм горурландым. Язмышыма, шундый бүләге өчен, аеруча рәхмәтлемен!..

Без ачлыкны ешрак күрдек шикелле...

Әдәбиятыбыз классигы Мөхәммәт Мәһдиевнең әлеге хатын укыганда үзеннән-үзе «Без — кырык беренче ел балалары» әсәре күңелгә килә, андагы шук-шаян да, уйчан-гамьле дә әдәби геройлар бер-бер артлы күз алдына килеп баса, һәм шулар арасында Яхъя Халитов атлы үсмер егет образы да, һичшиксез, урын алгандыр, дип уйлап куясың. Ник дигәндә, алар Арча педагогия училищесында бергә укыган, соңгы телем икмәкне бүлешкән, «ата кара тараканның кан әйләнеше»н бергәләп өйрәнгән сабакташлар ич.

Быел Яхъя агага 85 яшь тулды. Ул иҗади сәләтен тулысынча тәрҗемә эшенә багышлады, урыс һәм дөнья әдәбиятының байтак җәүһәрләрен татар телендә яңгыратты. Алар арасында Михаил Шолоховның «Тын Дон», «Күтәрелгән чирәм», Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры», «Бәхил бул, Гөлсары», «Дөя күзе», Александр Дюманың «Өч мушкетёр», Майн Ридның «Башсыз җайдак» әсәрләре бар.

Әлеге хатны ТР Милли музеена Яхъя Халитовның хәләл җефете Сания апа Сибгатуллина тапшырды. Ул матбугатта беренче мәртәбә басыла.

Флүрә Дәминова,
Татарстан Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре

Яхъя дус!

Шушы көннәрдә генә «Тын Дон» китабының татарча чыккан сигнальный экземплярын күрдем дә, сиңа бер хат язарга уйладым әле. Бик зур һәм изге эш башлагансың бит, малай. Аны инде исән-сау, сәламәт килеш бөтенесен дә башкарып чыгарга һәм безгә үз кулыбыз белән тотып укырга насыйп булсын иде. Шул китапны кулыма алгач, ирексездән, безнең бергә узган малай вакытлар, «тормыш университетларыбыз» искә төште. Менә шундый вакытлар бар иде бит: син әтәч булып карават өстенә басып кычкырасың, шул вакытта сиңа Шәрип (ни өчендер шуны Шәриф дип әйтелмәгән) бәрәңге ыргыта иде, тотылган һәр бәрәңге синеке була иде. Ә мин, мескен, әтәч булып та кычкыра алмый идем, шундый һөнәре булган кешегә кызыгып карап тора идем. Синең белән мин, ничектер, ул ачлыкны ешрак күрдек шикелле, ул гына да түгел, ачлык темасына без бик еш әңгәмә алып барырга да башкаларга караганда яратыбрак тотына идек, ахрысы. Синең ул вакытта кия торган киемең соры төстәге спортивный костюм, ә минеке ала-тилә итеп



манылган киндер чалбар иде (шуны кигән көе кич белән Рфәйдә исемле кызый янына китә идем). Синең гәүдә бик озын булганлыктан, ачлык фаҗигасе синең кыяфәттә тагын да куркынычрак була иде кебек Шуңа күрә, мин сиңа, ничектер, «кырык җиденче елның диаграммасы», дип әйткән идем. Синең ул сүзгә ачуың килде, тамак тук вакыт булса, шиксез, эш алай гына бетмәгән булыр иде, ләкин хәерчелекнең соңгы чигендә кеше шул дәрәҗәгә җитә ки, яхшылык өчен рәхмәт әйтми һәм яманлык өчен ачуланмый башлый. Шулай итеп, ул ачу бер секундта узды. Без синең белән берничә мәртәбә, дәрескә кермичә, караватларыбызга сузылып ятып калдык. Шулвакытта безнең янга училищеның врачын (яһүд иде) җибәрделәр. Син аңа, баш әйләнә, дидең, ә мин, борыннан кан китә, дип ялганладым. Ул безнең һәр икебезгә дә дарулар кереп алырга кушты. Мескен, нинди дару кирәген белсә иде ул безгә!!!

Синең шушы зур хезмәтеңне кулыма алганда менә шул картиналар күз алдымнан үттеләр. Һәм тормышның шул мәктәбен геройларча үткән егетнең хезмәте булганга, ул китапны кулыма ниндидер бер әйтеп бетергесез ихтирам белән, шатлык белән алдым. Мин татар телендә мондый зур әйбернең чыгуына, һәм аны син эшләгән булуга бихисап шат. Беренче китапның аягы төкле булсын!

Сәлам белән, Мөхәммәт. Күңел йомшак чакта язылды, сизгәнсеңдер.

1963 ел, 30 июль ■



АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Булмаса дуслык, җитә бит сугышырга бер юк эш.

● Борча атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.

● Кайчанга чаклы татар... берберсенә ук атар, иттифакъсыз?

● И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!

● Кеше сатмас кеше тапмак асатмы? Сине соң кайсы дуст дошманга сатмый?

● Дуст кем, дошман кем — милләт үзе аерыр.

● Бер кеше 20 миллионлы бер халыкның там[31] яртысын дошман күреп, калган яртысын дуст күрәм дип дәгъва кыйлса, аның бу дәгъвасе ап-ачык бер ялгандыр... Татарларның яртысы булган ирләр — мөэминнәр-мөселманнар, инсаннар булган шикелле, икенче яртысы булган хатыннар да шулай ук мөэминә-мөслимә вә инсаннардыр.

***

● Безнең татарларда, иң әүвәл мәртәбә әйткәндә, һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер.

● Тәрәккый дә итәмез, һәр нәрсәне көттерәмез дә.

● Тырышып, күп акчалар тотып һәм төрле-төрле чаралар күреп, ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә! Милләтнең чире — керешмәүдер эшкә.

● Руслар эш күрәләр, мөселманнар төш күрәләр.

● Бер кеше, комган берлә салкын су алып коенганда, суны тәненә тигезмичә, читкә түккәндин соң: «Әле дә ярый тимәде», — дип куана, имеш.

● «Яңа» дип һәр нәрсәгә мөкиббән кителмәскә вә... айнык караштан аерылмаска кирәк.

***

● Дөньяның, мәсәлән, кошларыннан вә хәшәрәтеннән генә дә акыллы кешегә гыйбрәт алырга мөмкин. Аларда да тигезлек юк. Мәсәлән: черки дә оча, чыпчык та оча... Шулар белән бергә, бөтен кошлар ханы булган каракошорел да оча. Ләкин һәрберсе үз канаты куәтенчә. Инсаннарның дөньяда торган чактагы таләпләре дә, күңелләрендәге теләкләре дә шул кошларның очышына охшыйдыр.

● Арысланның гайрәте, төлкенең хәйләлеге, куянның куркаклыгы, дуңгызның нәҗеслеге бар. Һичберсенә дә ачуланып булмый. Алла шулай яраткан. Боларның кайсы шәригатькә хилаф?

● Арыслан берлән юлбарыс яратылган бер каннан.

● Арыслан, вәхши хайван булса да, чыпчык авызыннан корт алып вакланмыйдыр.

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында.

***

● Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлауларына уянырга кирәк иде.

● Уяныңыз да тартышыңыз. Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыңызны!

● Безнең мәйданымыз милләт каһарманнарының мөбарәзәсе[32] өчен ачыктыр. Килсеннәр, ул шанлы вә намле[33] каләмнәрен уйнатсыннар!

● Без һөҗүм итүче булмыйча, тик каршы торып, аны кире кагучы булуыбыз белән чын бәхетлебез.

● Тотып милләт ливасын[34], юлга чыктык: «Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».

● Башны бөксәм — зур җинаятьтер олуг җан хакъкына.

● Сыңар җиңнән ике кул чыгарыйк без.

● Хөррият, ирек — барча кешеләргәдер; бай, фәкыйрь, галим, җаһил, ир вә хатын һәм милләт, аерылмаенча, һәркемгә бертигездер.

● Бер кешенең...: «Хөррият! Инсаният! Исламият!» — дип кычкыруы гына аның рухын аңларга җитмәгәнлеге... билгеле инде.

● Китә кайчакта кәефең, хакимең булса ишәк.

● «Җир аны эшләүчеләр өчен», — дию тәмам юк ителгән. Теләсәң, күктә яки йолдызлар арасында урын тап.

● Бюрократлар нәсыйхәте... «Әгәр халыкка тигез хокук бирелсә, инсанның кадере бетәчәк...» Бюрократларның бу сүзе әбиләрнең: «Май ашама, сукыр булырсың», — дигән сүзләренә бик охшый.

● Без Думага депутат сайларга никадәр хаклы булсак та, ул закон йортына клоун һәм дә талантсыз клоун сайларга хаксыз.

● Борчак — маклерның авыз капчыгыннан бертуктаусыз коела торган орлык.

● Мәдәният бер локомотив шикелледер. Ул полный ходка барганда, син юл өстенә чыгып туктатмакчы буласың. Локомотив ул синең кеби кабан дуңгызларын түгел, төяләрне дә изеп, яньчеп китәдер.

***

● Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл; бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (Гыйззе вә Җәл).

● И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

● Татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар... Үз араларында төрекчә сөйләшеп маймыллланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «Госманлыез, әфәндем», — дип йөрүче хиффәтләребез[35] дә аз булмады. Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте... Без, татарлар, һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр — Истанбулда, без — монда.

● Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара: нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара. «Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампаның һичбер нуры» — шул мәкаль монда дөрест шул, ах, аны җен оргыры!

● Авылны күпме мактасаң да, аның калада торып өйрәнгән кешене разый итмәслек урыннары табыла икән.

***

● Рус җирендә без әсәрле, эзле без, тарихында бер дә тапсыз көзге без.

● Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып... Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

● Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез. Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук!

● Без — руслар белән татарлар — һәр вакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз.

● Бу замандагы европалылар нәрсә тарихында изге ат калдырса, шуңар

түгел, нәрсә әле бүген дә тамак туйдырса, шуңар тотыналар, түгел аерым личностьлар, хәтта бөтен милләтләр шул эш илә генә мәшгульләр.

***

● Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем; саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым. Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле; дөнья бирсәләр дә сатмам милләт, миллиятемне.

● Күңел берлән сөям бәхетен татарның, күрергә җанлылык вакытын татарның. Татар бәхете өчен мин җан атармын: татар бит мин, үзем дә чын татармын.

● Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!

● Тиеш... үтәргә изге юлда бу гомер барсы түләү берлән бурычны Тәңремә һәм халкыма... Бәхетлемен шушы хәлдән, бүтән бер хәл дә көтмимен, шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын.

● Бу юлда, шөбһә юк, без җан бирербез; ниһаять, милләткә дан һәм шан бирербез.

● Соң булса да, бөтенләй булмаудан яхшырак.

● Көтеп алган кадерле була.

● «Нигә, — дим, — изге мәктәптән, сабый чаклардан аерылдым? Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым?»

● Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын; яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.

● Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы, шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

● Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым, көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым... Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш: керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

● Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса — шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем.

● И үлем! Мин синдә бер хәсрәт вә бер шатлык күрәм.

● Онытылу, тибәрелү — үлемнән яманрак.

***

● Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.

● Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы.

II

● Каләм — хөкем йөртүче Җир йөзендә, аның белән ант ителгән «Нүн» сүрәсендә.

● Каләм — бөек, каләм — дәрәҗәле; Ходайның телендә ант урынында ул. Каләм — данлы, каләм - шанлы, каләм ул — чиргә дәва, кайгыны юар сабындыр.

● Милләт... тик каләмнән генә хәят, тик каләмнән генә нәҗат көтә.

● Әйбәт язучы... Каләме — милләткә файда, язганы — Хак көзгесе.

● Каләм иясе булып чыгучыларымыз күбәйсен, солдатның өстенә дә шинель, астына да шинель, баш астына да шинель дигән шикелле, алай тартсак та, шул бер-ике мөхәррир, болай сузсак та, бер-ике язучыбыз гына булмасын.

● Мөхәррирләр гаскәрләр кебидер: сугышка чыкканда, запас гаскәрләребез булмаса, әсир булырмыз, хур булырмыз.

● Бездә мөхәррирләр тәмле хыялларга корбан булырга түгел, кирәк эшләремезгә дә аздыр. Әгәр... кыйбатлы мөхәррирләремез һәлак булып бетсәләр, дөньяда тик корчаңгы мөхәррирләр генә калачактыр.

Сүзлекчә

[31] Там — тәгәл;
[32] Мөбарәзә — бергә-бер чыгып көрәшү;
[33] Намле - абруйлы;
[34] Лива — байрак;
[35] Хиффәт — тиле, юләр.

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор **ЗӨФӘР РӘМИЕВ** алып бара.

БӨДӘЙЛИ Мәхмүт Кәшфелһади улы (1895-1975), язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Озак еллар (Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов кебек классик әдипләр яшәгән заманнарда ук) татар язучыларының яшерен имзаларын җыю белән шөгыльләнә. Тупланмасын китап рәвешендә бастырып чыгарырга өлгерми, бары тик бер өлеше генә «Казан утлары» журналы сәхифәләрендә дөнья күрә. Ул Т. кулланган псевдонимнарны җыюга да күп көч куйган. Аныңча, Т. үзенең әсәрләрен түбәндәге псевдонимнар белән бастырган: Г.Тукай; Шүрәле; Тиктормас; Һөд-һөд; Бичура; Феакут; Имам-Хатыйб; Имзасыз да Яраретдинов; Тәнкыйть сөюче; Биик усал; Т.Г.Т.; Мин язмадым; Гөмберррт; Кыйссасыл әнбия. Рабгузи; Кырмыска; Милләтче; Мәҗнүн; Сөемсез; Ишан мөнкире; Догачы Шүрәле; Хәятел-хәйванаттан күчерүче; Сәгыйть Аннук Самакай малае. Соңрак тикшеренүләрдә бу исемлек тулыландырылды, кайбер саналган имзаларның Т.ныкы булуы расланмады, кайберләренең шикле булуы ачыкланды. Хәер, татар язучыларының псевдонимнарын җыйганда фәнни принциплар кулланып эш итмәвен Б. үзе дә искәрткән. Б.М. сатирик һәм юмористик әсәрләрен 1920 нче елларда өч китап итеп бастырган. «Татарча лөгатьләр» исемле сатирик парчасы (1928) исә Т.ның сүзлекчә рәвешендә язылган текстларын хәтерләтә. Үзе төзеп чыгарган «Юмор һәм сатира» исемле җыентыкка (К., 1966) Т.ның дүрт әсәрен урнаштырган (Б.9-15).

З.Рәмиев

Әдәбият

Әсәр.: Бөдәйли М. Тормыш төпчекләре. К.: 1928. — Б.173-174; Һади М. Псевдонимнар хакында берничә сүз // КУ.: 1969. — №1. — Б.169-182.

Әдәб.: Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст, хронология мәсьәләләре. К.: 2000. — Б.16-17; 28-30.

ЧУЛПЫЛАР

ТР Милли музеенда сакланучы хатын-кыз бизәнү әйберләренең берсе — чулпы белән танышып китик. *«...Чулпыны чәчне йөртүдә тиешле тәртипне саклаган барлык татар хатын-кызлары да таккан. Кыз баланың чәче билгеле бер озынлыкка җитүгә үк, ул чулпы тага башлаган һәм аны үлгәнче йөрткән. Һәрбер чулпыда тәңкәләр саны уннан егермегә кадәр булган, хатын-кыз хәрәкәт иткәндә матур чылтырау тавышы чыккан...»*, — дип яза Н.И.Воробьёв.

Чулпыларның бик күп төрләре булган. Мәсәлән, икеле чулпы. Аны еш кына көянтәле чулпы дип йөрткәннәр. Чөнки ике аерым чулпы көянтә аша бер-берсенә тоташкан була. Ул төрле җиз тәңкәләр, асылташлар — сердолик, фирүзә, яшма һ.б. белән бизәлгән.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.*

ИПЛЕ ҺӘМ ИГЪТИБАРЛЫ ТҮРӘ ИДЕ

Гәрәй Рәхим

Мансур Хәсән улы Хәсәнов – XX гасыр уртасындагы татар мәдәнияте, әдәбияты, сынлы сәнгате, музыкасы, театры тарихында гаять күп хезмәт куйган дәүләт эшлеклесе, язучы, галим һәм халкыбызның күренекле шәхесләренең берсе.

Ул озак еллар КПССның Татарстан өлкә комитетында, Республикабыз хөкүмәтендә һәм фәнни оешмаларында бик тә җаваплы вазифалар башкарды. Татарстан Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары булып эшләгәндә ул Татарстанның фән, сәламәтлек саклау, социаль тормышы, мәгариф, мәдәният, идеология, әдәбият һәм сәнгать өлкәләренең нормаль үсеше, аларның санап бетергесез проблемалары өчен җаваплы кеше иде.

Аның белән аралашуларым Казанда, Татарстанда, Мәскәүдә РСФСР язучылар берлекләрендә штатта эшләгән вакытымда уртак мәсьәләләрне бергәләшеп хәл итүләребез нәтиҗәсендә булды. Мин Мансур Хәсән улының татар әдәбияты, аның олы тарихы һәм киләчәге турында аеруча кайгыртып, яратып, көч куеп яшәвен һәм эшләвен ассызыклап әйтер идем.

Мин Мансур ага белән бик озак еллар аралаштым. Әле Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда ук (1962-1967 еллар) «Казан утлары» журналында һәм республика газеталарында басылып чыккан шигырьләрем турында Мансур ага, Язучылар берлеге яки университет коридорларында очрашсак, аяк өсте генә: «Син, егет, кызык язасың, шулай дәвам ит», — дип күңелне күтәреп китә иде. Китапларым чыга башлагач та, ул, һәр китабымның исемен әйтеп, бер-ике мактау сүзе белән минем күңелне «очындыра» иде.

Инде мин Татарстан Язучылар берлегендә яшь язучылар белән эшләүче консультант, партия бюросы һәм Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы булгач, бигрәк тә 1981 елдан РСФСР Язучылар берлеге идарәсенең Татарстан, Башкортстан, Чувашстан Язучылар берлекләре буенча куратор һәм Россия Язучылар берлегенең төрки әдәбиятлар комиссиясе сәркатибе булып эшләгәндә, без, Мансур ага белән, татар әдәбиятына кагылышлы зур-зур мәсьәләләр буенча киңәшләшү өчен, КПССның Татарстан өлкә комитетында, Министрлар Советында, РСФСР һәм Татарстан Язучылар берлекләре биналарында ешрак очраша башладык.

Ул елларда Мәскәүдә, Союзлар йортының колонналы залында Кол Гали, Габдулла Тукай, Акмулла, Муса Җәлил юбилейларын, Мәскәүнең атаклы Лужники үзәк стадионында татар шигърияте кичәсен, Язучыларның Үзәк йортында (ЦДЛ) Сибгат Хәкимнең, Галимҗан Ибраһимовның юбилейларын һәм яшь татар шагыйрьләренең шигырь кичәсен үткәрдек. Бу чараларның һәрберсе Мансур Хәсән улы белән киңәшеп, аның тәкъдимнәрен искә алып үткәрелде.

Мин Мәскәүдә эшләгәндә Татар әдәбиятын, СССР күләмендә булса,

Мансур Хәсәнов 1963 нче әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта катнашучы Татарстан язучылары арасында.

Беренче рәттә сулдан уңга – Роберт Бикмөхәммәтов, Ләбибә Ихсанова, Афзал Шамов, Мансур Хәсәнов, Гомәр Бәширов, Хәй Хисмәтуллин, Нәкый Исәнбәт, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Гариф Гобәй. Икенче рәттә – Баян Гыйззәт, Габдрахман Әпсәләмов, Мария Елизарова, Әнәс Камал, Зәки Нури, Әминә Бикчәнтәева, Нәби Дәүли, Әдип Маликов, Әхмәт Юныс, Нури Арслан, Газиз Иделле, Фатих Хөсни, Габдрахман Минский, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази. Өченче рәттә – Зәет Мәҗитов, Хәй Вахит, Рафаэль Төхвәтуллин, Идрис Туктар, Гариф Гали, Гали Хуҗи, Госман Бакир, Самат Шакир, Шәүкәт Галиев, Газиз Мөхәммәтшин, Нур Гыйззәтуллин, Рафаэль Мостафин. Дүртенче рәттә – Илдар Юзиев, Нил Юзеев, Барлас Камал, Сергей Ефремов. Татарстан язучыларының Г.Тукай исемендәге клубы (Казан, Бауман ур. 19 нчы йорт). 1964 елның 27 марты

да чын-чынлап таныту юлларын эзли башладым. Уен эш түгел бит, 1983 елда Кол Галинең тууына 800, 1986 елда Тукайның тууына 100 ел тула. Бу юбилейларны СССРда гөрләтеп үткәрергә кирәклеге көн кебек ачык иде.

Ул елларда РСФСР Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе булып күптән түгел генә Парижда, БМОның ЮНЕСКО дигән халыкара мәдәни оешмасы штатында эшләп, хәзер СССРга кайткан Анатолий Иванович Волков эшли иде. Гаять киң күңелле, Европа мәдәниятендә тәрбияләнгән Анатолий Иванович сәркатип булып эшли башлаганының беренче көннәрендә үк мине үз итте, яратты.

РСФСР Язучылар берлегенең бөтен оештыру эшләре аның кулында иде. Шуннан мин моңа Кол Галинең тууына 800 еллык юбилейны ничек үткәрү турында киңәшергә кердем. Әлбәттә инде минем кулда Кол Галинең азмы-күпме биографик мәгълүматлары һәм аның «Кыйссаи Йосыф» әсәренең бөтен СССР, Азия, Европа музейларында һәм китапханәләрендә булган,

Анатолий Волков, Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм берлек рәисе Гариф Ахунов, 1983 ел

халык арасына киң таралган нөсхәләре турында документларым әзер иде. Анатолий Иванович бу мәгълүматларны карады да гаҗәпкә калды. Шуннан ул: «Тууына 800 ел, бу бит РСФСР территориясендә булмаган хәл, әйдә, минем Парижда ЮНЕСКОда эшләүче дусларым бар, бу юбилейны ЮНЕСКО календарена кертеп, бөтен дөньяда үткәрәбез», — дип җибәрмәсенме! Мин инде бу сүзләрдән коелып төштем. Шул ук көнне ул мине Сергей Михалковка алып кереп китте дә, Парижга Михалков имзасы белән хат язарга килеште. Мин хат проектын шул көнне үк язып, Михалковтан кул куйдырдым һәм Казанга Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Мансур Хәсәновка шалтыраттым. Мансур ага баштан икеләнебрәк калгандай булды, бу керәшен малае арттырыбрак җибәрми микән, дип уйлагандыр инде. Ниһаять, мәсьәләне берәмтекләп аңлатып биргәч, ул: «Парижга документларны бик тәфсилләп эшләп бирергә кирәк, мин Ахуновка (ул чактагы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов) шалтыратырмын, материалларны сиңа китерсеннәр», — диде.

Безнең бу эш бик уңышлы барып чыкты, Кол Галинең тууына 800 ел ЮНЕСКО календарена кертелеп, ул 14 илдә зурлап билгеләп үтелде. Ә Мәскәүдә юбилей Союзлар Йортының колонналы залында зурлап билгеләп үтелде. Юбилей комиссиясе рәисе — СССР Язучылар берлеге председателе Георгий Марков — кичәне ачып җибәрде, Татарстан делегациясе рәисе Мансур Хәсәнов Кол Гали һәм аның иҗаты турында тирән эчтәлекле доклад ясады.

1986 елны исә Габдулла Тукайның 100 еллыгын ЮНЕСКО календарена кертеп үткәрү бераз җиңелрәк булды, чөнки тәҗрибә бар иде.

Хәзер инде, Аллага шөкер, башкалабыз Казан Кремле һәм Бөек Болгар тыюлыгы ЮНЕСКОның бөтендөнья мәдәни истәлекләре исемлегенә кертелде. Шулай итеп без — Мансур Хәсән

Мансур Хәсәнов (уңнан икенче) Татарстан Дәүләт Советы депутатлары белән. Уңнан дүртенче – Дәүләт Советы рәисе Василий Лихачёв, уңнан бишенче – Дәүләт Советы аппараты хезмәткәре Гәрәй Рәхим. 90 нчы еллар

улы, Гариф Ахунов, Анатолий Волков һәм мин ЮНЕСКОга салган беренче сукмаклар игелекле вә нәтиҗәле булып чыкты. Россия Федерациясенең бер генә милли республикасы да әле 4 объект белән ЮНЕСКО исемлегенә кергәне юк. Шунысын да әйтеп китәсем килә — Кол Гали һәм Тукайның юбилейларын ЮНЕСКО календарена керткәндә без дәүләттән бер тиен акча да алмадык, барысын да бушлай, үз инициативабыз белән генә эшләдек. Казан Кремлен һәм Бөек Болгарны ЮНЕСКО исемлегенә кертү өчен исә республикабызның берничә дистә белгече катнашты һәм шактый чыгымнар тотылды.

Кол Галинең һәм Тукайның юбилейларын Мәскәүдә үткәрүнең оештыру яклары нигездә минем җилкәгә төште. Бөтен кәгазьләрне, хат һәм документларны педантларча төгәл җыеп, аерым папкаларга салып бардым. Бу папкалардагы мәгълүматлар татар әдәбияты тарихына кызыклы булыр дип, мин Мансур ага белән киңәшергә булдым һәм әлеге папкаларны йә Республика музеена, йә Дәүләт архивына тапшырырга теләвемне әйттем. Мансур ага акыллы һәм тәҗрибәле кеше буларак, миңа папкаларны үземдә саклап торырга киңәш итте. «Ул кыйммәтле материалларны кулыңнан ычкындырма, кая бирсәң дә югалып бетү мөмкинлеге бар. Әле үзең иҗат итеп торасың, ул документлар үзеңә кирәк булуы мөмкин», — диде ул. Алтын сүзләр әйткән Мансур ага! Еллар үткәч, мин Кол Гали һәм Тукай юбилейлары турында мәкаләләр язып бастырдым. Аларны үземнең сайланма әсәрләремә дә керттем. Әлеге мәкаләмдә дә мин шул папкалардан файдаландым.

Әгәр бүген миннән: «Мансур Хәсәнов нindиерәк кеше иде?» — дип сорасалар, минем җавабым бер булыр: «Ипле һәм игътибарлы түрә иде!» ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ӘХМӘДУЛЛИН ГАБДЕЛВӘЛИ МӨХӘММӘДСАДЫЙК УЛЫ (1871-?) – XX гасыр башында Казанда «Сабах» нәшриятының җитәкчесе. Казан университеты басмаханәсендә 55 ел чамасы машинист булып эшләп, көмеш һәм алтын медальләр белән бүләкләнгән Мөхәммәдсадыйк Әхмәдуллин гаиләсендә туган. «Касыймия» мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Габделвәли университет басмаханәсендә хәреф җыючы булып эшли башлый. 1901 елда дивари өзмә календарь төзеп бастыра. 1902 елда ул, энесе Гали белән бергәләп, китап сәүдәсе белән шөгыльләнә башлый. 1906 елда алар «Сабах» нәшрияты һәм 1911 елда «Өмид» басмаханәсе ачып җибәрәләр. Нәшрият үзенең яшәү дәверендә 461 татар китабы һәм брошюралар бастырып тарата. Ул 1921 елда национализацияләнгән.

ӘХМӘРОВ ШАҺБАЗГӘРӘЙ ИЗМАИЛ УЛЫ (25.III.1853-9.IV.1900) – Казан губернасы Чистай өязеннән. 1878 елда Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый, Казанда рус-татар укытучылар мәктәбендә рус теле һәм педагогика укыта. Аның «Госмания» мәдрәсәсендә һәм Казанның бишенче мәчете мәдрәсәсендә 1872 елдан рус теле укытканлыгы билгеле. 1884 елда Казан уку округында халык укуханәләре инспекторы итеп билгеләнә. Татар телендә фигыльләр ясалышы һәм фигыльләрнең төрләре турында хезмәт яза.

Ш.Әхмәров 1890 елда татар телендә «Казан» исемле гәзит чыгарырга рөхсәт сорап, өч тапкыр Петербургка мөрәҗәгать итеп карый, ләкин аңа мондый рөхсәт бирелми, чөнки хөкүмәт татарча гәзит чыгарудан курка һәм Әхмәровка тикле дә дүрт-биш тапкыр мондый омтылышларны кире каккан була.

1897 елда инде ул Казан татар укытучылар мәктәбендә инспектор булып тора. Шушы елны Россиядә халык санын алу кампаниясе алдыннан җирле укыту округы назиренә (попечителенә) ул түбәндәгеләрне яза: *«Казан шәһәрендә яшәүче татарлар арасында халык санын алу алдыннан төрле имеш-мимешләр йөрүе һәм динне кысмагайлары, дип тәшвишләнү сизелә. Татарлар гомумән үзләренең дини шик-шөбһәләрен үз араларында рус мәгарифе мәктәпләре булу белән бәйлиләр, шуңа күрә төрле чуалышлар килеп чыга калса, татарлар, кызып китеп, укытучылар мәктәбенә дә зыян салырга мөмкиннәр дип көтәргә була, чөнки, алар фикеренчә, бу мәктәп*

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

Әхмәровлар гаиләсе. Казан. 1912-1913 еллар

башка рус-татар мәктәпләренең башында тора». Үзенең бу гаризасында Әхмәров әфәнде губерна администрациясенең тиешле саклык чаралары күрүен үтенә.

Әхмәровның өлкән кызы Мәһипәрваз Казанда кызлар гимназиясен һәм аның каршындагы сигезенче педагогия классын тәмамлый, икенче кызы Сара 1912 елда Петербургта Бестужев югары хатын-кызлар курсларын тәмамлап, шунда приват-доцент сыйфатында калдырыла һәм гыйльми дәрәҗә алган беренче татар кызы булып исәпләнә. Әхмәровның улы Йосыф Казанда икенче ирләр гимназиясен тәмамлаган.

Җамал Вәлиди аны *Шаһбазгәрәй мирза Әхмирев*, дип телгә ала.

ӘХМӘРОВ ШИҺАБЕТДИН ШӘРӘФЕТДИН улы (1882-1966) — педагог, журналист һәм нашир. Чыгышы белән Татарстанның Чүпрәле районындагы Новозадоровка авылыннан. Мәдрәсә тәмамлагач, авылда укытучы булып эшли, 1907 елдан Казанда. «Болгар» кунакханәсендә яшәгәндә күрше номерда ук торучы Габдулла Тукай белән дуслаша. Ул Габдулла Тукайга хәленнән килгәнчә ярдәм итеп килгән. Заманында аның ярдәме Салих Сәйдәшевкә дә тигән.

1908-1918 елларда Шиһабетдин Әхмәров — «Сабах» нәшриятында баш редактор, «Өмид» типографиясенең техник җитәкчесе, 1913-1914 елларда бер үк вакытта «Мәктәп» журналының да редакторы була. 1913 елда бу журналның 15 номеры, 1914 елда 10 номеры дөнья күрә. Журнал сәхифәләрендә шул заманның күренекле педагоглары, мәгърифәтчеләре, әдипләре, җәмәгать эшлекләре: Гаяз Исхакый, Мөхетдин Корбангалиев, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев, Фәхрелислам Агиев, Камил Мо-

Р.Фәхреддиннең «Әхмәт бай» китабы

тыйгый, Галимҗан Шәрәф, Мәхмүт Фоат, Һади Атласов, Садрый Җәләл, Сәгыйть Сүнчәләй, Фатих Сәйфи, Ибраһим Бикколов һ.б. катнашалар. 1918 елда бу журнал, исемен «Мәгариф»кә алмаштырып, кабат чыга башлый һәм 1936 елга кадәр шул исем белән нәшер ителә. 1936-1937 елларда ул «Башлангыч мәктәп» дип атала, аннары аның исеме «Совет мәктәбе» дип үзгәртелә (1938-1941, 1949-1990 еллар). Ниһаять, 1990 елда журнал, совет чоры исеменнән баш тартып, кабат «Мәгариф» журналына әйләнә.

Шиһабетдин Әхмәров «Шәрык клубы»н оештыруда да катнашкан. Татарча «Әлифба»лар төзегән, татарда китап басу эше турында хезмәтләре бар. Нигезсез репрессияләнгән, 1959 елда реабилитацияләнә.

ӘХМӘТ БАЙ — Әхмәт Гали улы Хөсәенов (1837-1906). Исеме Әхмәд бай рәвешендә дә очрый. Оренбургтагы сәүдәгәр, миллионер, меценат. Оренбург тирәсендәге Сәет бистәсендә (Татар Каргалысында) туган. Аның ата-бабалары бирегә XVIII гасыр урталарында Казан губернасының Кибәхуҗа авылыннан күченеп килгән һәм сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Әтисе Гали Хөсәенов ахырда тәмам бөлгән һәм ишле гаиләсен хәерчелектә калдырып үлеп киткән. Шуңа күрә Әхмәт инде унике яшендә үк бөтен гаиләне ризыкландыручы булып исәпләнгән. Ул биш сум акча туплап, вак-төяк һәм чимал белән сәүдә «эшен» башлап җибәргән. Соңрак аңа энеләре Мәхмүд (1839-1910) һәм Гани (1839-1902) ярдәм итә башлаганнар. Әхмәт Хөсәенов кадими мәдрәсәдә бераз укып алган булса да, уку-язуны үзләштерә алмаган һәм соңыннан халыкның фәкыйрьлегенә, наданлыгына белемсезлек гаепле дип санаган. Шуңа күрә Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе ачу өчен ул күп тырышлыклар куя. 1896 елда ул, бергә тапкан мал-мөлкәтләрен туганнары белән бүлешеп, Казанга күчеп килә һәм Кабан күле буенда, хәзерге Мәрҗани урамы, 42 нче йортта яши башлый. Р.Фәхреддин язганча, Казанда үткәргән ун ел эчендә

Әхмәт бай үзенең һәр кеременнән 3000 сумнан артык акчасын халык файдасына бүлеп, 20дән артык мәчет һәм мәдрәсә бинасы төзетә, 40тан артык мәктәп мөгаллименең хезмәтенә түләп бара, 200дән артык мәктәпне дәреслекләр белән тәэмин итә. Гомумән, ул шәһәрдәге яңа җәдид ысулы кертелгән мәдрәсәләргә, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә ярдәм итеп килә. «Хөсәения» мәдрәсәсенең киләчәген тәэмин итү өчен вакыф калдырган. Ләкин үзе үлгәч, ул вакыф белән идарә итүчеләр аны үзләштерә һәм әрәм-шәрәм итә башлый. Мәрхүмнең васыятьнамәсендә тагын түбәндәге иганәләр билгеләнгән: 1) Казандагы сәнәгать мәктәбендә укучы алты шәкерткә һәм Оренбургтагы алты шәкерткә елына 108 сум биреп торырга; 2) Казандагы Татарская учительская школада ике шәкерт укытырга, һәрберсенә елына 150 сум бирергә; 3)Коммерция училищесында дүрт шәкерт укытырга, һәрберсенә елга 200 сум бирергә; 4) Гимназиядә ике шәкерт, реальныйда ике шәкерт укытырга, һәрберсенә елга 300 сум бирергә.

Әхмәт байның тәрбиягә алган улы Габдерахман Дәүләтшин «Китап» нәшрияты оештырып, китап бастыру һәм сәүдә итү белән шөгыльләнгән.

Әхмәт бай Казанда татар зиратында җирләнгән.

ӘХМӘТОВ ИСХАК — Емельян Пугачёвның үзе билгеләгән полковнигы. Казан янындагы Татар Кавалы авылында туган. Беркадәр мәдрәсәдә йөреп, язу язарга, кул куярга өйрәнгән, ләкин тормыш итү авыр булганлыктан, мәдрәсәне тәмамлый алмаган. Читкә китеп, Урал заводларында эшләп йөргән, шунда русча сукаларга өйрәнгән. Әмма үзенең авылдагы хуҗалыгын аякка бастырырлык акча туплый алмагач, Оренбург якларына китеп урнашырга ниятләгән. 1763 елда ул шундагы Мостафа авылына барып, үзенә өй урыны һәм җир кисеп бирүләрен сорый һәм әкренләп шунда тормыш корып җибәрә. 1773 елда көз көне Оренбургка ашлык сатарга баргач, хакимиятләр шәһәрне бикләп куялар, чөнки бу вакытта Пугачёв гаскәре якынлашкан була. Исхак Әхмәтов өенә кайтып китү өчен шәһәрдән чыгаруларын сорагач, губернатор Рейнсдорпның боерыгы буенча, аңа башка эш йөклиләр: кулына пакет тотыралар да, Пугачёвка каршы килүче патша гаскәре командующие генерал Карга тапшырырга кушалар. Исхак Әхмәтов моңа ризалык биргән, әмма шәһәрдән качып чыккан икенче бер кеше белән бергәләп пугачёвчы казакларга барып кушылган. Казаклар аны Оренбург янындагы Бердә бистәсенә — Пугачёв станына китергәннәр. Шул рәвешле ул «патша хәзрәтләренә» хезмәттә кала һәм сотник итеп билгеләнә. Сугышларда үзен батыр командир итеп таныта. (Алар Оренбург, Каргалы тирәләрендә сугышканнар.) Утлы-Карагай крепостен алганы өчен Пугачёв Әхмәтовка полковник дәрәҗәсе бирә. Казанны камауда (1774 елның июле) Исхак Әхмәтовның да катнашканлыгы билгеле. Пугачёв восстаниесе бастырылгач, Исхак Әхмәтовны, иптәшләре Сәлим Гаделшин һәм Борис Савельев белән бергә кулга алып, чылбырлар белән богауланган хәлдә, Казанга яшерен комиссиягә озатканнар. Тикшерү вакытында аларны бик каты кыйнаганнар, ахырда борын-колакларын кисеп, гомерлек каторгага җибәргәннәр, шуннан соңгы язмышлары билгесез. Ихтимал, аларның соңгы эзләрен Пугачёвның көрәштәше башкорт батыры Салават Юлаев һәм аның әтисе сөрелгән Балтыйк буеннан эзләргә кирәктер. Ә Салават 1800 елда үлгән. Чыннан да ул заманнарда татар-башкорт, кыргызкайсак (казах) кебек төрки халыкларны Себергә сөрү балыкны суга җибәрү белән бер булыр иде. ■

«АФӘРИН, АЙРАТ!»

Атлас Гафиятов

Бүген спорт төрләре дә, көч сынашулар да бихисап. Әмма аларның Олимпия Уеннары программасына кергәннәре, дөнья чемпионатлары уздырылганнары популяр санала. Бокс – әнә шундый популяр төрләрнең берсе.

Бокс – (инглизчәдән box – сугу) спортчыларның, кулларына йомшак перчаткалар киеп, аерым кагыйдәләр буенча, рингта көч сынашуына нигезләнгән спорт төре. Әлеге спорт төре XVI-XVII гасырларда Англиядә барлыкка килә. 1904 елда бокс Олимпия уеннары программасына кертелә. 1946 елда Халыкара һәвәскәр бокс ассоциацияләре оеша. 1924 елдан Европа чемпионатлары, 1974 елдан башлап дөнья

чемпионатлары уздырыла. XIX гасыр ахырыннан башлап, профессиональ бокс та үсеш ала.

Татарстан боксчыларыннан иң титуллы спортчы — Айрат Хаматов. Ул — СССР һәм дөнья чемпионы, Европа беренчелегенең көмеш медаль иясе, халыкара турнирларда күп җиңүләр яулаган шәхес. Менә дистә елдан артык аның хөрмәтенә Казанда бик тә мәртәбәле турнир уздырыла. Әлеге турнир җиңүчеләренә спорт остасы исеме бирелү дә аның дәрәҗәсе хакында сөйли. Ә 2014 елның 26-31 октябрьдә үткән уникенче турнирга Айрат 1989 елда дөнья чемпионатында СССР җыелма командасы составында бергә чыгыш ясаган дусларын да җыйды. Әлбәттә, тарих өчен 25 ел, ягъни чирек гасыр әллә ни зур вакыт арасы түгел. Әмма кеше тормышында гаҗәеп әһәмиятле вакыт ул. Спорт белән азмыкүпме таныш кешеләр белә: дөнья чемпионатларында аңа кадәр дә, аннан соң да Россия (СССР) боксчыларының 1989 елдагы кебек уңышка ирешә алганнары юк. Уйлап карагыз: безнекеләр ул чакта 5 алтын, ике көмеш, дүрт бронза медаль яуладылар. Айрат Хаматов 57 килолы үлчәүдә җиңү яуласа, Юрий Арбачаков 51 килолы, Игорь Ружников 63,5, Исраэль Акопкохян 71, Андрей Курнявка 75 килолы үлчәүдә чемпион булдылар. Нәкъ менә 25 елдан соң Айрат дусларын Казанга җыйды. Рингта берберсенең авыз-борыннарын җимереп, канга батышып тукмашучы көндәшләрнең тормышта чын дуслар булып калуы сокландыра. Бу очракта да Айратка «Афәрин!», диясе генә кала. Ә без 1989 елда Мәскәүдә үткән дөнья чемпионатының 57 килограммдагы үлчәүдәге финал очрашуын искә төшердек.

…«Рингка СССРның спорт остасы Айрат Хаматов чакырыла! — диде диктор. Ул 155 очрашу уздырган, шуларның 126сында җиңгән. Аның көндәше — Болгария Халык Республикасы спортчысы Киркор Киркоров. Ике тапкыр Европа чемпионы. Үзе үткәргән 103 алышның 7сендә генә оттырган…»

Мәскәүдәге «Олимпийский» спорт комплексында дөнья чемпионатын күзәткән тамашачыларның күбесе ул минутларда Киркор җиңәр, дип уйлагандыр. Ул, соңгы ике елда континент беренчелеген отып, СССР чемпионы Артемьевны да медальсез калдырган боксчы бит. Хаматовның исә ил чемпионатында да җиңгәне юк.

Айрат болай тыныч күренә үзе. Менә ул, очрашуның башланганлыгын белдереп чаң сугылуга, Киркорның колак төбенә «кундыра». Тегесе дә җавапсыз калмый: аның бокс перчаткалары Айратның күз алдында уйнап кына тора. Шулай да болгар боксчысының бер генә һөҗүме дә нәтиҗә бирми. Милләттәшебез оста саклана, җае чыкканда, һөҗүм дә итә. Беренче раунд әнә шулай — ике якның да күзәтүе, ягъни «разведка ясавы» белән үтә.

Икенче раунд башлануга, Болгария боксчысы хәйләгә керешә, үзе һөҗүм итми башлый. Айратның атакага ташлануын һәм, көрәш белән мавыгып китеп, башын, җилкәләрен, күкрәк турысын ачуын көтә. «Аннан соң мин сине сугып егам», янәсе. Тик рингта Хаматовның көрәш тактикасы өстенлек итә. Ул төгәл

ударлар ясый, шул ук вакытта, көндәше белән араны тиз генә кыскартып, аның сугуларыннан сакланып калу җаен да таба…

Өченче — соңгы раунд та тулысынча Казан боксчысының өстенлеге белән башлана. Ул көндәшенең маңгаена көчле итеп суккач, болгар спортчысы чайкалып куя, шулай да егылмый. Бу — боксчылар телендә «нокдаун» дигән сүз. Рингтагы судья Айрат файдасына исәпне ачып җибәрә. Тагын бер удар — тагын нокдаун. Киркор инде һөҗүм итү турында уйламый да, бары, перчаткалары белән битен каплап, бер урында таптанып кына тора. Өченче нокдауннан соң судья очрашуны бөтенләй туктата — татар егетенең өстенлеге бәхәссез!

Дөнья чемпионатының финалында мондый хәлләр сирәк була. Әле ун минут элек кенә Болгария спортчысының җиңүенә ышанган тамашачыларның күбесе, судья Айратның кулын югары күтәрүгә, милләттәшебезне аягүрә басып алкышлый. Кояшлы Үзбәкстаннан килгән спорт сөючеләр исә, тамашачылар мәхәббәтен яулаганы өчен, татар егетенә махсус приз — түбәтәй белән чапан кидертеп куя.

СССРның атказанган спорт остасы, Олимпия уеннары чемпионы Борис Лагутин, дөнья чемпионатында җиңгәне өчен, Айрат Хаматовка алтын медаль, алтын билбау, приз һәм грамота тапшыра. Чемпион хөрмәтенә Советлар Союзы гимны яңгыраганда, Айратның күзләрендә яшь тамчылары җемелди. Бәлки, ул бу минутларда үзенең әтисез-әнисез үткән үсмер вакытын, бу җиңүенә унбер ел буе әзерләнүен, җыелма команда составына кергәндә булган бәхәсләрне исенә төшергәндер?!

…Башка бик күп үсмерләр кебек, Айрат та, буш вакыт тиюгә, туп тибә. Ул чакта Казанның Нефтьчеләр бистәсендә футбол уйнамаган малай да булмагандыр. Бер елны исә Айрат чыгыш ясаган команда «Күн туп» клубы призына үткәрелә торган уеннарда республикада икенче урынны ала. Айраттан футболчы чыгар идеме-юкмы — билгесез, әмма гаиләләре Дәрвишләр бистәсенә күчкәч, малай бокс белән «җенләнеп» китә. 84 нче мәктәпнең физкультура укытучысы Александр Талманов кечкенә буйлы ябык малайга физик яктан ныгырга булышса, тренер Минхан Вәлиуллин Айратка бокс буенча беренче дәресләрен бирә. Унөч яшендә әтисен югалта малай. Дүрт елдан исә әнисе фаҗигале төстә һәлак була. Бертуган абыйсы Азат Айратны туган якларына — Тукай районының Югары Байлар авылына чакыра, әмма егет үзе яраткан спорт төрен, күңеленә якын булып өлгергән тренерларын ташлап китә алмый. Беренче остазы Минхан Вәлиуллин да, икенче тренеры Виктор Краснов та бокс серләренә генә өйрәтеп калмый, аңа зур тормышта беренче адымнарын ясарга да булыша. Югыйсә, урам төркемнәренә ияреп китәргә дә була иде бит Айратка. Кайчакта кесәсендә ипи алырга биш тиен акчасы да булмый аның, әмма секциягә йөрүен ташламый. Сигезенче классны тәмамлаганнан соң, егет 59 нчы профессиональ-техник училищега укырга керә, аннан соң оптика-механика заводында эшли башлый. Кичләрен исә күнегүләр, күнегүләр…

Чемпионның беренче тренеры Минхан Зиннәтович болай дип сөйли: «Беренче тапкыр секциягә килгәндә, Айрат яшьтәшләреннән берни белән дә аерылып тормый иде. «Бу ябык малайдан боксчы чыгар микән?» дип тә шикләндем башта. Чыннан да, шәһәр беренчелегендә катнашучыларны билгеләү өчен уздырылган сайлап алу ярышларындагы өч очрашуның өчесендә дә вакытыннан алда җиңелде ул. Тик шунысы сөендерде: икенче көнне үк секциягә башкалардан алда килеп җитә һәм үз авырлыгында иң көчле малай белән көч алыша иде Айрат. Кайбер егетләр, бер-ике тапкыр җиңелсәләр дә, «миннән булмый икән» дип кул селтәп, секцияне ташлап китәләр бит. Айрат кебекләрдән исә чын спортчы, чын ир-егетләр чыга. Минемчә, ул шулчакта беренче иң зур җиңүен яулады да: иң зур көндәшен — куркуын җиңде».

…1989 елда бокс буенча дөнья чемпионаты тәмамлангач, Куба җыелма командасының баш тренеры болай ди: «Иң техникалы боксчыга» дигән призны ярышларда гадәттә бер генә спортчыга бирәләр. Мәскәүдә аңа лаеклы ике кеше бар иде: немец Маске һәм сезнең Хаматов. Призны Германия спортчысына бирделәр, әмма Хаматов та аңа лаек иде». Мактауга саран булган тәҗрибәле тренерның бу сүзләре якташыбыз осталыгына иң зур бәя булып яңгырый. Тагын шунысын да белеп торыйк: Айрат финалда тукмашкан Киркор Киркоров 1991 елда дөнья чемпионы исемен алды. Бу аның чыннан да көчле спортчы булуы хакында сөйли.

Дөнья чемпионы булганнан соң да байтак җиңүләр яулады Айрат. 1991 елда Казанда үткән ил беренчелегендә алтын медаль отты, халыкара турнирларда җиңү яулады.

Тагын бер талантлы якташыбыз — Фоат Гатин белән бергә Айрат 1992 елда Барселонада үткән Олимпия уеннарында да катнашырга тиеш иде. Чөнки алар, сайлап алу турнирларында уңышлы чыгыш ясап, Олимпиадада катнашу өчен шәхси юлламалар яулап алдылар. Әмма илнең спорт җитәкчеләре башкача уйлаганнар. СССР таркалган вакыт бу, җыелма командага үзләрен бәйсез дип игълан иткән республикалардан күбрәк спортчыларны алырга тырышканнар. Айрат урынына ул чакта Үзбәкстаннан Григорянны алдылар, ә Фоатны Санкт-Петербург вәкиле Чеботарёв «алыштырды». Аларның икесе дә беренче очрашуларда ук җиңелде. Ә безнең егетләрнең Олимпиадада катнашу өчен бердәнбер мөмкинлекләре иде бу. Әмма 2000 елдан башлап Татарстанның бокс федерациясен җитәкләүче Айрат Хаматов республикабызда киләчәктә үзе кебек, Фоат кебек оста боксчылар үсеп чыгасына ышана, моның өчен кулыннан килгәннең бөтенесен дә эшләргә тырыша. Бүген республикабызда 4 меңнән артык малай һәм үсмер бокс белән шөгыльләнә. Күмәк уен төрләре (хоккей, футбол, волейбол, баскетбол…) өстенлек иткән төбәктә бокс кебек шәхси төрләргә дә зур игътибар бирә башладылар. Ә Айрат һәм Фоат кебек «йолдызлар» бүгенге малайлар, үсмерләр арасыннан барыбер үсеп чыгачак әле! ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның декабрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Шәһәр катогы

Шәһәрнең Черек күлдәге катогы 28нче ноябрьдә булган торгида елына 700 сум бәрабәренә Русаев дигән кешегә бирелгән һәм 3 ел мөддәткә [срокка] иҗарәгә [арендага] алу шарт ителгән. Бу торгины тасдыйк итү [раслау] шәһәр Думасы мәҗлесенә гарыз ителәчәк [тапшырылачак].

Кояш. — 1914. — №568. — 1 декабрь.

Мәҗрухлар файдасына бал атнасы

Казандагы умартачылык җәмгыяте вилаять вәлисе җәнапларының мөсагадәсе [ярдәме] белән 3нче декабрьдән башлап 9ына кадәр бал атнасы ясаячак. Моның саф файдасының яртысы мәҗрух гаскәриләр тәрбиясе өчен ачылган кооперативный лазарет файдасына тапшырылачактыр.

Кояш. — 1914. — №569. — 2 декабрь.

Мөселман шифаханәсенә[1]

15 ноябрьдән декабрь башына кадәр Садыйк хәзрәт Иманколовтан[2] 33 нөсхә, Әхмәтсолтан Таһировтан 15 нөсхә китап китерелгән. Моннан башка Зөләйхә ханым Апанаевадан[3] пәрәмәчләр, Фатхуллин һәм дә Сөләйманов җәмәгатьләреннән алмалар, Габдрахман Мөәминовтан тәмәкеләр һәм шатранҗ [шахмат] уены, шәһәр комитетыннан 15 күлмәк, 15 ыштан, 15 пар оекбашлар һәм тәмәкеләр, нәмәгълүм бер рустан 3 пинҗәк, бер брюки, 2 пар оекбаш, бер сөлге, бер күлмәк, чирек такта чәй, бер мөселманнан бер лампа һәм 12 аршин ситсы, янә берәүдән бер кадак кадәр чәй-шикәр китерелгән. Гомумән алганда, шифаханәне башлап җибәргәндә кызу гына башланган бу эштә ни өчендер акрынайганлык күренәдер.

Гаскәри балаларына ашханә

Шәһәрнең 29 вә 30 нчы апрелендә янганнарга иганә җыю комитеты тарафыннан җыелган акчадан билгеләнгән биш йөз сум акча белән Пеләтәндә Балубин йортында гаскәргә алынганнарның мохтаҗ гаиләләре балаларына җылы аш ашату өчен ашханә ачылды. Бу ашханәне төзетү вә юлга куюга шул ук биш йөз сумнан мәсариф [расход] тотылган. Хәзерге көндә бу ашханәгә 50гә кадәр бала җылы аш ашарга килә вә боларның 35 кадәресе мөселман балаларыдыр. Янганнарга иганә комитетыннан билгеләнгән бу акча, табигый, бу ашханәнең озак дәвамына хезмәт итә алмаячагыннан,

[1] Мөселман шифаханәсе — сугышта яраланган мөселманнарны дәвалау өчен 1914 елда Казанда ачылган шифаханә.

[2] Садыйк хәзрәт Иманколов (1870-1932) — шагыйрь, Фатих Әмирханның әтисе Мөхәммәтзариф Әмирханов мәчетендә (9 нчы мәхәллә яки «Иске таш» мәчет) икенче мулла.

[3] Зөләйха Апанаева — беренче гильдия сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Апанаевның хатыны.

хосусый иганәләр кабул ителүгә ихтыяҗ күреләчәк. Боларга булган иганәләр, ашханәнең үзендә һәм дә ашханә мөдирәсе М.В.Беркутовада кабул ителәләр.

Кояш. — 1914. — №570. — 3 декабрь.

Барабызлар[4] хакында

Вилаять вәлисе җәнаплары шәһәр главасына кәгазь җибәреп, барабызларга шәһәрнең һәммә җирендә йөрергә мөмкинлеген сораган үтенечен кабул иткәнен, Воскресенская һәм Грузинская урамнарында буйдан буйга йөрүне тыеп, шәһәрнең һәммә урамнарында йөрергә мөсагадә [мөмкин] икәнен белдергән. Моның өстенә бу мөсагадә киләсе елга кадәр генә булып, моннан соң, утырып йөрүчеләрнең егылып төшү имгәнүләре хәвефе булган чаналарда кеше утыртып йөртергә рөхсәт ителмәячәген тәнбиһ иткән [кисәткән] вә барабызлар хакында махсус кагыйдәләр төзергә управага гарыз иткән [белдергән]. Управа бу гаризаны управа әгъзасы К.А.Осиповка тапшырган.

Асрарга ике бала бирелә

Бу көннәрдә Казанга Минскидан ике мөселман поляк (поляклашкан татар) баласы китерелгән. Бу балаларның берсе — 7 яшьлек Ягъкуп, икенчесе — 4 яшьлек Фатимадыр. Балалар сау, таза, матур вә пакизәләр [чисталар]. Боларның аталары вафат булып, аналары икенче иргә чыккан, вә бу соңгы ире дә аналары хәстәләнгәч балаларны асрарга теләмәгән вә шунлыктан бер мәрхәмәтле кеше боларны Казанда берәр җиргә урнаштырып булыр бәлки дип, монда китергән икән. Мөселманнардан бу балаларны тәрбиягә алучы табылмаса, башка милләт гаиләсенә булса да бирелү мәҗбүриятендә икәннәр. Өмет итәбез, баласыз берәр гаилә мәрхәмәт итеп, шул бәхетсез балаларны үз яннарына алыр вә бу яшьлекләреннән иң зур бәхетсезлеккә очраган кечкенәләрне мәрхәмәтле кочагында җылытыр. Балаларны күрергә мөмкин: «Сөембикә» журналы идарәханәсендә (Кабан күленең аргы ягы белән сузылган урамда, Архипов йортында, беренче номерлы квартирда).

Кояш. — 1914. — №572. — 5 декабрь.

Шәкертләр һәдиясе

5 нче городской кызлар мәктәбендә укучы шәкертләрдән сугыш мәйданындагы гаскәриләргә һәдия [бүләк] өчен 14 сум 32 тиен акча җыелды. Бу акчага ун пар җылы оек, егерме пар җылы оекбаш һәм дә җитмеш пачка папироса алынды. Кызлар тарафыннан китерелгән чәй, шикәр, кәгазь, конфет, энә вә җепләр илә барысы бергә җитмеш капчык тутырылып, окружной инспектор зәүҗәсе [хатыны] мадам Богоявленская җәнапларына тапшырылды. Мәктәп мөдирәсе: Мәрьям Мөхетдиния.

Кояш. — 1914. — №573. — 7 декабрь.

[4] Барабызлар — XIX йөз-XX гасыр башында кешеләрне гади йөк чаналарына утыртып юл йөртүче извозчиклар.

Муллаларга барып язылыгыз

Гаскәри хезмәткә алынганнарның хисабын управа муллалардан сорый. Шәһәребезнең һәр имамы, үз мәхәлләсендә булган иганәгә мохтаҗ гаскәри гаиләләрен, 10 декабрьдә язып, управага бирәчәк. Бинаән галәйһи [шуның өчен] гаскәргә алынганнарның гаиләләре кай мәхәлләдә булса, шул мәхәлләнең имамына барып, вә воинский начальниктан үзенең гаскәри гаиләсе икәнчелегенә алган шәһадәтнамәсен күрсәтеп, үзен яздырырга тиештер. 10 декабрьгә кадәр барып, әлбәттә, яздырсын. Моны укыган адәмнәрнең, үзләре белгән иганәгә мохтаҗ гаскәри гаиләләренә ирештерүләре үтенеләдер.

Кояш. — 1914. — №574. — 8 декабрь.

Сөембикә марасы

Шәһәр управасы ошбу 1914 нче елда Сөембикә манарасын 2000 кадәр сум мәсариф белән беркадәр төзәттергән иде. Бу хәтле генә төзәтү искерүнең ахыр чигенә җиткән тарихи бу манарага бик аз ислях бирә алган. Инде хәзер управа киләсе елга бу манараны ишлерәк рәвештә төзәтергә уйлап, техника шөгъбәсенә тапшырган. Шәһәрнең техника шөгъбәсе, бу эшне тикшергәч, киләсе 1915 нче ел сметасына ошбу манараны төзәтергә 5000 сум мәсариф керткән.

Гаскәри гаиләләренә киемнәр

Октябрьнең 19-20ләрендә җыелган әйберләр төрлесе-төрлегә аерылып беткән инде. Бу әйберләр эченнән сугыштагы гаскәриләргә җибәрергә яраклылары җибәрелгән вә бер кыйсеме аерылган булып, болардан калган кыйсемендә байтак кына балаларга яраклы киемнәр бар икән. Шәһәр управасы, бу киемнәрне гаскәргә алынганнарның мохтаҗ балаларына өләшергә карар биргән һәм шушы әйберләрне алыр өчен, мохтаҗ балаларны әйберләр саклана торган җиргә күндерүне чиркәү мөтәвәлиләренә һәм дә мәхәллә имамнарына әйткән.

Кояш. — 1914. — №579. — 14 декабрь.

Шәрык клубында

14 нче декабрьдә Шәрык клубының идарә мәҗлесе булып, мәҗлес, иң әүвәл, клуб әгъзалары арасында Русия илә сугыш хәлендә булган дәүләтләрнең тәбәгаләре[5] булып-булмадыкны тикшерде. Фәхри [мактаулы] әгъзалары арасында Хөсәен Хильми паша[6] бар икән. Клуб идарәсе, Төркия хәзерге көндә Русия илә сугыш хәлендә булындыгыннан, аның тәбәгасен үзендә әгъза итеп тотуны мәгъкуль тапмадыгыннан, Хөсәен Хильми пашаны клубның әгъзалыгыннан чыгарырга карар бирде. Аннан соң идарә мәҗлесендә балалар кичәсе ясау мәсьәләсе мөзакәрә[7] ителеп, балалар кичәсен елдагы гадәт буенча ясарга тиеш күрелде. Янә гомуми җыен ясау мәсьәләсе мөзакәрә ителеп, җыенга катнашыр өчен акча түләгән әгъзаларның саны тикшерелде. Бу ел акча түләүнең мөддәтен [срогын] гыйнвар аена кадәр кичектерүгә карамастан, әгъзалык бәдәлен [хакын] түләүчеләр күп түгел икән.

Кояш. — 1914. — №581. — 16 декабрь.

---

[5] Тәбәгә — берәр дәүләтнең гражданнары, берәр дәүләт кул астындагы халык.
[6] Хөсәен Хильми паша (1855-1922) — Госманлы империясенең бөек вәзире, соңрак Венадагы илчесе.
[7]Мөзакәрә итү — фикер алышу.

Мәдрәсәи «Госмания»[8]

Тихвинская урамындагы мәдрәсәи «Госмания»нең доходлы бер йортын һәм постоялый дворын иҗарәгә [арендага] бирү хакында 29 нчы декабрьдә дүшәмбе көн кич сәгать биштә торги булачак. Иҗарә мөддәте [срогы] 1 нче февральдән башлап өч елга кадәр.

Кояш. — 1914. — №582. — 17 декабрь.

Муллаларга хөкем

Мамадыш өязендәге Елышово авылында[9] Мөхәммәт Гатин һәм Ибраһим Бикмөхәммәтов дигән ике мулла мәктәпләр ачып, пәнҗешәмбе сәдакалары бәрабәренә ир вә кыз балалар укыта башлаган булган. Балалар 20 кадәр булган. Халык мәктәпләре инспекторы бу хәлне күреп, мәктәп ачуга хосусый рөхсәт алмаган бу ике мулла өстеннән протокол куярга полициягә хәбәр иткән, вә полиция протокол куйган булган. Якын көннәрдә Казанның окружной судында шушы эш каралды. Муллалар, мәктәпне мәхәллә халкы соравы буенча ачтык, дип күрсәтәләр. Окружной суд Гатинны бер көнгә, Бикмөхәммәтовны 4 көнгә хәбес итәргә [кулга алырга], мәктәпләрне ябарга хөкем итте.

Кояш. — 1914. — №584. — 19 декабрь.

Хөббелинсан җәмгыяте

Хөббелинсан[10] җәмгыятенең Казан шөгъбәсе [бүлеге] өяз земстволарына мөрәҗәгать итеп, шушы шөгъбәгә иганә билгеләүләрен сораган булган. Хәзергә кадәр бу мөрәҗәгатьләргә ике өяздән кабул җавабы килгән: 1) Ядрин өязе — 200 сум; 2) Спас өязе 100 сум билгеләгән. Хәзерге көндә бу акчалар шөгъбә кассасына җибәрелгәннәр дә инде.

Кояш. — 1914. — №588. — 24 декабрь.

Куен дәфтәре

Берничә елдан бирле нәшер ителеп килә торган куен дәфтәренең 1915 нче елгысы да шушы көннәрдә мәйдан интишарга[11] куелган. Габдрахман хәзрәт Гомәров тарафыннан 5 елдан бирле нәшер ителеп килә торган бу куен дәфтәре үзенең мөндәриҗаты вә нәфасәте [бизәлеше] илә елдан ел тәрәккый итә барадыр. Бу елгысында календарь, юл йөрешләре, тыйбби [медицинага бәйләнешле] вә хозяйственный киңәшләр, 1914 нче елдагы зур вакыйгалар, вексель кәгазьләренең бәһаләре кебек кешегә һәрвакыт кирәк була торган мәгълүматлар кыскача гына дәрҗ ителгән. Хасыйл [нәтиҗәдә], куен дәфтәре булган кеше, һәрвакыт ашыгычлык берлә кирәк була тоган мәгълүматның күбесен үз дәфтәреннән таба алачак. Дәфтәрнең ашыгычлык илә языла торган запискалар өчен запас кәгазе дә байтак. Дәфтәрнең бәһасе — егерме тиен.

Кояш. — 1914. — №589. — 25 декабрь.

---

[8] Мәдрәсәи «Госмания» — 1867-1918 елларда эшләгән мәдрәсә. Бинасы Җиһанша бай Госманов тарафыннан салынган.
[9] Елышево — хәзерге Саба районындагы Елыш авылы.
[10] Хөббелинсан — кешене сөю, ярату.
[11] Мәйдан интишар — таралу мәйданы, ягъни сәүдә итү урыны, базар, кибет мәгънәсендә.

Ул елларга карап көнләшерлек...

«Чаян» редакциясе, үзенең утырып эшләрлек рәтле бүлмәсе юклыгын исәпкә алып, Казан шәһәрендәге иң зур йортларга караганда да зуррак иттереп йорт салдырды. Рәсемдә «Чаян» редакциясе йортының бер кечкенә кисәге (бөтен килеш журнал битенә сыйдырып булмады) күрсәтелә. Хәзер инде бу биек йортка күчәр көннәр якынлашып килә.

«Чаян» белән бергә башка редакцияләр дә шатлансыннар. Чөнки «Чаян» бу йортны берүзе генә файдаланмаячак — үзеннән артып калган бүлмәләргә, моңар кадәр утырып эшләү өчен рәтле урын таба алмый йөргән «Кызыл яшьләр», «Яшь Ленинчы» газеталарын, «Пионер каләме», «Техника», «Совет әдәбияты» һәм «Азат хатын» журналларын урнаштырачак. Шулай ук «Кызыл Татарстан» газетасын һәм барлык газета-журналларны басып чыгаручы типографияләрне дә сыйдырырбыз әле. «Чаян» әле боларга урын бирү белән генә чикләнмәскә уйлый.

Татгосиздатның барлык секторларын һәм иң зур китап кибетләрен дә үз янына алырга чамалый. Китап, кәгазь складларына да өлеш чыгарырга исәп юк түгел. Хәтта, гомер буена бүлмәгә туймый йөргән Реклам бюроны да «Чаян» абзагыз читтә калдырмас: клуб күрергә тилмергән язучылар, журналистлар да «Чаян» канаты астында җылы табарлар. (Билгеле, «Чаян» үзенә дә бер аерым бүлмә эләктерәчәк.)

1934 ел, «Чаян», 17-18 нче саннар.
*Сәхифәне **Алмаз Хәмзин** әзерләде.* ■

- ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНА КЕРЕРГӘ СОРАП ЗАЯВЛЕНИЕ ЯЗЫП БИР ӘЛЕ, ИПТӘШ, ҮЗЕМ КИЛЕШТЕРЕП ЯЗА БЕЛМИМ.
- АЛАЙСА СИҢА, КИЛЕШТЕРЕП ЯЗАРГА ӨЙРӘНГӘНЧЕ, КӨТӘРГӘ ТУРЫ КИЛЕР ИНДЕ.

Мирасворд

Гарәп язуы төре

… Шагыйрь-жан

Ша-гыйрь Зәки …

«Кыйсса-сел-әнбия» китабы авторы

Кыргыз эпосы

Иртәнге саф, йомшак җил

Борынгы Идел

Борынгы Римда көмеш тәңкә

«Ител суы … торур» (Н.Фәттах)

Тегү машинасы механизмы

Төрки халык

… Ишморат

Пәйгамбәр

Күпме булса да җитми

Коръәнне яттан укучы

«Рәдде бичара кыз» драмасының авторы

Марсель Галиевнең 2005 елда чыккан китабы

Язучы … Дунай

Экскурсовод

… Туишева

1800 елда Казанда ачылган беренче типография

Хәзәр каганлыгындагы шәһәр

Россия составындагы җөмһүрият

Вивьен …

Драматург Хәй …

Африка күле

Нота

… Барбюс

… — Енисей язмалары

Камыр чималы

Хәнҗәр савыты

Борынгы болгар сугышчылары өс киеме

Нечкә йонлы сарык токымы

Крит утравындагы тау

Бер урында даими яшәүче

Англиядә 91,4 см.га тигез үлчәү берәмлеге

Ау кошын кундырып йөртә торган агач

Жак … Кусто

Алтайлыларның элекке атамасы

Кавказда яшәүче аз санлы халык

Актаныш районындагы авыл

… -аут

Римның беренче патшасы Ромулның абыйсы



Рәис Габдулла төзеде.

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: чабата, бакрач, еру, «Җомга», кирмән, өрек, саам, Лев, кем, гает, Амара, Кашгарый, Лао, уа, Гай, Садыйкова, Роза, «Ла», лор, Лодзь, лыбы, «Мазда».
Өстән аска: Җангали, Колый, Мөлеков, зоб, Грета, сарын, Апанаев, «Шура», яга, Абрек, Аристарх, йолым, Акчура, ым, Мамай, «Йолдыз», әмер, «Аваз», кашага, Аль.

2014 ЕЛГА «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

ТАРИХИ МИРАС

Азат Зыятдинов белән **Илдус Заһидуллин** әңгәмәсе. Республикабыз мәнфәгатьләрен кайгыртып. — №1. — Б.47-53.

Айдар Гайнетдинов. «Нократка бардык без…» — №6. — Б.35-36.

Алмаз Мөхәммәдиев. Идел буе Болгар дәүләтендә мөселман мәхкәмәләре һәм казыйлары. — №1. — Б.4-11.

Вахит Имамов белән **Равил Сабыр** әңгәмәсе. Вахит Имамов: «Nein, nein, ich bin kein Russisch, ich Tatar!» — №4. — Б.68-71.

Габделбарый Баттал. Сөембикә манарасы. — №10. — Б.29-39; №12. — Б.9-19.

Габделхаликъ Әхмиров. Япон сугышы яки татар солдаты. — №3. — Б.29-39.

Газинур Морат. Арыслан. — №4. — Б.67.

Гаяз Сәмигулов. XVII-XVIII гасырларда Көньяк Урал төбәгендә яшәгән татарлар тарихыннан. — №1. — Б.12-23.

Гомәр Даутов. Гамьле сәфәр хатирәсе. — №6. — Б.44-45.

Дамир-Сәед Шаһаби. Җәмалетдин әл-Әфгани һәм Ризаэддин Фәхреддин. — №2. — Б.23-28.

Диләрә Госманова. Каурый каләм эзеннән… — №5. — Б.20-22.

Фәнзаман Баттал. Тәхетле Җәллад. — №12. — Б.4-8.

Әзһәр Мөхәммәдиев. Мең еллар элек… — №7. — Б.4-10.

Әлфинә Сибгатуллина. Ататөрек мәктүбе. — №7. — Б.14-17.

Әлфрит Бостанов. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Галимҗан Барудиның яңа табылган кулъязмалары. — №2. — Б.18-22.

Җәмил Мөхәммәтшин. Иске Рәҗәп авылы зиратының кабер ташлары. — №6. — Б.30-34.

Җәүдәт Миңнуллин. Г.Батталның «Сөембикә манарасы» хезмәте хакында. — №10. — Б.40-42.

Зариф Бәшири. Мишәрләр. — №10. — Б.43-47; №11. — Б.14-21; №12. — Б.22-27

Ильяс Мөстәкыймов. XV-XVIII гасыр төрки-татар дәүләтләре тарихы буенча гарәби язулы нарратив чыганаклар. — №2. — Б.4-18.

Ильяс Мөстәкыймов. Төрки-татар тарихи терминнары.— №5. — Б.50-51.

Ильяс Мөстәкыймов. Төрки-татар тарихи терминнарының аңлатмалы сүзлеген төзүгә карата. — №4. — Б.72-79.

Инера Сәфәргалиева. Вулкан серен ачкан татар. — №5. — Б.52-55.

Йосыф Акчура. Төрек вә татар тарихы. — №10. — Б.22-28.

Йосыф Акчура. Яңа төрек дәүләте уңчылары. — №1. — Б.27-35; №2. — Б.36-43; №3. — Б.20-23; №4. — Б.54-56; №5. — Б.17-19; №6. — Б.26-29; №7. — Б.11-13; №8. — Б.34-37; №9. — Б.9-11; №12. — Б.20-27.

Ирек Һадиев. Тарихи ташъязмалар белгече. — №7. — Б.18-21.

Ленар Гобәйдуллин. «Ватанпәрвәрлек нә-маишләре». — №8. — Б.38-45.

Ленар Гобәйдуллин. Гыйлем, мәгърифәт нурын чәчүче... — №1. — Б.36-38.

Ләбиб Лерон. Миркасыйм! — №5. — Б.29.

Марсель Әхмәтҗанов. Алтын Урда чоры этник тарихына карата кайбер фикерләр. — №4. — Б.57-61.

Мәсгуд Гайнетдин. Йосыф Акчура һәм аның «Яңа төрек дәүләте уңчылары» әсәре. — №1. — Б.24-25.

Мәсгуд Гайнетдин. Хәтер көне байрагы. — №10. — Б.20-21.

Минтимер Шәймиев: «Гомер буе вакыт җитмәде». — №3. — Б.14-19.

Минтимер Шәймиев: «Кизәк яккан чаклар да бар иде...» — №5. — Б.4-6.

Миркасыйм Госманов белән **Нәсим Акмал** әңгәмәсе. «Шәхесләрсез милли тарих юк...» — №5. — Б.42-49.

Миркасыйм Госманов. Археографик көндә-лек. — №5. — Б.23-28; №6. — Б.41-43.

Михаил Худяков. Казан татарларында агач архитектурасы. — №9. — Б.4-8.

Нәсим Акмал. Соңгы әңгәмә.— №5. — Б.40-41.

Нократ бәете. — №6. — Б.37-40.

Һади Атласи. Сөенбикәне сагыну. — №10. — Б.18-19.

Һарун Йосыпов. Болгар-татар эпиграфика-сында антропонимнар. — №7. — Б.22-27.

Раиф Мәрданов. «Сугышта вәйран була газиз башлар...» — №10. — Б.48-57.

Раиф Мәрданов. Хәтер яңарту: рус-япон сугышы татар чыганакларында. — №3. — Б.24-28.

Ризаэддин Фәхреддин. Шәех Җәмалетдин. — №2. — Б.29-35.

Рифкать Әхмәтҗанов. Нардуган һәм сәүмәт. — №1. — Б.54-57.

Роберт Әхмәтҗан. Тәп йорт. — №5. — Б.7.

Сәмига Сәүбанова. Йортларның да җаны бар. — №3. — Б.40-46.

Фатих Әмирхан. Бөек шигарь, олуг идеал. — №9. — Б.12-13.

Фаяз Хуҗин. Борынгы Чаллыга тарихи сәяхәт. — №11. — Б.4-13.

Фәйзелхак Ислаев. Уртак мирас. — №10. — Б.10-17.

Фәния Фәйзуллина. Милләт язмышын кай-гыртып... (Гаяз Исхакый көндәлеге). — №4. — Б.62-66.

Ярослав Пилипчук. Кыпчакларның хәрби сәнгате. — №5. — Б.8-16.

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ

«Чын мирас» журналы: кичә, бүген, иртәгә». — №3. — Б.2-12.

«Язма мирасны барлау юлында». — №5. Б.30-39.

ӘДӘБИ МИРАС

«Әлифба» музее... Бердәнбер! — №4. — Б.107.

Айдар Гайнетдинов. Кан алдыру үзенчәлекләре. — №2. — Б.106-109.

Альта Мәхмүтова. Р.Фәхреддин: «Милләт аналары йитешдерегез!» — №2. — Б.64-69.

Без ачлыкны ешрак күрдек шикелле... — №12. — Б.88-89.

Бер рәсем тарихы. — №3. — Б.53.

Бим шәһәре төзүчесе һәм Гүәшир падишаһның вәзире. — №12. — Б.51-63.

Габдулла Тукай. Ачы тәҗрибә авазы. — №9. — Б.78-79; №10. — Б.93-95; №11. — Б.74-76; №12. — Б.90-92.

Гаяз Исхакый. Солдат. — №8. — Б.87-89; №9. — Б.60-67; №10. — Б.80-87; №11. — Б.56-59; №12. — Б.64-73.

Дания Заһидуллина. Кеше кичерешләренең рәссамы. (Шәриф Камалның тууына 130 ел) — №2. — Б.96-105.

Әдип турында замандашлары (Әмирхан Еникинең тууына 105 ел) — №3. — Б.75.

Әмирхан Еники. Кунакчыл дошман. — №5. — Б.64-75.

Әнвәр Шәрипов. Асыл шигырь югалмас! — №7. — Б.54-61.

Әнвәр Шәрипов. Йөрәк каны белән языл-ган. — №6. — Б.64-68.

Әхтәм Зарипов. Ике рәсем тарихы. — №11. — Б.60-61.

Зариф Мөэминов. Мәрьям. — №2. — Б.70-87; №3. — Б.54-73.

Зиннур Мансуров. Тукайча татар кодексы. — №4. — Б.88-102.

Йосыф Баласагуни. Кутадгу билик (Ко-тайткыч белем). — №1. — Б.58-70; №2. — Б.46-62; №3. — Б.48-51; №4. — Б.80-87; №5. — Б.56-61; №6. — Б.60-63; №7. — Б.48-53; №8. — Б.78-81; №9. — Б.56-59; №10. — Б.76-79; №11. — Б.52-55; №12. — Б.44-47.

Лена Гайнанова. Чишмә башы. — №1. — Б.72-83.

Ләбиб Лерон. Әмирхан Еники музее булыр-мы? — №3. — Б.76-77.

Марсель Әхмәтҗанов. «Айкай сине Иде-лем...» - №12. — Б.74-78.

Марсель Галиев. Бишенче фасыл. — №5. — Б.84-87.

Марсель Галиев. Күчем ханның онысы. — №9. — Б.68-76.

Марсель Галиев. Сүз хәнҗәре кынындамы? — №3. — Б.78-83.

Марсель Галиев. Табарлар безнең эзләрне. — №2. — Б.63.

Марсель Галиев. Хәтер ярыннан торып... — №1. — Б.96-100.

Марсель Галиев. Чын шагыйрь иде. — №2. — Б.88-92.

Марсель Әхмәтҗанов. Шагыйрь Дусмәмбәт. — №11. — Б.62-67.

Мәсгуд Гайнетдинов. Гаяз Исхакыйның «Солдат» романы. — №8. — Б.82-86.

Милли мәзәкләр. — №3. — Б.86.

Миннәхмәт Кашапов. Язмышым бүләге. — №12. — Б.85-87.

Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль. Маҗаралы хикәятләр. — №12. — Б.48-50.

Нәсим Акмал. Кемдер калыр барыбер сагынып... — №11. — Б.68-73.

Нияз Акмал. Шигырьләр. — №2. — Б.93-95.

Разил Вәлиев. Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә... — №1. — Б.71.

Рәмзи Вәлиев. Фаил — Карашәм күгендәге йолдыз. — №5. — Б.76-81.

Рәмзи Вәлиев. Бәяләмә... — №12. — Б.79-84.

Рәшит Әхмәтҗанов. Шигырьләр. — №6. — Б.79.

Рөстәм Акъегет. «Ана күңеле дә ирешмәслек еракларга китеп барышым...» — №7. — Б.62-71.

Рөстәм Акъегет. Карәхмәтнең соңгы көннәре. — №8. — Б.92-93.

Сәмига Сәүбанова. Киткән кебек тә түгел... — №6. — Б.74-78.

Тәлгат Галиуллин. Язмыш йөртә кешене. — №10. — Б.88-92.

Тукай энциклопедиясе. — №4. — Б.103; №5. — Б.90; №6. — Б.73; №8. — Б.90; №9. — Б.77; №10. — Б.96-97; №11. — Б.77; №12. — Б.93-94.

Үткәннән хатлар — №5. — Б.82-83; №6. — Б.69-72.

Факил Сафин. Әкиятче бабай. (Зариф Мөэминовның тууына 120 ел). — №1. — Б.84-95.

Фәннур Сафин. Шигырьләр. — №3. — Б.84-85.

Эдуард Мостафин. Шигырьләр. — №5. — Б.88-89.

Эльмера Галимҗанова, Фәния Фәйзуллина. Тукай дәреслеге (Г.Тукай төзегән җыентыкларның милли әдәбият үсешендәге әһәмияте). — №4. — Б.104-106.

Эльс Гаделев. Шигырьләр. — №1. — Б.101-103.

Яңа китап. — №8. — Б.91.

СӘНГАТИ МИРАС

«Идел» бит ул... «Идел» бит ул!. — №6. — Б.90-97.

Бикчәнтәевләр йолдызлыгы. — №3. — Б.105-107.

Габдулла Шамуков. Тукай образын иҗат иткәндә. — №4. — Б.108-110.

Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. Гасырлардан килгән матурлык. — №1. — Б.106-111.

Әзһәр Шакиров. Сөйкемле сөякле Фирдәвес. — №7. — Б.80-85.

Әхтәм Зарипов. Зөләйха. — №3. — Б.96-104.

Әхтәм Зарипов. Минзәләм мизгелләре. — №6. — Б.80-89.

Марс Макаров. Бәяләнмәгән талант. — №9. — Б.96-101.

Марс Макаров. Җыры калды. — №8. — Б.98-101.

Марс Макаров. Сәйдәш маршы. — №5. — Б.98-99.

Рашат Низами. Ул — Яруллиннар йолдызлыгыннан. (Фәрит Яруллинның тууына 100 ел). — №1. — Б.112-119.

Филүсә Арслан. Милли мирас сагында. — №3. — Б.88-95.

Хәбир Ибраһим. «Тыңлар идем тавышыңны...» — №8. — Б.102-105.

ФӘННИ МИРАС

Алмаз Гафиятов. Спорт тарихы — ил тарихы. — №3. — Б.116-118.

Таһир Гыйлаҗев. Җиһанда сүзе калыр. — №5. — Б.100-102.

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Ләбиб Лерон. — №4-12.

КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛДА МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

İstiklal Marşı. — №4. — Б.40.

Алмаз Гафиятов. Безнең ничек көрәшкәнне тарих белеп тора... — №4. — Б.52-53.

Габделкадыйр Инан. Тәңреләр һәм рухлар. — №4. — Б.38-39.

Галиҗәнап Шигырь сүз ала... — №8. — Б.30-31.

Әбдиморат Атаҗанов. Җәйрәннәр. — №8. — Б.22-27.

Илсөяр Рәмиева. Тукай әсәрләре кырым татар телендә. — №4. — Б.29.

Лирон Хәмидуллин. Еракгагы якын кардәшләр. — №8. — Б.19-21.

Лирон Хәмидуллин. Үзбәк әдәбиятына үз өлешен кертүчеләр. — №4. — Б.30-35.

Минтимер Шәймиев: «Без — төрки дөньяның бер өлеше». — №4. — Б.5-11.

Нурулла Гаптуллин. Ат уйнаткан вакытлар... — №4. — Б.36.

Рафис Корбан. Кардәш әдипләр хезмәттәшлеге. — №8. — Б.4-5.

Резеда Ганиева. Фөзули иҗаты һәм татар әдәбияты (Фөзулинең тууына 520 ел). — №4. — Б.12-17.

Рәдиф Гаташ. Яңа чор үзбәк шигърияте Чулпаны. — №9. — Б.20-23.

Рәшит Минһаҗ. Дуслык күперен ныгыткан-да. — №8. — Б.32-33.

Ризаэддин Фәхреддин. Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр: Фөзули. — №4. — Б.18-21.

Ркаил Зәйдулла. Рәештәге рәвеш. — №10. — Б.4-9.

Ркаил Зәйдулла. Төркләр. — №4. — Б.37.

Төрки дөнья әдипләре хәзинәсеннән: Мәхтүмколый. Булмас; Токтогул. Кызыйлар; Чулпан. Шәрык нуры; Р.Н.Гүнтәкин. Мәхәббәт әсире; М.Әүэзов. Өйләнү. — №4. — Б.42-51.

Төркиянең Дәүләт гимны. — №4. — Б.41.

Усеин Болатуков. Айшә ханым. — №7. — Б.39-45; №8. — Б.6-12; №9. — Б.14-19.

Фирдәвес Гарипова. Исемдә дә, җисемдә дә исән без! — №8. — Б.13-18.

Фөзули шигырьләре. — №4. — Б.22-23.

Хатыйп Миңнегулов. Татар-төрек әдәби бәйләнешләре яссылыгында Тукай иҗаты. — №4. — Б.24-28.

Шөһрәт Ризаев. Үзбәк театры үсешенә татарлар йогынтысы. — №8. — Б.28-29.

ҖИҢҮ — 70

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе. — №7. — Б.79.

Алексей Литвин, Рәис Төхфәтуллин. «Кайту» тарихы: ФСБ архивыннан бер документ. — №8. — Б.63-68.

Алмаз Хәмзин. Бабаларым, әбиләрем... — №10. — Б.65-68.

Асилә Закирова. Уфалла арбасы. — №9. — Б.44-45.

Әлфия Шамова. Дәһшәтле еллар хатлары. — №10. — Б.69-73; №11. — Б.36-39. №12. — Б.36-39.

Җәлилчеләр иҗаты. — №8. — Б.60-62.

Ләбиб Лерон. Бабайларыбызның каберләре кайда — 2. — №11. — Б.32-35.

Ләбиб Лерон. Бабайларыбызның каберләре кайда? — №5. — Б.91-95.

Мидхәт Садыйков. Берлинны кем алган?.. — №5. — Б.96-97.

Мостай Кәрим. Җәләлетдин эти. — №6. — Б.48-59.

Рашат Низами. Низаметдинның ике улы. — №9. — Б.51-53.

Ришат Гапсәләмов. Бабам истәлекләре. - №12. — 34-35.

Фәрит Баттал. Кем ул — Абдулла Баттал?! — №8. — Б.69-75; №9. — Б.46-50.

Хатлар яздым утырып... — №7. — Б.46-47; №8. — Б.76.

Хәнәфи Бәдигый. Данлы юл эзләре. — №9. — Б.54-55.

Шаһинур Мостафин. Беренче гвардиячеләр. — №10. — Б.62-64.

Шаһинур Мостафин. Очыш дәвам итә. - №12. — Б.31-33.

Шәфигулла Гарипов. «Илемә булган сөю ялкыны». — Б.40-41.

Эльвира Ихсанова. Бер рәсем тарихы. — №6. — Б.46-47.

ШАЯН МИРАС

«Тынгысыз каләм» битләреннән... — №6. — Б.112-117; №7. — Б.102-107; №8. — Б.114-117.

Көлке куа килә... — №9. — Б.116-118; №10. — Б.116-118.

Рабит Батулла. Көлке көлә килә, артыңнан куа килә... — №11. — Б.110-118.

Рәисә Шәрәфиева. «Шура» журналыннан — мәзәкләр. — №5. — Б.111; №6. — Б.111; №7. — Б.101; №8. — Б.118.

Ул елларга карап көнләшерлек... — №12. — Б.112-113.

Фаил Шәфигуллин. Кумпык. Тмин Казанда. — №5. — Б.112-115.

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

Атлас Гафиятов. Дөнья иңли Сабантуйлар. — №6. — Б.24-25.

Көрәшче Мәрҗани — №6. — Б.22.

Ленар Гобәйдуллин. Миллият рухы бәйрәме. — №6. — Б.4-13.

Мөдәррис Әгъләм. «Сөлгеләр тотыла, һәр авыл...» — №6. — Б.23.

Мөхәммәт Мәһдиев. Сабан туе бизәкләре. — №6. — Б.14-21.

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

Адлер Тимергалин. Миллият сүзлеге. — №3. — Б.108-111; №4. — Б.112-114; №5. — Б.103-105; №6. — Б.103-105; №7. — Б.86-89; №8. — Б.106-109; №9. — Б.106-109; №10. — Б.108-111; №11. — Б.98-101. №12. — Б.100-103.

Әткәм-әнкәм, балам-оныгым теле. — №11. — Б.102-105.

Миргазиян Юныс. Тел язмышы — милләт язмышы. — №9. — Б.102-105.

Рөстәм Акъегет. Әткәм-әнкәм, балам-оныгым теле.... — №6. — Б.98-99.

Сибгат Хәким. Тел ил белән икән. — №6. — Б.100-102.

Фирдәвес Гарипова. Юлларыбызга изге капкалар ачылсын. — №7. — Б.90-95.

100 ЕЛ ЭЛЕК

Ленар Гобәйдуллин. «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 ел. — №№1-12.

ДИНИ МИРАС

Айдар Гайнетдинов «Шәкертләргә бүләк иттем...» — №9. — Б.24.

Альмира Таһирҗанова. Хөрмәткә лаек исем. — №11. — Б.26-29.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин. Ал мәчет. — №9. — Б.30-33.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин. Яңа татар бистәсе зиратының юл күрсәткече. — №11. — Б.22-25.

Ризаэддин бине Фәхреддин. «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» — №9. — Б.25-29; №10. — Б.58-61.

Ризаэддин бине Фәхреддин. Ислам диненең бинасы. — №6. — Б.118.

ХӘТЕР САГЫНДА

Айгөл Әхмәтгалиева. «Тамырлардан безне таныйрлар...». — №8. — Б.46-57.

Александр Филиппов. Кыштым афәте. — №10. — Б.100-105; №11. — Б.88-93.

Гәрәй Рәхим. Ипле һәм игътибарлы түрә иде. — №12. — Б.96-99.

Милли музей хәзинәләре. — №9. — Б.89.

Мөбарәк Мусин. Урланган такта кыйссасы. — №9. — Б.80-84.

Рамил Вәлиев. Мөкатдәс хәзинә. — №9. — Б.85-88.

Руфия Мөхетдинова. Милли музей хәзинәләре. — №10. — Б.98-99.

Руфия Мөхетдинова. Милли музейда күн эшләнмәләре. — №11. — Б.84-85.

Руфия Мөхетдинова. Чулпылар. — №12. — Б.95.

Хәмзә Бәдретдинов. Милләтне кайгыртучы килен. — №7. — Б.28-38.

Чулпан Мөслихова. Милли мәдәният музеенда Ризаэддин Фәхреддин мирасы. — №11. — Б.86-87.

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Әхтәм Зарипов. Ташкыннардай ташкан еллар... — №7. — Б.72-73.

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

Бер бәйләм беркетмә — №5. — Б.62-63.

«Якутлар табыладыр вакыт белән» — №11. — Б.78-83.

Авыл өстендә йолдызлар. — №8. — Б.94-97.

Заман утлары — №7. — Б.74-78.

Ярты гасыр элек — татар мәктәбе. — №9. — Б.90-95.

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

Расиха Фәизова. Феномен. — №7. — Б.108-110.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Афәрин, «Идел»! — №7. — Б.111-116.

МИРАС ҺӘМ ВАРИС

Юрист киңәше — №5. — Б.116-117; №7. — Б.117-118.

ПЕДАГОГИК МИРАС

И, туган тел... — №9. — Б.40-41.

К.Бикколый, Г.Госмани. Әхлак. — №9. — Б.38-39; №11. — Б.30-31; №12. — Б.28-30.

Ләлә Мортазина. Белем әлифбадан башлана. — №9. — Б.34-37.

ХӘТЕР САНДЫГЫ

Газинур Морат. Сүз һәм сурәт. — №10. — Б.74-75.

Ислам Әхмәтҗанов. Сүз һәм сурәт. — №9. — Б.42-43.

Марат Закир. Хакыйкатьнең төсе нинди? — №12. — Б.42-43.

Равил Фәйзуллин. Сүз һәм сурәт. — №11. — Б.40-41.

Разил Вәлиев. Сүз һәм сурәт. — №8. — Б.58-59.

ТАБИГЫЙ МИРАС

Акташ упкыны. — №10. — Б.106-107.

Кара күл. — №8. — Б.105.

Морад Дусай. Ак кыя. — №9. — Б.110-111.

Мөслим төбәге. — №11. — Б.94-97.

ТАТАР ГАМЕ

Ибраһим Бикколов. Казан татарлары тормышыннан бер кисәк. — №11. — Б.42-45.

Фәйрүзә Мөслимова. «Җырлар чәчтем бакчага...» — №11. — Б.46-51.

СПОРТ

Атлас Гафиятов. «Афәрин, Айрат!». - №12. — Б.104-107.

ЯҢА КИТАПЛАР. — №№1-5.

МИРАСВОРД. — №№3-12.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ. — №№4-12.

Проломный урамы (хәзерге Бауман урамы). Щетинкин йорты

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
Елъязмасы / декабрь

150 ел элек (1864)

3 декабрьдә язучы һәм галим Муса Акъегет (1864-1923) дөньяга килә.

130 ел элек (1884)

19 декабрьдә концерт гармуннарында уйнау остасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, Бөтенсоюз (СССР) гармунчылары конкурсы лауреаты Фәйзулла Туишев (1884-1958) дөньяга килә.

95 ел элек (1919)

26 декабрьдә Халык Комиссарлары Советы РСФСРда укый-яза белмәүчелекне бетерү турында декрет кабул итә.

90 ел элек (1924)

Һади Такташ «Сыркыды авылы» поэмасын яза.

80 ел элек (1934)

Татар дәүләт «Әкият» курчак театры оештырыла.

75 ел элек (1939)

Хезмәт ияләренең җирле Советларына сайлаулар уза. Казан шәһәр Советына сайланучы депутатлар арасында Муса Җәлил, Шәриф Камал һәм Шәйхи Маннур бар.

60 ел элек (1954)

16 декабрьдә бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшев (1900-1954) вафат була.

55 ел элек (1959)

«Совет әдәбияты» журналында Һади Такташның яңа табылган хатлары дөнья күрә.

50 ел элек (1964)

2 декабрь санынннан башлап, «Социалистик Татарстан» газетасында Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» исемле яңа романынннан өзекләр басыла башлый.

25 ел элек (1989)

20 декабрьдә Казан дәүләт университетында филология, тарих, этнография, археология мәсьәләләре белән шөгыльләнүче галимнәрнең җыелышы була. Анда СССР Фәннәр академиясе карамагында көнчыгыш илләрне өйрәнүчеләр Бөтенсоюз ассоциациясенең Татарстан бүлеге оештырыла. Рәис итеп Миркасыйм Госманов сайлана.

НИЯЗ ХАҖИӘХМӘТОВ

Нияз Тавил улы Хаҗиәхмәтов 1969 елның 17 февралендә Казан шәһәрендә туа. Казан сәнгать училищесын (1988), Санкт-Петербургтагы Илья Репин исемендәге рәсем сәнгате академиясенең китап графикасы факультетын тәмамлый. 1997 елдан — Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстан Мәдәният министрлыгының Бакый Урманче исемендәге премиясе лауреаты.

Нияз Хаҗиәхмәтов китап бизәү, дизайн һәм графика жанрларында иҗат итә. Соңгы елларда рәссамның «Казан — Россиянең өченче башкаласы» дип аталган плакатлар сериясе киң танылуга иреште.

Плакат. «Казан – Россиянең өченче башкаласы» сериясеннән. Компьютер графикасы. 2012 ел

«Урта гасырда – Казан». Компьютер графикасы. 2012 ел. Документаль фильм өчен ясалган рәсемнәр



www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

Халкыбызның ерак гасырларга барып тоташкан бәяләп бетергесез бай тарихи үткәне, тирән тамырлы әдәбияты, мәдәни җәүһәрләре – милли мирасы бар. «БЕЗНЕҢ МИРАС» журналы битләрендә ерак гасырлардан сакланып килгән һәм әле моңа кадәр дөнья күрмәгән тарихи, дини-иҗтимагый хезмәтләргә, борынгы һәм хәзерге заман әдәбияты үрнәкләренә, сәнгать әсәрләренә бәйле мәгълүматларга киң урын бирелә, чорыбызның мөһим вакыйгалары, әдәбият, сәнгать яңалыклары яктыртылып барыла.

2015 елның беренче ярты еллыгына язылу бәясе – **420 сум**

БЕЗ - МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «БЕЗНЕҢ МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

12+

4 612750 670172